ЯНӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА
№4 (328) – АПРЕЛЬ 2019

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

ISSN 0130-2418
ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

1920 елдан
нәшер ителә

Халыклар
дуслыгы тарихы

Диагноз:
кешелеклелек

Затлы
мирас

ЛЕОНИД БАРЫШЕВТАН
КӨЧЕ ШӘҺӘРЛӘРНЕ ЯШӘРТҮ РЕЦЕПТЫ

16+

Редакция:
420066, Казан,
Декабристлар ур., 2,
тел. (843) 222-09-79
tatarstan@tatmedia.com

Баш мөхәррир: Татьяна Николаевна Вафина,
vafina@tatmedia.com
Шеф-редактор: Әскәр Сабиров,
sabirov@tatmedia.com
Баш мөхәррир урынбасарлары:
Нияз Әхмәдуллин, ahmadullin@tatmedia.com
Алсу Дәүләтшина
Чыгарылыш мөхәррире:
Фәридә Әхмәтҗанова
Әдәби мөхәррир: Луиза Янсуар
Бүлек мөхәррирләре:
Ольга Туманская, Алёна Кутыркина, Руфия Фазылова
Веб-редактор: Алсу Дәүләтшина
Авторлар: Катерина Котова, Фаяз Хуҗин
Фотографлар: Лилиана Вәлитова,
Александр Ефремов, Ната Смирнова
Дизайн-макет: Леонид Гобәйдуллин
Вёрстка: Игорь Глушков, Леонид Гобәйдуллин
Препресс: Игорь Глушков
Корректор: Айсылу Корманова
Офис-менеджер: Ләйсән Һадиева
Тышлыкта: Леонид Барышев,
«ЭССЕН ПРОДАКШН АГ» ЯАҖ генераль директоры
Ната Смирнова фотосы

Журнал 1920 елдан нәшер ителә

1979 елда Халыклар дуслыгы
ордены белән бүләкләнә

Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр
һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә
күзәтчелек буенча федераль хезмәттә теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС 77 – 66045, 10.06.2016.

Татар телендә тираж: 1100 данә,
рус телендә: 3400 данә

Гомуми тираж: 3500 данә

Бәясе ирекле

Редакциянең язма рөхсәтеннән башка «Татарстан» журналындагы материалларны күчереп бастыру тыела. Күчереп бастырганда, журналның исемен күрсәтү мәҗбүри. Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Реклама материалларының эчтәлеге өчен редакция җавап бирми.

Журнал «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы типографиясендә басылды: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2

Заказ № О-1049
Басарга кул куелды: 24.04.2019
Басмадан чыкты: 29.04.19

Дистрибуция һәм трафик бүлеге җитәкчесе:
Миләүшә Байрашева,
milyaushanb@tatmedia.com

Коммерция директоры:
Юлия Фәсәхова, 89272483384_pr@mail.ru
тел.: (843) 222-09-76, +7-9272-483-384

Коммерция директоры урынбасары:
Җәмилә Әхмәтшина, ahleva5@mail.ru

Бухгалтерия:
Ольга Басаркина, тел. (843) 222-09-80

Махсус проектлар бүлеге җитәкчесе:
Алсу Троицкая, alsu_1970@list.ru
тел.: (843) 222-09-79

КАНАТЛЫ ВАКЫТ

Апрельдә без очабыз. Күчмә кошлар кебек – мәңгелек җәйдән кыска вакытлы, әмма гаҗәеп матур язга. Ягъни туган якка. Самолетларда Башкортостан пассажирлары Татарстан көннәре уңае белән очкандай. Кадерле күршеләреңне күрмичә ярамый бит инде! Кайчакта үткәнгә дә очабыз – яшьлекнең кадерле мизгелләренә. Ә кайчакта Галәмнең үзенә дә юл тотабыз – йолдызларны якыннан күреп, яңадан өйгә әйләнеп кайтыр өчен. Кайтуыбызга безне йомшак диван белән җирдәге иң гаҗәеп хис – мәхәббәт көтә. Оча торгач, инде талчыгып та куябыз, кайчан безгә канатларын җилпеп Биклән ләкләге килер икән дип, зур өметләр белән көтә башлыйбыз. Ул демографик миссиясен яхшы белә бит, бәхет алып килеп бүләк итү миссиясен – аннан да яхшырак.

Яз ул – күчмә вакыт, җәмәгать! Аның койрыгын ычкындырмагыз. Сезнең бу айдагы да, киләсе айлардагы да юлдашыгыз булган (һәм булачак) «Татарстан» журналы очышлар турында барысын да белә! Ул хәтта казлар очышын да тел шартлатырлык итеп сурәтләп бирергә сәләтле.

Апрельнең барлык очышлары да – шушы санда. Иң мөһиме – сез укудан гына йөз чөермәгез. Ә бит уку, очыш шикелле үк, акыллы һәм канатлы кешеләрне аерып тора торган асыл сыйфат.

СЕЗНЕҢ АКЫЛЛЫ РЕДАКЦИЯГЕЗ

Редакция советы:
АЛАЕВ Юрий Прокопьевич
АЛЕКСАНДРОВСКАЯ Ирина Алексеевна
ӘХМӘТШИН Равил Кәлимуллович
БЕЛЯКОВ Роман Юрьевич
БИКЧӘНТӘЕВ Фәрит Рәфкатович
БОЛЬШАКОВ Андрей Георгиевич
ВӘЛИЕВ Разил Исмәгыйлевич
ВӘЛИЕВА Зилә Рәхимҗановна
ГАЛИЕВ Марат Гадыевич
СӘЛӘХОВ Мәгъзум Кәлимуллович
ФӘЙЗУЛЛИН Равил Габдрахманович
ХӘКИМОВ Рафаэль Сибгатович
ХОМЕНКО Вадим Васильевич

татмедиа

Гамәлгә куючы:
«ТАТМЕДИА» АҖ
Нәшер итүче:
«ТАТМЕДИА» АҖ

420097, Казан,
Академическая ур., 2

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла

«Татарстан» журналына язылу барлык элемтә бүлекләрендә кабул ителә
Индекс **П2381** – татар телендә
Индекс **П2378** – рус телендә
Ярты елга язылу бәясе: **930 сум 00 тиен**

«Татарстан» журналына РФ буенча онлайн-язылу:
Индекс **П7076** – татар телендә
Индекс **П7077** – рус телендә

«ТАТАРСТАН»НЫҢ КАРТИНАЛАР ГАЛЕРЕЯСЫ

Александр Иванов. «Йолдыз сугышлары». 2007 ел.

АПРЕЛЬ

ЭЧТӘЛЕК

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

6. Президент маршрутлары. Копенгаген чүп яндыру заводы королева резиденциясеннән күпме ераклыкта урнашкан

12. Гаиләгә ярдәмгә. Балаларны карауга түләүләр буенча яңа кагыйдәләр

14. Уфада очрашулар. Татарстан Башкортостанда ничек кунак булды

20. «Балакай, без барыбыз да бераз бахбай…» Фермерлык уңышының сере нәрсәдә

22. Уку һәм укыту теләге. Роботлар кемне алыштыра алмый

24. Күктәге песнәк – кулдагы торна. Казан галимнәре чит ил орнитологларын ничек гаҗәпләндерде

28. Олы Елга. XIX гасыр мәчетен ничек реставрацияләделәр

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

32. Равил Шәймәрданов: «Кешеләрне яратмасаң, табиб булып йөрмә…»

36. Кече шәһәрләрне яшәртү рецепты. Ни өчен роллга соусны Татарстан майонезыннан ясыйлар

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

44. Тарих сәхифәләре. Казан тәхетендә Касыйм ханнары

48. Тукайның билгесез хаты? Затлы мирас кайда саклана

52. Гасыр портретлары. Галәм кешесе туган Татарстаны өчен нәрсә эшләгән

56. Шәриф Хөсәенов. Тормышның ике магистрале

84. Татар авыллары. Кыюлар бикләнеп яшәми

Тулырак мәгълүмат түбәндәге сайтта:
www.protatarstan.ru

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

23. 03

Рөстәм Миңнеханов, Татарстан Президенты, – Уфада Башкортостан Республикасы оешуга 100 ел тулуга багышланган тантаналы чарада журналистлар белән аралашканда:

– Башкортостан һәм Татарстан – сәнәгать потенциалы буенча Россиянең иң көчле төбәкләре унлыгына керә. Без беркайчан да көндәшләр булмадык һәм булмабыз да. Башкортостан – безгә иң якын республика. Безнең товар әйләнеше дәрәҗәсенә күз салу да җитә: берничә юнәлештә, шул исәптән нефть химиясе өлкәсендә дә, үзара бәйләнештә һәм бер-беребезне тулыландырып торабыз.

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

1.04

Александр Шадриков, Татарстанның экология һәм табигать ресурслары министры, – санитар-экология ике айлыгына старт биргәндә:

– Татарстан халкы ЭкоЯзга елдан-ел активрак кушыла бара. Узган ел 1 200 000 кеше республика территориясен чистартуда катнашты. Мин ышанам, быел да безнең кешеләр битараф калмаслар. Гомуми эшкә һәркем үз өлешен кертсә, әйбәт булыр иде. Ә өлкән кешеләр яшьләргә үрнәк күрсәтә ала. Экология безгә мираска тапшырып калдырылмаган, ул – безнең киләчәк буыннарга тапшырасы байлыгыбыз.

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

2.04

Михаил Пиотровский, Дәүләт Эрмитажының генераль директоры, – Казанда «Алтын Урда һәм Кара диңгез буе. Чыңгыз империясе сабаклары» күргәзмәсе ачылышында:

– Безнең төп бурычыбыз – «хәтер сугышлары»н мәдәният диалогына әйләндерү. Ә «Алтын Урда» – бүгенге Россиядә бу «сугышлар» өчен төп сюжетларның берсе булып тора. Бөтенесе шуны ачыклый: кем – кемне? Ә без фәнни әңгәмә тәкъдим итәбез. Бу күргәзмә – үзе бер тикшерену, китап дияр идем, аны өстән-өстән генә дә, детальләп тә өйрәнергә мөмкин.

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

Копенгаген чүп яндыру заводы королева резиденциясеннән **НИКАДӘР** ераклыкта урнашкан

Татарстан Башкортостанда **НИЧЕК** кунак булды

Роботлар **КЕМНЕ** алыштыра алмый

Казан галимнәре чит ил орнитологларын **НИЧЕК** гаҗәпләндерде

XIX гасыр мәчетен **НИЧЕК** реставрацияилиләр

ЯНӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

2019 елның
II яртыеллыгына
«Татарстан»
журналына язылу
башланды

«Татарстан» журналына ТР буенча язылу индекслары:

П 2381 **татар телендә** 930 сум 00 тиен

П 2378 **рус телендә** 930 сум 00 тиен

«Татарстан» журналына РФ буенча язылу индекслары:

П 7076 **татар телендә**

П 7077 **рус телендә**

Реклама 16+



ПРЕЗИДЕНТ МАРШРУТЛАРЫ БУЕНЧА

Татарстан Президентының эш графигы никадәр тыгыз булуын аңлар өчен, бернинди махсус хронометраж үткәрү таләп ителми. Аның сәфәрләре маршрутына күз салу да җитә. Республика, ил, дөнья буйлап туктаусыз йөри ул. Еш кына Рөстәм Миңнеханов иртән нинди дә булса Европа илендә потенциаль инвесторлар белән сөйләшүләр үткәрергә, көндез Россия башкаласындагы мөһим киңәшмәдә катнашырга өлгерә, берничә сәгатьтән соң исә Әлмәттә нефть тармагы үсеше перспективаларын тикшерә... Һәм көн саен диярлек шундый хәл күзәтелә.

Юлда үткән сәгатьләр һәм чакрымнар, мөһим очрашулар, җитди чыгышлар һәм җаваплы карарлар. ТР Президентының соңгы арадагы эш сәфәрләреннән «Татарстан» аеруча әһәмиятлеләрен сайлап алырга тырышты.

КОПЕНГАГЕН. «АКЫЛЛЫ» ЧЕЛТӘРЛӘР ҺӘМ ХИКМӘТЛЕ «ЦИФРА»

НӘРСӘ:

Татарстан Президенты – Дания корольлегендә

КАЙЧАН:

Копенгаген

КАЙДА:

3 апрель

Рөстәм Миңнеханов, Татарстан Президенты:
– Без Татарстанга Дания бизнесын һәм капиталын җәлеп итәргә тырышабыз, моңа һәрьяклап ярдәм итәргә әзербез. Фикер алышулар вакытында эшлекле даирә вәкилләре хезмәттәшлек өчен яңа юнәлешләр ачарлар, уртак проектлар турында килешүләргә ирешерләр, дип көтәбез.

Владимир Барбин, Россиянең Дания корольлегендә Гадәттән тыш һәм Тулы вәкаләтле вәкиле:
– 2018 елда Россия белән Дания арасындагы товар әйләнеше 5 млрд АКШ долларын тәшкил итте, үсеш – 30%ка якын. Россиягә кертелгән Дания инвестицияләре күләме 1,5 млрд АКШ долларыннан артыкны тәшкил итә.

Ларс Твин, «Данфосс» компаниясе президенты:
– Без Россиядә «Данфосс» компаниясенең цифрага бәйле эшкәртмәләрен гамәлгә ашыру буенча беренче төбәк Татарстан булуын телибез.

Фотолар ТР Президенты сайтыннан алынды

ТУЛЫРАК:

Копенгагенда Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов Россия–Дания мөнәсәбәтләре кысаларында Дания чит илләр эшләре министрының тышкы сәүдә буенча урынбасары Сюзанна Хюлделунд ханым белән Татарстан һәм Дания арасындагы хезмәттәшлекнең перспективалы юнәлешләрен тикшерде, Даниянең авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек Советының җитәкчелеге белән очрашты. Татарстан Президенты шулай ук «Дания–Татарстан» түгәрәк өстәлендә катнашты һәм эшлекле даирә вәкилләре белән сөйләшүләр үткәрде.

Сюзанна Хюлделунд белән очрашуда Президент, аерым алганда, Даниядәге коллегалары белән эшлекле элемтәләргә югары бәя биреп билгеләп үтте: «Без уртак проектларны дәвам итәргә телибез, – диде ул. – Аларның күбесе – гамәлгә ашыру стадиясендә. Моннан тыш, үзара эшчәнлекнең башка юнәлешләрен дә табу мөһим». «Татарстан – Дания» түгәрәк өстәле кысаларында кабул ителгән документларга караганда, үзара файдалы хезмәттәшлекне киңәйтү өчен потенциал чыннан да аз түгел. Рөстәм Миңнеханов катнашында Татарстан Республикасы Хөкүмәте белән «Хальдор Топсе» компаниясе арасында хезмәттәшлекне үстерү турында Килешү; Казан милли-тикшеренү технология университеты белән «Хальдор Топсе» арасында хезмәттәшлек турында Килешү; «Данфосс» компетенция (Казан дәүләт энергетика университеты) үзәген ачу турында Килешү имзаланды.

Хезмәттәшлекне киңәйтү мәсьәләләре «Данфосс» компаниясе җитәкчелеге белән оештырылган очрашуда да тикшерелде. Хәзерге вакытта компания Татарстанның энергетика инфраструктурасын камилләштерү өчен таләп ителгән программа белән тәэмин ителешне эшли, акыллы челтәрләр проектларын тәкъдим итә һәм аларны (аерым алганда, Яр Чаллыда «акыллы җылылык челтәре» проектын) гамәлгә кертү белән шөгыльләнә. ТР Президенты сүзләренә караганда, бүген мондый проектлар транспортлау вакытында челтәрләрдә җылылык күп югала торган шәһәрләр өчен аеруча актуаль.

Рөстәм Миңнеханов шулай ук Копенгагендагы Amager Bakke чүп яндыру заводында булды. Әлеге комплекска чүп эшкәртү заводы, ҖЭҮ һәм түбәдә эшләнгән актив ял итү паркы керә. Amager Bakke елына 560 мең тонна чүп калдыгын эшкәртүгә исәпләнгән. Дания королевасы резиденциясенең чүп эш яндыру заводыннан бары тик ике генә километр ераклыкта урнашу факты кызыклы.

БЕЛЕШМӘ:

Татарстанда Даниянең ресурсларны һәм энергияне саклау өлкәсенә караган тәҗрибәсе, яңа технологияләре кулланыла, бу, беренче чиратта, «Данфосс» компаниясе җиһазларына карый. ТР нефть-газ химиясе комплексы предприятиеләре һәм вузлары «Хальдор Топсе» компаниясе белән хезмәттәшлек итә. «Роквул» компаниясенең «Алабуга» МИЗнда 2012 елда ачылган предприятиесе Татарстан – Дания хезмәттәшлегенең мөһим юнәлеше булып тора. Әлеге җитештерү янмый торган материаллар чыгару буенча Европада иң эре заводлардан санала.

НИДЕРЛАНДЛАР КОРОЛЬЛЕГЕ. ИННОВАЦИЯЛӘР ЯКТЫЛЫГЫНДА

НӘРСӘ:

Татарстан Президентының Нидерландлар корольлегенә эш сәфәре

КАЙДА:

Хелмонд, Бест (Төньяк Эйндховен)

КАЙЧАН:

2 апрель

Рөстәм Миңнеханов, Татарстан Президенты:

– Хезмәттәшлекне үстерүнең яңа юлларын эзләргә кирәк, беренче чиратта, инновацияләр өлкәсендә. Инновацияләргә һәм яңа технологияләргә зур игътибар күрсәтәбез. Без Голландия компанияләренең Россиядә старт алу мәйданчыгы буларак безнең республиканы сайлауларына омтылырга тиеш.

Фотолар ТР Президенты сайтыннан алынды (Эдуард Хәйруллин)

ТУЛЫРАК:

ТР Президенты Рөстәм Миңнехановның Нидерландларның Климат өлкәсендә сәясәт һәм икътисад министрлыгы генераль секретаре Маартен Кампс белән очрашуы эш сәфәре барышында төп пунктларның берсе булды. Кампс әфәнде билгеләп үткәнчә, Россиянең икътисадый яктан алга киткән төбәге буларак Татарстанны Нидерландлар белән ныклы эшлекле элемтәләр бәйли. Аның сүзләренә караганда, мәнфәгатьләр охшаш һәм элемтәләрне ныгыту нокталары буларак авыл хуҗалыгы, мәгълүмати технологияләр, сәламәтлек саклау, транспорт кебек тармакларны атарга була. Үзара файдалы багланышларны киңәйтү мәсьәләсе шулай ук Нидерландларның эшлекле даирә вәкилләре белән үткәрелгән түгәрәк өстәлнең төп темасына әверелде. Татарстан Президенты басым ясаганча, төбәкләр арасындагы хезмәттәшлек бүгенге көндә мөнәсәбәтләрне алга этәрүче булып тора.

Сәфәр барышында Рөстәм Миңнеханов Төньяк Эйндховенда урнашкан Philips Инновация үзәгендә булды. Компания онкология авырулары өлкәсендәге тикшеренүләргә зур игътибар бирә. Татарстанның Philips компаниясе белән хезмәттәшлек итү тәҗрибәсе бар, дип билгеләп үтте ТР Президенты. Әлеге багланышларга сәламәтлек саклау өлкәсенә караган яңа проектлар булдыру көчле импульс бирергә мөмкин. Уртак проектларны тиз арада җентекләп эшләү өчен эшче төркем төзергә кирәк, дигән фикергә килделәр.

High Tech Campus югары технологияләр кампусында Татарстан Президенты челтәрле яктылык-диодлы яктырту буенча карарлар кабул итү, системалар эшләү һәм хезмәтләр күрсәтү сферасында дөнья күләмендә лидер булган Signify компаниясе эшчәнлеге белән танышты. Рөстәм Миңнехановка Казанның бердәм яктылык мохите концепциясен тәкъдир иттеләр. ТР башкаласы биналарын һәм иң кызыклы объектларын, шәһәрнең тарихи өлешендәге урамнарны, Ирек мәйданын һәм башкаларны бердәм яктыртылу системасы берләштерә ала, бу очракта яктыртуга чыгымнар шактыйга кимергә тиеш, дип саныйлар проектны эшләүчеләр. Рөстәм Миңнеханов фикеренчә, проект игътибарга лаек, бигрәк тә ТАССР төзелүнең 100 еллыгын бәйрәм итүгә әзерлек кысаларында. Ләкин проектның бәясен санап чыгарырга, бәя һәм сыйфат нисбәтен карарга, эксплуатацияләүгә китәчәк чыгымнарны исәпкә алырга кирәк.

Хелмондта Татарстан Президентына юл хәрәкәте белән идарә итү буенча биш үзәктән берсенең эшен күрсәттеләр. Презентация барышында хәбәр ителгәнчә, илнең юлларында берничә мең камера урнаштырылган, алардан алынган мәгълүмат даими рәвештә төбәк үзәкләренә килеп тора. Ул тиз арада юл-транспорт вакыйгалары булган урыннарга барып җитәргә, автомобильләр агымын көйләргә, шулай ук агымның тизлеген чикләргә мөмкинлек тудыра.

БЕЛЕШМӘ:

2018 ел йомгаклары буенча, Татарстан һәм Нидерландлар арасында товар әйләнеше, өчтән бер өлешкә артып, 2,8 млрд долларга якынны тәшкил итте. Татарстан һәм Голландия компанияләре нефть табу һәм нефть химиясе сферасында хезмәттәшлек итәләр. «Филипс» компаниясе белән сәламәтлек саклау, инфраструктура объектларын яктылык белән тәэмин итү, электротехника тармаклары буенча хезмәттәшлек алып барыла. Моннан тыш, голланд агросәнәгать җиһазлары һәм технологияләре Татарстан авыл хуҗалыгында да киң кулланыла. Яр Чаллы шәһәрендә DSM компаниясенең терлекчелек өчен югары сыйфатлы премикслар җитештерү заводы эшли.

ДУБАЙ.
КИЛӘЧӘКНЕҢ ДӨНЬЯ ИКЪТИСАДЫНА ТАБА

НӘРСӘ:

Дубайда IX Еллык инвестиция форумы (Annual Investment Meeting 2019)

КАЙДА:

Берләшкән Гарәп Әмирлекләре

КАЙЧАН:

8 апрель

Фотолар ТР Президенты сайтыннан алынды (Марсель Бадыйкшин)

ТУЛЫРАК:

«Булачак турыдан-туры чит ил инвестицияләренең чагылышы: цифралы глобальләшү аша дөнья икътисадын баету» – быел Дубай форумының төп темасы әнә шулай яңгырый. Татарстан Президенты форумның тантаналы ачылышында катнашты һәм Россия Федерациясе вәкиле сыйфатында пленар утырышта чыгыш ясады. Утырыш модераторы Корнелия Мейерның (энергетика өлкәсендәге эксперт, MRL Corporation компаниясе генераль директоры һәм рәисе – ред. иск.) дүртенче сәнәгать революциясенең ТР икътисадына йогынтысы турындагы соравына җавап биреп, Рөстәм Миңнеханов, тулаем алганда, Россия Федерациясе өчен цифралы трансформация һәм инновацияле үзгәртеп корулар үсешнең өстенлекле юнәлешләренең берсе булып тора, дип билгеләп үтте. Әлеге аспектта Татарстан Республикасында цифралы икътисадны үстерүне тәэмин итү яңа бурыч булып тора, республикада икътисадый яктан актив һәр гражданин цифралы грамоталылыкка ия, ә дәүләт һәм бизнес югары цифралы компетентлыкны үзләштереп, аны үзләренең эшчәнлекләрендә кулланалар. Цифралы трансформация икътисадый эшчәнлекнең барлык тармакларын, шул исәптән сәнәгатьне һәм җитештерүне үзгәртеп корырга тиеш. Татарстан, дип билгеләп үтте ТР Президенты, Россия күләмендә барлык юнәлешләрдә дә һәрвакыт лидер булырга һәм дөнья дәрәҗәсендә танылырга омтыла. IX Еллык инвестиция форумы барышында Рөстәм Миңнеханов Берләшкән Гарәп Әмирлекләренең рәсми хакимияте һәм эре бизнесы вәкилләре, һәм шулай ук башка илләрдән килгән катнашучылар белән кайбер очрашуларны үткәрде. Татарстан Президентының БГӘнең инфраструктурасын үстерү министры Абдулла бин Мөхәммәд Бинхаиф Әл-Нуайми белән кыска гына әңгәмәсе оештырылды. Рөстәм Миңнеханов шулай ук Дубай әмирлекләрендә хакимлек итүче гаилә әгъзасы – инфраструктураны, энергетика проектларын үстерү һәм чимал товарларын сату белән шөгыльләнүче компанияләр төркеме хуҗасы шәех Әхмәд бин Дальмук Әл-Мактум белән очрашты. Компанияләр Азия һәм Африка илләрендә актив инвестицияле эшчәнлек алып баралар, Россия төбәкләре икътисадына да инвестицияләр кертү мөмкинлеген карыйлар. Татарстан Президентының Zamil Group Holding Company халыкара инвестицияле компаниясе (Согуд Гарәбстаны корольлеге) һәм сәламәтлек саклау һәм медицина белеме өлкәсендә Amanat Holdings инвестицияле компаниясе (БГӘ) җитәкчелеге белән әңгәмәләре эчтәлекле һәм файдалы узды.

БГӘнең эшлекле даирәләре Россиянең һәм Ислам хезмәттәшлеге оешмасының «KazanSummit» Халыкара икътисадый саммитында актив катнашалар. Агымдагы елның 24–26 апрель көннәрендә Әмирлекләрнең вәкиллекле делегациясе, чираттагы саммитта катнашыр өчен, Казанга килер, дип көтелә.

БЕЛЕШМӘ:

2018 ел йомгаклары буенча, Татарстан Республикасы белән БГӘ арасында тышкы сәүдә әйләнешенең күләме 34 млн АКШ долларыннан артып китте. Шул исәптән экспорт 23 млн АКШ долларына якынны тәшкил итте, импорт – 11 млн АКШ долларыннан артыкны. Татарстан Республикасы «КАМАЗ» ГАҖ, «Казан вертолет заводы» ГАҖ, «КМҖБ» АҖ, «Казан Компрессормаш» ААҖ, «Түбән Кама Нефтехим» ГАҖ продукциясен, «А.М.Горький ис. Яшел Үзән заводы» АҖ җитештерә торган титан кою җитештерүен һәм нефть-газ табу җайланмаларын экспортка чыгарырга, һәм шулай ук ислам банкингы өлкәсендә хезмәттәшлекне үстерергә, ТРнда уртак инвестицияле проектларны гамәлгә ашырырга тели.

ГАИЛӘГӘ ЯРДӘМ БУЛСЫН ӨЧЕН

Владимир Путин үзенең Федераль Җыенга Юлламасын демографик сәясәттән башлады, аерым алганда, гаиләләргә ярдәм чараларын туплаган яңа пакет турында сөйләүдән. Без Татарстан экспертларыннан әлеге пунктларны шәрехләүләрен үтендек.

БЕРЕНЧЕ БАЛА БЕЛӘН ИКЕНЧЕ БАЛА ТУУЫНА БӘЙЛЕ ТҮЛӘҮЛӘРНЕҢ ЯҢА КАГЫЙДӘЛӘРЕ

Владимир Путин, РФ Президенты:

«Бала туу һәм аны тәрбияләп үстерү гаиләне фәкыйрьлек чигенә китереп җиткермәскә тиеш, ягъни аның яшәү дәрәҗәсенә зур йогынты ясамаска. Сез инде беренче һәм икенче яшь ярымга кадәрге балалар өчен түләүләр каралган икәнлеген беләсез. Беренче балага түләүләр федераль бюджеттан керә. Икенче балага түләүне гаилә ана капиталында каралган акчалардан алырга хокуклы. Түләү бәясе федерациянең аерым бер төбәгендәге балага каралган яшәү минимумы дәрәҗәсеннән тора. Ил буйлап исәпләп чыгарганда, уртача бер балага аена 11 меңнән артыграк була. Хәзер мондый түләүләрне керем дәрәҗәсе кеше исәбенә бер ярым яшәү минимумыннан артмаган гаиләләр ала. Инде чираттагы адымны ясарга вакыт. 2020 елның 1 гыйнварыннан гаилә әгъзасына булган яшәү минимумы планкасын икегә кадәр күтәрергә тәкъдим итәм. Бу өстәмә түләүләргә хокуклы гаиләләр санын да бер ярым мәртәбәгә арттырырга ярдәм итәчәк. Дәүләт ярдәмен беренче һәм икенче балалары дөньяга килгән 70 процент гаилә куллана алачак, дигән сүз».

Чулпан Илдарханова, социология фәннәре докторы, ТР ФАнең Гаилә һәм демография үзәге директоры:

– Балалары булган гаиләләргә дәүләт ярдәменең нәтиҗәлелеге ни дәрәҗәдә икәнлеген тикшерер өчен, безнең Үзәк туу буенча объектив күрсәткечләрне әлеге чаралар кертелгән чордан башлап күзәтте, ягъни 2007 елдан. Шулай ук бу чорда бала алып кайткан хатын-кызлар биргән субъектив бәягә дә тукталды. Анализ күрсәткәнчә, югарыда искә алынган сәясәт буенча, туучылар санының үсеше 17 мең кешене тәшкил иткән. 2007–2017 елларда («Ана капиталы» программасы кертелгәч) демографик сәясәтнең туучылар исәбе күрсәткечләренә керткән өлеше 90 процентны тәшкил итә, ягъни әлеге программа булмаган очракта 90 процент гаиләләрдә икенче, өченче бала тумаган булыр иде.

Татарстанда туучылар санын арттыру чараларының йогынты колачы Россиядәгедән артыграк. Бу төбәк программалары белән бергә, региондагы уңай социаль-икътисадый шартлар белән дә бәйле булырга мөмкин.

2018 елда, Муниципаль берәмлекләр ассоциациясе ярдәме белән бергә, безнең Үзәк «Татарстан Республикасында замана хатын-кызының репродуктив-ана булу стратегияләре структурасындагы эш белән мәшгульлеге» дип исемләнгән социаль-демографик тикшеренү уздырды. Бу тикшеренүдә республиканың 3 агломерациясеннән репродуктив яшьтәге 2,3 мең хатын-кыз катнашты. Нәтиҗәләр түбәндәгечә булды. Әгәр без баланың тууы турында аның гаиләдә ничәнче булуына бәйсез рәвештә сүз йөртәбез икән, 2007–2017 елларда бала алып кайткан һәм сораштыру узган хатыннарның 26 проценты аны дәүләт ярдәме булганга гына табулары турында әйтте. 31 проценты ана капиталы кертелгәнчегә кадәр, ягъни планлаштырган сроктан алдарак бәби алып кайткан. Күп балалы гаиләләргә җир участогы бирелү дә гаиләләрне өченче бала алып кайтырга дәртләндергән. Владимир Путинның Федераль Җыенга тәкъдим иткән һәм алга таба күздә тоткан яңа чаралары туу календарен яңартырга мөмкин, дип фаразлый алабыз. Ягъни соңрак бала алып кайтырга уйлап торган хатын-кызлар иртәрәк – якын арада ук көмәнгә узарга ниятләргә бик мөмкиннәр.

Хәзер: гаиләнең бер әгъзасы исәбеннән яшәү минимумы **1,5тән** **узмаган керемле** гаиләләргә өстәмә түләүләр каралган

2020 елның 1 гыйнварыннан: гаиләнең бер әгъзасы исәбеннән яшәү минимумы **2не** **тәшкил иткән керемле** гаиләләр өстәмә түләүләр алырга хокуклы булачак.

2007–2018 елларда хатын-кызларның бала табу карарына демографик сәясәт чараларының йогынтысы*



ИНВАЛИД БАЛАЛАРНЫ КАРАУ ӨЧЕН ПОСОБИЕНЕҢ КҮЛӘМЕН АРТТЫРУ

Владимир Путин, РФ Президенты:

«Бүген инвалид балаларны һәм кечкенәдән беренче төркем инвалидларны карау өчен пособиенең күләме 5,5 мең сумны тәшкил итә. Алдагы елның 1 июленнән бу сумманы 10 меңгә кадәр арттырырга тәкъдим итәм. Әлбәттә, бу зур сумма түгел, шулай да гаилә өчен өстәмә ярдәм була ала. Андый гаиләләрдә бала бит аерым тәрбиягә мохтаҗ. Кайбер исәпләр буенча, бу үзгәрешләр 460 мең кешегә кагылачак».

Ольга Тимуца, «Ретт синдромы белән авыручыларга ярдәм күрсәтү ассоциациясе» Автоном коммерциячел булмаган оешмасы директоры:

– Пособие күләме арту – бу һичшиксез яхшы күрсәткеч, чөнки эшләмичә авыру баланы карарга мәҗбүр булган кеше өчен 5,5 мең сум – бөтенләй юк диярлек сумма. 10 меңгә кадәр арттыру да – әллә ни зур сумма түгел, әмма, ничек кенә булмасын, кешеләрнең яшәү шартларын яхшырту, дигән сүз. Шуның белән беррәттән, искә төшерәсем килә: узган ел инвалид балалары булган әти-әниләр бер-бер артлы митинглар оештырды. Алар пособие күләмен 15 меңгә кадәр арттыруны таләп итте, болай иткәндә, ул әле күпмедер дәрәҗәдә аларның хезмәтен каплый, диделәр. Чынлап та, каты авыру баланы һәм олы яшьтәге инвалидны карау – ул искиткеч авыр хезмәт. Әлбәттә, безнең авыру балалар һәм өлкән яшьтәге зәгыйфь гаилә әгъзаларыбыз – ул шәхси җаваплылыкны таләп итә торган затлар. Кешеләр үзләренең авыру туганнарын карый икән – бу нормаль күренеш. Әмма дәүләт тә аларның бу авыр йөген җиңеләйтер өчен нидер эшләргә тиеш. Бу мәсьәләдә тагын бер аспект бар: эшләмәгән ата-ана пособие алырга хокуклы, ә менә эшли торганы, салым түләүчесе – инде юк. Әгәр ата-ана эшли икән, авыру бала белән кем утырырга тиеш? Димәк, ул эш хакының зур бер өлешен үзе эштә чакта баланы карап утырган кемгәдер кайтарып бирәчәк, дигән сүз. Мондый шартларда юньләп яшәргә берничди мөмкинлек калмый. Мин менә нәрсә тәкъдим итәр идем: без инде бик күптәннән авыру балалар өчен караучы, ярдәмче кирәклеге турында сүз алып барабыз. Андый караучылар, ярдәмчеләр бигрәк тә бала балигълык чорына кергән гаиләләр өчен зарур, чөнки 18 яшьтән соң социаль ярдәм күрсәтү кузгә күренеп кими. Әмма проблемалар кимеми ләбаса, арта гына – олы яшьтәге инвалидны карау бик катлаулы. Еш кына бу ситуациягә элеккән аналар үзләре дә сәламәтлеге какшаудан җәфалана. Аның табибка барып күренергә дә хәленнән килми, ул инвалид баласының колына әверелә, дисәк тә арттыру булмас. Ә менә караучы һәм ярдәмче кебек социаль хезмәт күрсәтүче табылса, аның хәле икеләтә җиңеләер иде.

Хәзер: инвалид балаларны һәм кечкенәдән беренче төркем инвалидларны карау өчен пособие –

5 500 сум

2019 елның 1 июленнән: инвалид балаларны һәм кечкенәдән беренче төркем инвалидларны карау өчен пособие –

10 000 сум

* Чыганак – ТР ФАнең Гаилә һәм демография үзәгенең «Татарстан Республикасы замана хатын-кызларының репродуктив-ана булу стратегиясе структурасында эш белән мәшгульлеге» иҗтимагый-демографик тикшеренүе нәтиҗәләре.

PRESSA

ТАТАРСТАН – БАШКОРТОСТАН: ХАЛЫКЛАР ДУСЛЫГЫ ТАРИХЫ

Автор:
Алёна Кутыркина

17 һәм 18 апрель көннәре Уфада ике тугандаш республиканың «Бергә без яхшырак булдырабыз!» дигән яңа шигаре белән үтте. Бу көннәрдә ике дистәдән артык мәдәни, спорт һәм бизнес чаралары үткәрелде. Соңгы тапкыр ике республика арасында мондый якын мөнәсәбәтләр күзәтелгәненә 30 елдан артык вакыт узган иде, шуңа күрә очрашуда катнашучыларның һәрберсенең чыгышында куәтле эмоциональ күтәренкелек сизелде.

Фото: Александр Ефремов

Бу көннәрнең иң тәэсирле һәм матур вакыйгасы Татарстан Республикасы сәнгать осталары концерты булды. Маппинг-тамашаның якты утлары, декорацияләр алышынган саен, залда соклану хисләре уятты, һәр чыгыш тамашачыда көчле тәэсирләр кузгатты. Гаҗәеп декорацияләр һәм актерлык таланты белән үрелгән тамаша аша кунаклар Халыклар дуслыгы тарихы белән танышып утырды.

Шул ук кичне күренекле мәдәният эшлеклеләрен бүләкләделәр, Татарстан һәм Башкортостан җитәкчеләре аларга рәсми рәхмәт кәгазьләре һәм республикаларның мактаулы исемнәрен тапшырды.

Мәсәлән, танылган җырчы һәм Татарстан Республикасының атказанган артисты Гүзәл Уразова, шулай ук аның ире һәм хезмәттәше – Башкортостанда туып-үскән Илдар Хәкимов Башкортостан Республикасының атказанган артисты исемен алдылар.

Татарстан Республикасының беренче Президенты Минтимер Шәймиевнең экранда пәйда булган видеомөрәҗәгате зур рухлану уятты. Минтимер Шәймиев ике халык арасындагы мөнәсәбәтләрне үстерү уңаеннан рәхмәт сүзләрен җиткерде.

Гаҗәеп декорацияләр һәм актерлык таланты белән үрелгән тамаша аша кунаклар Халыклар дуслыгы тарихы белән танышып утырды.

Концерт Татарстанның халык артисты Салават Фәтхетдинов башкаруында «Мин яратам» җыры белән тәмамланды. Беренче аккордлардан ук тамашачылар, торып басып, җырчыга кушылып җырлый башлады һәм зал халык мәхәббәтенә күмелгәндәй тоелды.

18 апрель иртәсе «Нур» татар театры каршында Габдулла Тукай һәйкәлен ачу тантанасыннан башланды. Башкортостандагы иҗтимагый оешмалар әлеге проектны тормышка ашырырга инде берничә ел омтылыш ясады, соңыннан бу ният Башкортостан башлыгы хакимиятендә дә хуплау тапты. Башта Уфаның яңа истәлекле урынын бу елның азагына ачарга ниятләгәннәр иде, әмма Башкортостан тарафының матди якны кайгыртуы һәм ике республиканың уртак тырышлыгы нәтиҗәсендә проектны Башкортостанда Татарстан көннәренә – нәкъ шагыйрь туган көне алдыннан тәмамларга мөмкинлек туды.

Тарихи мизгелне – һәйкәлнең япмасын ачу вакыйгасын йөзләгән камера теркәде. Япма ачылгач, сигез метрлы мәһабәт һәйкәл җиһанга күренде. Биек постаментта сурәтләнгән шагыйрьнең бер кулында – каләм, икенче кулы белән ул әлеге тамашага җыелган халыкны театрга чакыра кебек... Җәйгә табарак, бу территорияне яшеллеккә күмеп, ял итү зонасы һәм аллеялар корып, бөтен мәйданны тулысынча үзгәртеп кору планлаштырыла.

Мәдәни чаралардан соң җитәкчеләр, ике республика арасында сәүдә-икътисадый, фәнни-техник, социаль һәм мәдәни хезмәттәшлек турында килешүгә кул кую өчен, Хөкүмәт йортына юнәлде.

Аннары Татарстан делегациясе Конгресс-холлга юл тотты. Эшкуарлык форумы Башкортостанда Татарстан көннәренең иң көтелгән мәйданчыкларыннан берсе булды. Мондый формат ике республиканың эшкуарларын һәм хөкүмәт вәкилләрен бер урында җыеп, тармакара һәм төбәкара эре проектлар хакында фикер алышырга мөмкинлек бирде.

Форумның пленар өлешендә республика башлыклары икътисадый һәм мәдәни хезмәттәшлек турында соңгы тапкыр 2010 елда имзаланган республикаара килешүне яңартты. Үз чиратында министрлыклар һәм төрле эшкуарлык берләшмәләре вәкилләре тармакара килешүләр имзалады. Шуннан соң сигез юнәлеш: сәнәгать, авыл хуҗалыгы, сәламәтлек саклау, мәгариф, кече эшкуарлык, туризм, яшьләр сәясәте һәм архив эше буенча түгәрәк өстәлләр узды.

Әлеге форумның киләсе елда, ТАССР төзелүгә йөз ел тулуны бәйрәм иткән вакытта, Татарстанда Башкортостан көннәре кысаларында дәвам итәчәге хәзер үк билгеле. Ул вакытка программаны бүгенге тәҗрибәне исәпкә алып эшләп бетерү, яхшырту һәм яңа мәйданчыклар өстәү планлаштырыла. Бу максатта, форум узуга ук, үзара килешүләр турында мәгълүмат тупланачак һәм республикалар арасында өч еллык чаралар планы булдырылачак. Эшкуарлар һәм хакимият вәкилләре хәзерләгән мондый «юл картасы» Татарстан белән Башкортостан арасында алга таба хезмәттәшлекне шактый җиңеләйтәчәк.

Рөстәм Миңнеханов,
Татарстан Республикасы Президенты:
– Башкортостанда Татарстан вәкиллеге эшләп килә, һәм без үзебездә сезнең вәкиллекне тизрәк ачу мәсьәләсендә ярдәм итәрбез.

Радий Хәбиров,
Башкортостан Республикасы башлыгы вазыйфаларын вакытлыча башкаручы:
– Хәзер бездә татар һәм башкорт халкы дуслыгының яңа символы бар.

Минтимер Шәймиев,
Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе:
– Татарлар һәм башкортлар – бер-берсенә якын туганнар. Без һәрвакыт бер дөньяда яшәдек һәм яшибез, бер үк җырларны җырлыйбыз, матур Сабантуйлар үткәрәбез. Иң мөһиме – бер-беребезне тылмачсыз аңлыйбыз.

Дамир Фәттахов,
Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министры:
– Җитәкчеләребездән чыккан энергетика һәм хезмәттәшлеккә омтылыш ике республиканың тагын да якынрак интеграциясенә импульс бирә.

Шамил Вәлиев,
Башкортостан Республикасы Иҗтимагый палатасы аппараты җитәкчесе:
– Бу бизнес-форум – реаль вакыт режимында заманча эшләнмәләр белән таныштыру, мәсьәләләрне хәл итүнең нәтиҗәле юлларын күрсәтү, шулай ук охшаш проблемаларны чишкәндә уңышсыз схемалардан саклап калу мөмкинлеге.

Илдар Хәкимов,
Башкортостан Республикасының атказанган артисты:
– Кайда яшәвең мөһим түгел, иң әһәмиятлесе – иҗатыңда үз мәдәниятең һәм телеңнең бер өлешен күтәреп чыгу.

Гүзәл Уразова,
Татарстан Республикасының һәм Башкортостан Республикасының атказанган артисты:
– Татарлар һәм башкортлар– күршеләр генә түгел, ә бердәм халык.

Мәхмүт Фатыйхов,
Уфаның «Нур» дәүләт театры актеры, Башкортостан Республикасының атказанган артисты:
– Бүген безнең хыял тормышка ашты, шатлыгым чиксез, чөнки хәзер һәр көн Тукай үзе, театр ишек төбендә безне каршы алып, татар халкына хезмәт итәргә рухландырачак.

«БАЛАКАЙ, БЕЗ БАРЫБЫЗ **ДА БЕРАЗ БАХБАЙ...»**

Күптән канатлы гыйбарәгә әйләнгән бу сүзләрне моннан 100 ел элек Владимир Маяковский язып калдырган. Бүген дөньяда атларның 430 га якын төре билгеле. Кеше белән бу акыллы хайванны аеруча җылы мөнәсәбәтләр бәйли. Атларга без сабыйларча сокланабыз, сөенәбез, әсәренәбез. Әлеге мөнәсәбәтләрнең кадерен белгән җирләрдә бахбайлар өчен бик шәп шартлар тудырыла, ат үрчетү үзәкләре булдырыла. Россиянең Адыгея, Калмыкия, Кабарда-Балкар төбәкләре, Казахстан, Кыргызстан...
Ихтимал, тиздән безнең республикабыз да әлеге исемлеккә өстәләр. «Татарстан» журналы Татарстанда ат үрчетүчелекне торгызучылар белән танышып кайтты.

Автор:
Алсу Троицкая

КРЕСТЬЯННАР ШӨГЫЛЕ

Айзат Сәлаховның крестьян-фермерлык хуҗалыгы Арча районы Курса Почмак авылы янында урнашкан. Башта ике ат кына асраганнар, хәзер хайваннарның баш саны инде 120 гә җиткән.

Бу шөгыль бары тик бик хуҗалыкчыл һәм хезмәт сөючән, крестьян җанлылар өчен, диләр. Шунлыктан ферма хуҗасы 27 яшьлек Айзат һәм аның ике ярдәмчесе бөтен көнелен биреп эшли – иртәнге сәгать алтыда торып, ашыкмыйча гына араннарны карап чыга, абзар идәнен себерә, улакларга хуш исле печән сала, бияләрне сава...

НУТРИЦИОЛОГИЯ БУЕНЧА ПРАКТИКА

– Ат – бик сак һәм сизгер хайван, – дип аңлата Айзат. – Янына килгәнче, башта аның игътибарын җәлеп итәргә, эндәшергә кирәк. Югыйсә ул курка һәм сөтен бөтенләй бирмәскә мөмкин. Алар болай да сөтне сыерлардан азрак бирә. Бер биядән көненә биш литр чамасы сөт савып алырга мөмкин. Шунлыктан аларны һәр ике сәгать саен савабыз. Бия сөте бик тиз әчи. Бездән аны Казаннан килеп сатып алалар, нигездә кечкенә балалар өчен. Ул төче, шуңа сабыйларга ошый. Әмма иң мөһиме – составы буенча, сыер сөтеннән аермалы буларак, ана сөтенә бик охшаш, җиңел үзләштерелә һәм аллергия китереп чыгармый диярлек.

– Аграр уку йортының икътисад факультетын тәмамлаучы белгеч нутрициология буенча ничек шулай күп белә? – дип кызыксынабыз.

– Тәҗрибә! Гомумән, авыл хуҗалыгы тармагындагы эшчәнлек һәрвакыт хәвефкә корылган һәм махсус белемнәр таләп итә. Бигрәк тә соңгы берничә дистә елда җитештерүгә кагылышлы күп кенә позицияләр юкка чыккан икән ат үрчетүдә. Бу нисбәттән иң нәтиҗәлесе – коллегалар белән аралашу. Без Казан ипподромы, күрше республикалар, Рязань өлкәсендәге Дивовода урнашкан Бөтенроссия ат үрчетү фәннитикшеренү институты белгечләре белән һәрвакыт элемтәдә торабыз.

Яңа савылган бия сөтеннән нигездә кымыз җитештерәбез. Җәен без инде көн саен 500 шәр шешә кымыз ясарга сәләтле. Әмма икенче сорау туа: аны кайда сатарга? Безнең Татарстанда әлеге эчемлекне яратып кулланучылар күп түгел шул әле, – дип елмая хуҗа һәм безне казылык цехы янәшәсендәге кымыз цехына алып керә. – Мактанмыйча әйтә алам, безнең кымыз – иң яхшылардан берсе. Чиста азык, яхшы тәрбия, тәмле печән һәм солы – кымызның сыйфаты турыдан-туры менә шуларга бәйле. Атлар азыкка һәм суга бик таләпчән. Минем әллә ничә тапкыр күргәнем бар – җәйге кич һәм төннәрдә малкайларны урман буенда көткәндә атлар ниндидер махсус үләннәрне табып сыйлана...

КАТГЫЙ РЕЖИМ КИРӘК

– Мин атларның нинди дә булса бер токымын башкаларыннан артыграк яратам, дип әйтә алмыйм. Әмма биредә минем бурычым – авыр йөк ташучы совет атларының нәсел үзеген формалаштыру. Хуҗалыкта без нигездә шуларга таянабыз. Һәм алар сөтне дә күбрәк бирә, – дип дәвам итә Айзат, безгә үзенең тулпарларын күрсәтеп. – Безнең бөтен ат һәм айгырларыбызның кушаматы бар. Һәркайсының – үз холкы. Һәркайсына махсус игътибар кирәк. Менә Вектор, иң үрчемле айгыр. Әнә тегесе Капитан кушаматлы. Алар хәзер урамда йөри, барысын да, чиратлап, көненә 2–3 сәгать саф һавада йөртәбез. Атларга катгый режим таләп ителә – ашату да, эчертү дә, урамда йөртү дә нәкъ вакытында булырга тиеш...

САБЫЙЛАРНЫ ДА, ӨЛКӘННӘРНЕ ДӘ ДӘВАЛЫЙЛАР

Айзат йөгәненнән тотып сыртында буе ике метрга якын булган, аяклары куе озын йон белән

Фото: Александр Ефремов



капланган кара айгырны алып чыга:

– Ә бу безнең – Магмум. Англиядә чыгарылган шайр токымлы нәселле айгыр. Без аны Германиядән алып кайттык. Курыкмагыз. Шайрлар Олимпия чемпионнарында гына булырдай тыныялык һәм сабыр холыклары белән аерылып тора. Безнең илдә аларны җирле токымнарны яхшырту өчен файдаланганнар. Авыр йөк ташучы Владимир токымлы байталларда да аларның каны ага. Алар чынлап та бик сабыр, балаларны яраталар. Якын арада без аларның бу үзенчәлеген тагын бер файдалы эштә куллана башларбыз кебек. Фермада «атлар белән дәвалау» – иппотерапия уникаль методикасын кертүне планлаштырабыз. Атлар янәшәсендә булуның файдасын үзебездән чыгып яхшы беләбез. Тулпар янында бераз утырып торсаң, начар кәеф тә, ару-талу да юкка чыга. Атлар – безне, без исә аларны аңлыйбыз.

АВЫР ЙӨК ТАШУЧЫ СОВЕТ АТЫ

– Без әле тагын авыл туризмын җәелдерергә дә ниятлибез. Биредә моның өчен табигатьнең матур почмаклары: елга, урман, чишмә, балыклы буа, дисеңме – бөтен нәрсә бар... Гомумән алганда, тормышка ашырып булырдай проектлар күп. Әмма бүгенгә иң мөһиме – кымыз һәм ит продукциясе белән ферманың товарлыклы өлешен үстереп, нәсел үзәген формалаштыру. Аннары исә «авыр йөк ташучы совет аты» токымлы бахбайлар үрчетү заводы ачып булачак. Чөнки көндәшлеккә сәләтле атларга ихтыяҗ Россия базарында да, халыкара базарда да арта гына бара. Бу исә бездән нәселле атлар үрчетү эшенә бик җаваплы карауны таләп итә. Шуңа тырышабыз да...

Матур урын, матур эш, матур хайваннар...

Айзат Сәлахов Магмум кушаматлы айгыр белән.

ХАЙВАННАР ТОРМЫШЫННАН: ИРИСКА ХИКМӘТЛӘРЕ

Берничә тапкыр барлык атлар да ниндидер могҗиза буенча абзардан ирекә чыгарылган. Хуҗалар моңа бик аптыраган. Ириска кушаматлы пони «җинаять урынында тотылгач кына», аның араннарны һәм абзар ишекләрен ачып, зур агайларын ирекә чыгаруы ачыкланган. Бу сөйкемле мини-атлар акыллы гына түгел, хәйләкәр һәм шук та икән...

АНА КАЙГЫСЫ

Бервакыт яңа туган тай үлгән. Әнисе, бер минутка да китмичә, янында басып торган. Тынычланырга вакыт биреп, хуҗалар аны борчымаган. Тайны алып киткәч үк, ат гөрселдәп җиргә ауган һәм җан биргән. Ана йөрәге кайгыга чыдамаган. Менә шундыйлар алар, тулпарлар...

Остадан СОРАГЫЗ!

Августта Казанда кабат дөньякүләм ярыш – WorldSkills-2019 чемпионаты үтәчәк. Анда 60 тан артык илдән иң оста яшь профессионаллар катнашачак. Балта осталары һәм чәчтарашлар, флористлар һәм икмәк пешерүчеләр, электроникачылар һәм токарьлар – барлыгы 56 компетенция тәкъдим ителәчәк. «Татарстан» журналы республикабызның үз осталыгы белән дөньяны таң калдырырга җыенучы яшьләре турында сөйләвен дәвам итә.

УКУ ТЕЛӘГЕ
ҺӘМ УКЫТУ СӘЛӘТЕ

Марина Сангинова – Казан педагогика көллиятенең 4 нче курс студенты. Ул WorldSkills милли чемпионатында «Башлангыч сыйныф укытучысы» компетенциясендә катнашырга җыена.

1. Сез ни өчен бу һөнәрне сайладыгыз?

Минем әнием укытучы булып эшли, шуңа балачагым гел мәктәптә үтте диярлек. Еш кына укытучы булып уйный, билгеләр куя идем. Миңа балаларны укыту процессы бик ошап китте. Үземнең беренче укытучымны да бик яратып искә алам. Нәрсәдер килеп чыкмаса, ул һәрвакыт ярдәмгә килә иде. Бервакыт, нәрсәгәдер күңелем төшкәндә, ул минем көндәлегемә илһамландыргыч цитата язып куйды: «Үзең турында начар уйларга ярамый, барысы да уйлаганча барып чыкмаса да, барыбер алга барырга кирәк», – дип. Минем өчен беренче укытучы – һәрвакыт ярдәмгә килергә әзер кеше, үзем дә шундый булырга телим.

2. Үткән WorldSkills ярышларында нинди кыенлыкларны җиңәргә туры килде?

Кыенлыклар стресс белән бәйле, чөнки модульләрне әзерләгән вакытта янәшәдә тавыш, ыгызыгы, шунлыктан фикерне тупларга өйрәнү зарур. Вакыт та аз, өч сәгать эчендә бик күп төрле бирем әзерләп өлгерергә кирәк. Биремнәрне үтәгән чакта без социаль челтәрләрдән файдалана, дәрес конспектларын куллана алмыйбыз – моның өчен шунда ук дисквалификация көтә. Милли чемпионатта минем дисциплина буенча Татарстан инде 4 ел рәттән беренче урыннарны яулый, шунлыктан экспертларның игътибары аеруча көчле, алар безгә башкаларга караганда таләпчәнрәк карый.

3. Эшче һөнәрләр чемпионатында катнашу сезгә нәрсә бирә?

WorldSkills хәрәкәтенә мин үз көчемне сынар, яшьтәшләрем белән ярышыр өчен кушылдым. Бу – үз һөнәреңдә күнекмәләрне камилләштерү мөмкинлеге, уңыш баскычы. Заман белән бергә атлыйсым килә, киләчәктә мин укытачак балалар янәшәләрендә чын һөнәрмәнд булуын сизсен иде, дип телим. WorldSkills безгә бары тик әзер белемне тапшыручы булып калу гына түгел, ә бәлки балага тәкъдим ителгән хәлдән чыгу юлларын табарга булышырлык проблемалы укытуда төрле технологияләрне файдалану мөмкинлеген дә бирә.

4. Булачак ярышларга ничек әзерләнәсез? Халыкара WorldSkills стандартлары безнең мәгариф таләпләреннән аерыламы?

3 нче курста укыганда, төбәк чемпионатында волонтер булып катнашканда ук, көллиятнең укыту программасы һәм WorldSkills программасының икесе ике төрле нәрсә булуын аңладым. Көллияттә безне нигездә теориягә өйрәтәләр, чемпионатта исә биремнәр спектры күпкә киңрәк һәм гамәли күнекмәләргә юнәлтелгән. Бүген мин көн саен 9 дан 12 гә кадәр шөгыльләнәм, кайчагында, мавыгып китеп, кичкә кадәр дә утыра алам.

5. Киләчәктән ни өмет итәсез? Якын арада эшче һөнәрләргә алмашка роботлар килмәсме?

Минемчә, укытучыны робот алыштыра алмый. Мөгаллим укучыга гомуми, база белеме биреп кенә калмыйча, аның әхлак сыйфатларын да тәрбияләргә тиеш. Бу исә машинаның хәленнән килми. Әйе, ул әзер белем бирергә һәм тестларны тикшерергә сәләтле. Әмма хәзер мәгариф системасы үзгәрә, укучылар белемне үзләре эсти. Укытучы аларга булыша һәм дөрес юнәлеш бирә, бу исә биремнәрне тикшерүгә караганда күпкә җаваплырак бурыч.

6. Һөнәрне үзләштерү өчен нинди күнекмәләргә һәм шәхси сыйфатларга ия булу зарур?

Укытучы балаларны яратырга, үз белемен алар белән уртаклашырга омтылырга тиеш. Мөгаллим максатчан, җаваплы булырга, барлык адымнарын һәм аларның нинди нәтиҗәгә китерәсен алдан уйларга тиеш. Без киләчәк буынны үстерәчәкбез, шунлыктан безгә балаларны үзебез теләгәнчә тәрбияләргә кирәк. Алар барысын да сеңдереп бара, шунлыктан лаеклы үрнәк күрсәтү бик тә мөһим.

7. Ун елдан соң үзегезне кем итеп күзаллыйсыз?

Әлегә мин, көллияттә калыргамы, әллә мәктәпкә китәргәме, дип икеләнәм.

Көллияттәге ресурслар үзәге базасында үз күнекмәләреңне үстерү өчен мөмкинлекләр һәм яңа җиһазлар бик күп. Кайбер мәктәпләрдә мондый җиһазландыру булмаска да мөмкин, әмма чын укытучы дәфтәр һәм каләм белән генә дә яхшы укытырга сәләтле.

Бүгенге әзерлегемә нигезләнеп, ышанып әйтә алам: ун елдан соң мин инде берничә сыйныфны укытып чыгарган уңышлы укытучы булачакмын. Балалар мине һәрвакыт яхшы яктан гына искә алачак, мин исә алар хакына тагын да тырышыбрак хезмәт куячакмын. ■

Автор:
Алёна Кутыркина

Фото: Алёна Кутыркина

ПЛОСКИЕ ГЕОМЕТРИЧЕСКИЕ ФИГУРЫ
ИЗУЧАЕМ РУССКИЙ ЯЗЫК
ПРОГРАММА
МЕТОДИЧЕСКИЕ РЕКОМЕНДАЦИИ
ДИАГНОСТИКА

КҮКТӘГЕ ПЕСНӘКЛӘР – КУЛДАГЫ ТОРНА!

Дистәләрчә ел берөзлексез кошларны күзәтү Казан тикшеренүчеләренә чит ил галимнәрен гаҗәпләндерерлек нәтиҗәләр ясарга мөмкинлек биргән булып чыкты.

Автор:
Ольга Туманская

Март аенда Япония Экология җәмгыятенең Кобэ шәһәрендә үткән еллык конференциясендә күренекле фәнни тикшеренүләр өчен премияләр тапшырылды. Барлыгы алты бүләкнең берсе Казан галимнәре Олег, Игорь һәм Артур Аськеевларга бирелде. Фән дөньясында Япониянең Ecological Research Paper Award премиясе иң абруйлылардан санала, һәм аңа лаек булган Россия галимнәре күп түгел.

Япон җәмгыяте күренекле дип тапкан мәкалә бөтенләй көтелмәгән нәтиҗәләр турында хәбәр итә. Климат үзгәрүе бөтен җирдә дә төрләрнең азаюына һәм биологик төрлелекнең кимүенә китерми икән бит. Җирнең кайбер почмакларында, глобаль җылыну нәтиҗәсендә, урманда яшәүче кайбер җан ияләренең саны әкренләп арта. Татарстан да шундый урыннарның берсе икән.

ПЕСНӘКНЕ КОЙРЫГЫННАН ЭЛӘКТЕРҮ

Озын койрыклы ап-ак йөнтәс йомшак шарчык. Бу – Татарстан урманнарында яшәүче озын койрыклы песнәк (ополовник). Кошчык чыпчыктан да бәләкәйрәк – авырлыгы көчкә 10 граммга тартадыр! Шундый мамык шарлар ботакка тезелеп утыра да, әй сайрашалар.

Аста исә, агачлар арасында, чаңгысы белән карны ерып, кеше бара. Бер дә ашыкмый үзе, әледән-әле башын күтәреп күккә карый. Кошларны күргәч, елмаеп җибәрә: бу йомшак песнәкләрне ул бигрәк тә үз итә. Атна буе очратмаган иде, ә бүген исә, әнә, көтүләре белән очып үтәләр. Димәк, хәзер кояшлы һәм җилсез булса да, кичкә буран чыгасын көт тә тор. Бер генә тапкыр да ялгышканнары юк кошчыкларның!

ОЗЫН КОЙРЫКЛЫ ПЕСНӘК

– Кардәшләреннән аермалы буларак, бу кошлар ничек һава торышы үзгәрәсен сизә соң? Әлеге механизм өйрәнелмәгән әле, тик бу фән өчен бик кызыклы күзәтү булыр иде, – ди ТР ФА Экология һәм җир асты байлыкларыннан файдалану проблемалары институтының биомо-

ниторинг лабораториясе мөдире Олег Васильевич Аськеев.

Көн саен диярлек – менә инде утыз ел! – Аськеевлар династиясе, җәяүләп яки чаңгыда, Татарстан урманнарын иңли вә буйлый. Казан галимнәре республиканың мәйданы өч мең квадрат километрдан артыграк булган утыздан артык мониторинг территориясен үз контролендә тота. Берничә дистә ел эчендә алар колачы

ОЗЫН КОЙРЫКЛЫ ПЕСНӘК

– Кардәшләреннән аермалы буларак, бу кошлар ничек һава торышы үзгәрәсен сизә соң? Әлеге механизм өйрәнелмәгән әле, тик бу фән өчен бик кызыклы күзәтү булыр иде, – ди ТР ФА Экология һәм җир асты байлыкларыннан файдалану проблемалары институтының биомониторинг лабораториясе мөдире Олег Васильевич Аськеев.

ҮРМӘЛӘЧ

– Безнең фаразлавыбызча, Татарстан территориясендә әлеге кошларның саны артуның төп сәбәбе климат үзгәрешләренә бәйле, – ди Олег Васильевич.

Фото Олег Аськеев архивыннан

буенча да, тикшеренү вакытының озаклыгы буенча да дөньяда тиңе булмаган материал туплаган. Япония Экология җәмгыяте экспертларын әнә шуның белән кызыктырган да алар: мондый эшне кабатлау инде мөмкин түгел, димәк, ул – уникаль. Тагын бер мөһим детальгә игътибар итмичә булмый: тикшеренүгә волонтерлар җәлеп ителмәгән. Бу аның дөреслеген дәлилләп кенә калмый, кабинетларында утырудан башканы белмәгән биологларны да «кырга» чыгуга илһамландыра ала.

Менә блокнот һәм бинокль тоткан тикшеренүчеләрнең берсе урман буйлап бара, тирә-яктагы тавышларны тыңлый – аңа кошларны тышкы кыяфәтеннән генә түгел, тавышыннан да таный белергә кирәк. Табылган һәркайсын саный, һәр төрен аерым язып бара. Лабораториягә кайткач, математик модельләр һәм методлар эшкә җигелә – нәкъ менә шулар кошларның урмандагы бер квадрат километрдагы ук тыгызлыгын исәпләргә һәм экологик факторларның кошларга йогынтысы турында нәтиҗә ясарга мөмкинлек бирәчәк. Билгеле, еллар буе бер үк маршрутлардан йөрү һәм кошларны санау бурычы җиңелләрдән түгел. Әмма нәтиҗә моның юкка булмавын күрсәтә, алынган статистика тренды исә шаккатыра: Аськеевлар тикшеренүенең беренче елларында (1990 нчы еллар) Татарстан урманнарының бер квадрат километрына кышын уртача 200–300 кош туры килсә, бүген аларның саны 500 дән дә артырга мөмкин!

Ә менә без – гади кешеләр – моны ничек күрә алабыз? Бу шактый катлаулы мәсьәлә. Олег Аськеев әйтүенчә, зур территорияләрдә күпьеллык тикшеренүләр кирәк. Чөнки былтыр сезнең җимлеккә биш песнәк килеп, быел унау килсә, аларны ике тапкыр арткан дип уйлау әле дөрес түгел. Шунысы да бар: әгәр сез элегрәк сандугач сайравына рәхәтләнеп, хозурланып, бүген аларны ишетмисез икән – бу да алар үлеп беткән дигән сүз түгел әле. Табигатькә циклылык хас, шунлыктан дөрес нәтиҗәне дистәләрчә еллык өзлексез фәнни күзәтүләргә таянып кына ясарга мөмкин.

Әлбәттә, Аськеевлар бөтен кошларны да игътибар үзәгендә тота, Татарстанда исә алар өч йөз төрдән артык. Әмма конкрет бу тикшеренү геройлары: песнәкләр төркеменнән – дистәләгән кош, шулай ук үрмәләч, чыелдык (пищуха) һәм иң кечкенә кош – сары башлы кәрлә чыпчык.

ҮРМӘЛӘЧ

– Безнең фаразлавыбызча, Татарстан территориясендә әлеге кошларның саны артуның төп сәбәбе климат үзгәрешләренә бәйле, – ди Олег Васильевич.

Ничек инде, гадәттә климат үзгәреше табигатьтәге күп проблемаларның сәбәбе санала бит, ә бездә шуның нәтиҗәсендә кошлар саны артамы?

ТУКТАП КАЛМАГЫЗ

Республикада климатның тотрыксыз булуы – хәзер инде фәнни факт. Шул ук вакытта моның глобаль җылынуга гына түгел, бәлки һава торышының глобаль үзгәрешенә бәйлелеген аңлау мөһим. Ягъни температура режимы гына түгел, явым-төшем күләме дә, тагын бәла-казаларының ешлыгы да үзгәрде. Сүз уңаеннан, хәзер инде татарстанлыларны көчле давыл яки чия зурлыгындагы боз яву белән гаҗәпләндереп булмый. Шулай да, Аськеевлар фикеренчә, климатның тулаем тренды уңайрак: җәй озынрак һәм җылырак, кыш исә карлырак, йомшаграк һәм кыскарак була бара. Алай гына да түгел, җылыну тренды, шул ук Европа һәм хәтта Скандинавия илләре белән чагыштырганда, Татарстанда күбрәк сизелә. Бигрәк тә – соңгы утыз елда. Әйтик, мәсәлән, Фенноскандиянең гаять зур территориясендә, 1970 елдан башлап, апрельдән августка кадәр интервалда температура фоны уртача 1–2 градуска күтәрелгән, бездә исә – 2,5 градуска.

– Мин кошларны бигрәк тә кышын күзәтергә яратам, – дип сөйли Олег Аськеев. – Бу иң мөһим чор – башка фасыллар нәкъ менә аның нинди булуына бәйле. Хәзер исә, кышлар җылынгач, кошларның уңышлы кышлау ихтималы артты. Үрчү сезоны башына аларның саны елдан-ел арта бара. Шуңа бәйле рәвештә, киләсе кышта без кошларның популяциясе тагын артуын күзәтәчәкбез. Димәк, безнең мәгълүматлар Европа галимнәренең, климат үзгәрешләре аркасында урман кошларының күп төрләренең баш саны кими дип дәлилләвен кире кага. Аларда бәлки кимидер (чөнки анда алай җылытмый), ә бездә – арта!

Бу нәрсәне аңлата соң? Климат үзгәрешләре тискәре генә түгел, уңай йогынты ясарга да мөмкин икән бит. Безнең төбәктә күзәтелгән климат үзгәрү тенденцияләре әлегә уңай. Һәм бу бөтен экосистема өчен бердәй, шунлыктан без бу моментны авыл, урман хуҗалыкларында, ягулык сәнәгатендә файдаланырга тиеш.

– Дөресен генә әйткәндә, элегрәк Татарстан мәңге яшел помидорлар территориясе иде, хәзер исә баклажан белән виноград та өлгерә! – ди Олег Васильевич. – Әмма күпмедер вакыт үткәч, вазгыять үзгәрергә дә мөмкин. Безне кошкайлар үзләре үк кисәтә кебек: «Егетләр, туктамагыз, тикшеренүегезне дәвам итегез!»

Игорь, Артур һәм Олег Аськеевлар инде менә утыз ел буе Татарстан урманнарындагы кошларны өйрәнә.

САРЫ БАШЛЫ КӘРЛӘ ЧЫПЧЫК

– Мин кошларны бигрәк тә кышын күзәтергә яратам, – дип сөйли Олег Аськеев. – Бу иң мөһим чор – башка фасыллар нәкъ менә аның нинди булуына бәйле. Хәзер исә, кышлар җылынгач, кошларның уңышлы кышлау ихтималы артты.

БЕРСЕ – **СОРЫ,** БЕРСЕ – **АК**

Савыт-саба калдыклары, төрле кирәк-яраклар, пыяла сәйләннәр арасында археолог... сөякләргә тап була. Мөгаен, берәр йорт кошыныкыдыр, дип чамалап куя ул, нәкъ менә шул табышы галимнәргә йорт казы эволюциясенең меңьеллык тарихыннан сер пәрдәсен бераз ачарга мөмкинлек бирәчәген күз алдына да китермичә.

Автор:
Ольга Туманская

ФӘННЕҢ АЛГЫ САФЫНДА

Казан биологлары – Игорь, Олег һәм Артур Аськеевлар кулына йорт казы сөякләренең шактый саллы тупланмасы эләгә. Өстәвенә, бер генә дә түгел, ә Россиядәге унбиш археологик һәйкәл-каберлектән! Әле ул гына да түгел, табылдыклар бөтен урта гасырларны колачлый: алар V–XVI йөзьеллыкларга карый, хәтта соңрак чорныкы – XVIII гасырныкылар да бар. Ягъни Идел буе төбәгендә һәм Россиянең Европа өлешенең төньягында йорт казлары асрау тарихын тулысынча диярлек күрсәтә.

– Бу безгә, дөньяда беренче булып, йорт казының борынгы ДНКсына җентекле тикшерү үткәрү мөмкинлеге бирде, – дип сөйли Олег Васильевич.

Борынгы ДНКны сөякләрдән аерып чыгару җиңел эш түгел, чөнки генетик материалның күп өлешен вакыт галиҗәнапләре җимергән-таркаткан. Мондый эш фәнни фронтир дип санала. Россиядә андый тәҗрибә юк диярлек. Казан галимнәре бәхетенә, тикшеренүләрнең бу өлешен Финляндиядәге фикердәшләре – Оулу университетының Халыкара фәнни үзәге хезмәткәрләре башкарырга ризалашкан.

КОШНЫ КУЛГА ИЯЛӘШТЕРГӘННӘР

Казны йортка ияләштерү тарихы бик борынгы заманнарга барып тоташа. Ул безнең эрага кадәр күп гасырлар элек үк башлана. Мисырдагы Борынгы патшалык заманында, дип фаразларга була, археографик табылдыклар шул хакта сөйли. Хәер, йорт казлары турында башка ышанычлы чыганаклар да бар. Мәсәлән, Гомерның «Одиссея»сенә ни диярсез?

– Без казларның доместикация (ягъни йортка ияләштерү) тарихы йорт үрдәкләренекеннән борынгырак дип уйлыйбыз, – дип сөйли Олег Аськеев. – Әмма шул ук вакытта бу хакта фәнгә бик анык билгеле түгел. Тарихи документларда каз турында фикер алышулар сирәк очрый, шуңа күрә таяныч булырдай чыганаклар юк дәрәҗәсендә.

Хәер, фәнни нигезләмәләр күзлегеннән караганда гына фактлар аз, ә менә кыйммәтле ит, йомырка, йон-каурый чыганагы буларак, каз турында искә алулар җитәрлек.

Казны йортка ияләштерү гап-гади аудан башланган дип фаразлана. Аннары кеше кошны тотып алып, хуҗалыкта асрарга була, дигән карарга килгән. Вакытлар узу белән, адәм баласы шуңа игътибар иткән: ата-ана казга караганда, бәбкәләрне кулга ияләштерү күпкә җиңелрәк, өстәвенә, җитәрлек ашатканда, бу кош тиз арада май җыярга сәләтле. Шактый авырайгач, күчмә кош булган кыр казы акрынлап миграция сәләтен югалткан һәм кешенең тугры юлдашлары сафын тулыландырган.

Бүген безнең өчен гадәти йорт казларын күзәтсәк, аларның никадәр төрле булуын бик тиз чамаларга мөмкин. Шулкадәр күп токымнар ничек китереп чыгарылды икән? Борынгы ДНК анализына нигезләнгән заманча тикшеренүләр теге яки бу төрнең эволюция тарихын аңларга, туганлыкны ачыкларга, ягъни кайсы токымның каян чыкканын билгеләргә мөмкинлек бирә. Тик нигә галимнәребезне, әйтик, сыер түгел, нәкъ менә каз кызыксындырган соң?

– Чөнки каз бу якларның символы диярлек! – дип җавап бирә бу сорауга Олег Аськеев. – Безнең төбәкнең изге кошы бит ул! Бирелгә риваять-ышануларның күбесе каз белән бәйле. Татарлар казны бик ярата, марилар, удмуртлар, башкортлар да... Идел буе һәм Урал алды халыкларының күбесе казларга табынган. Мин хәтта Казан сүзе дә уакка эленгән казаннан түгел дип уйлыйм! Шәһәребезнең исеме татар телендәге «каз анасы», ягъни «ана каз» сүзтезмәсеннән чыккан – мондый фаразга ни диярсез?

БОРМАЛЫ ТАРИХ

Әйе, без яраткан йорт казы соры кыр казыннан килеп чыккан дип санала. Әмма халыкара фәнни команда моның шулай булганлыгы яки инде бу процесска башка тагын ниндидер каз «кушылганмы-юкмы»

икәнлеге хакында дәлилләр таләп итә иде. Әйтик, Көнчыгыш Азия халыклары кулга ияләштергән «кытай казы»ның «корыборын» дигән төрдән килеп чыкканлыгы билгеле хәзер. Шул ук вакытта «кытай» казы бездәге «европалы» туганы белән бик җиңел кушыла ала, ә безнең казлар исә, үз чиратында, кыргый кардәшләре белән гаилә корырга каршы килми. Бик бормалы, буталчык, катлаулы тарих килеп чыга түгелме?

Табылдык сөякләрнең кайсы төргә караганын күз белән генә ачыклау бик кыен, шуңа күрә генетик анализсыз бу сорауга төгәл җавап биреп булмый. Борынгы ДНКны тикшерү Казан галимнәренә Россиянең Европа өлеше территориясендә һәм, аерым алганда, Татарстанда нинди казлар яшәвен аңларга мөмкинлек бирде. Шулай ук геннар дәрәҗәсендә бу кошның доместикация процессы барышын билгеләүгә юл ачты.

Табышмакның җавабы нинди соң? Казу эшләре вакытында табылган кош сөякләре калдыкларына борынгы ДНК анализы Европадагы йорт казы эволюциясендә соры кыр казы гына түгел, ә тайга гуменнигының катнашуын да күрсәтте, кызганычка каршы, бу кош хәзер безнең якларда очрамый диярлек. Шулай ук ДНКда тагын бер эз – әлегә билгесез токымлы казның эзләре табылган. Без искә алган токым вәкилләре әле табылмаган, бәлки, инде үлеп беткәннәрдер.

Аськеевларның тикшеренү нәтиҗәләре каз эволюциясенең элек уйлаганча гади генә процесс түгеллеген күрсәтә. Сораулар күп. Менә, мәсәлән, йорт казы гуменник белән ничек кушылып китә алган соң?

– Кешеләр ярдәмендә! – дип ярып сала Олег Васильевич, сорауны ишетүгә. – Алар гуменник йомыркаларын йорт казларыннан утыртып чыгартканнар. Бу исә безгә өйрәнү өчен башка – кешенең ничек яңа токым алуы турындагы тарих сәхифәләрен ача. Әмма шул ук вакытта кешеләр махсус сайлап алу ярдәмендә йорт казларының кыргый төрен әле бик озак саклап килгән. Мондый казларны яратучылар арасында марилар, удмуртлар, татарлар да булган... Әйтик, Татарстанның төньягында чыпчын соры кыр казларын асраганнар. Мин аларны бик яхшы аңлыйм. Кыр казлары тупланыбрак яшәүне үз иткән, өстәвенә – оча торган кошлар, бик игътибарлы ата-аналар. Ерак авылларда яшәүчеләр бу токымны сакларга тырышкан. Бәлки, аның ите дә тәмлерәк булгандыр. Ә бәлки, үзенчәлекле матурлыгы җәлеп иткәндер?

Казан галимнәре үткәргән тикшеренүләр берьюлы өч уңай нәтиҗәгә ия. Беренчесе – академик нәтиҗә: алар казны кулга ияләштерү тарихын аңлауга, бик аз булса да, яктылык нуры кертә; икенче нәтиҗә статус белән бәйле, чөнки бу тикшеренүләр илебез фәненең мөмкинлекләрен күрсәтә: әйе, без әле һаман да аның алгы сафында була алабыз. Һәм өченчесе – гамәли яссылыкта.

– Экосистемаларны саклау мәсьәләсенә килсәк, аларга билгеле бер дәрәҗәдә акыл белән тыкшыну хокукын мондый тикшеренүләр генә бирә алганына ышанам, – ди Олег Аськеев. – Безнең территориягә теләсә нинди хайваннар, кошлар һәм балыклар алып килеп була – хәзерге глобализация андый мөмкинлек бирә! – һәм әнә шулай, беренче каршка, яхшы ниятләргә нигезләнеп, барлык автохтон (ягъни җирле, асаба) җан ияләре юк ителә ала. Чөнки генетика дигән нәрсәне һичкем кире кага алмый! Югыйсә кош-корт, хайван асраучы, безнең якларда гасырлар буе яшәгән-үрчегән һәм җайлашкан җирле төрләрне һәм токымнарны саклап, акыл белән дә алып барырга мөмкин. Нәкъ шундыйтөрләр һәм токымнар асылда иң сәламәтләре дә һәм иң югары – генетик дәрәҗәдә! – безнең өчен туры килә торганнары да булып тора асылда. ■



Фото: Ната Смирнова



ХАЛЫККА КАДЕРЛЕ МӘЧЕТ

Соңгы вакытта журналистлар тарафыннан Балык Бистәсенең Олы Елга авылы еш телгә алына. Киң җәмәгатьчелекнең игътибарын ник җәлеп итте соң ул? Бередә 1879 елда төзелгән мәчетне сүтү эшләре бара. Олы Елгага барып, гади халык белән аралашкач, шуны аңладым: кешеләрдә шатлык хисләре белән бергә курку-шикләнү дә бар.

«АЛЛАҺЫ ТӘГАЛӘ САКЛАГАНДЫР...»

Узган саннарның берсендә Лаеш районының Кече Елга авылы турында язган идек. Ул язмада Олы Елга да еш телгә алынды, чөнки ике сала да бер вакытта оешкан, тарихлары бер. Тереләп ук торган бу ике авылның берсе – Лаешка, икенчесе Балык Бистәсенә карый. Авылларның уртак яклары шактый булган кебек, аермалыклары да бар. Шуларның берсе – борынгы, күп фаҗигаләр шаһиты булган мәчет.

Олы Елга электән үк ике мәхәлләгә бүленгән. Авылда беренче мәчет 1879 елда төзелгән. Иң гаҗәбе – ул хәзер дә сафта. Хәер, инде үткән заманда язарга кирәктер, чөнки 140 ел элек төзелгән агач бина бүген сүтелеп бетеп бара. Дөрес, бу вакытлы гына күренеш дип ышандыралар, бер ел дигәндә тарихи бина яңартылып, кире үз урынына кайтырга тиеш икән.

Мәчетне Указлы мулла – Вәлиулла Галиев төзеткән. Проекты Казан губерна идарәсе тарафыннан расланган булган. 1908 елда Олы Елгада икенче мәчет салына. Ләкин аның язмышы 1879 елда салынган гыйбадәтханәнекеннән кыскарак була. Коммунистлар хакимияткә килгәч, яңа мәчетнең манарасы кисеп төшерелә. Ә беренче эшләнгән мәчет шул килеш утырып кала. (Ул турыда соңрак).

– Мәчет манарасын кисү тарихлары һәр авылда бар диярлек, – диде Олы Елга авылы мулласы Таһир хәзрәт Гайнетдинов. – Нигездә, әлеге яман эшкә бәйле кешеләрнең язмышы фаҗигале тәмамлана. Бездә дә шулайрак булды ул. 1908 елда салынган мәчет манарасын кистергән кеше картлык көннендә михнәт чигеп дөнья куйды. Манарасыз гыйбадәтханә совет чорында клуб, кибет булып хезмәт итте. Аннан соң, дин яңадан әйләнеп кайткач, аны сүтеп, урынына яңа таш мәчет эшләп куйдылар.

– Ә совет чорында иске мәчетнең манарасы ничек киселмәгән? – дим.

– Аллаһы Тәгалә саклагандыр... Совет чорында ул амбар ролен үтәде. Әле безнең, бала-чагаларның, мәчет манарасына менеп, качышлы уйнаганыбызны хәтерлим. Алай гына да түгел, имансыз бәндәләр манараны мишень урынына да кулланган. Кызык өчен аңа атып уйнаганнар. Мәчет манарасында ядрә эзләре бар. Иман йорты колхоз складына әйләнгән иде. Анда ашлык белән бергә ашлама саклыдылар.

– Олы Елганы электән динле авыл булган диләр. Мәчеттән ашлама склады ясауга авыл кешеләре ничек карады? – дим.

– Ничек карасын, өзгәләнделәр инде, бигрәк тә өлкәннәр. Тик нишлисең, сәясәткә каршы бара алмыйсың. Күпләр, кача-поса, өйләрендә намаз укыды. Без, яшь буын гына әлеге кыйммәтләрне аңламый үстек. Аллага шөкер, дим, ул куркыныч заманнар артта калды...

– Мәчет яңадан ничек халыкка кайтарылды?

– 1990 нчы еллар башында. Шул вакытта динне тыю бетерелде, шулай да җитәкчеләр ул турыда кычкырып әйтмиләр иде әле.

Автор:
Руфия Фазылова

Фото: Александр Ефремов

– Әбүбәкер мулла безнең авылга Әлки якларыннан килгән дип сөйлиләр. Ул бик яхшы күңелле, изге кеше була. Кашан каласы җимерелгәннән соң (якынча 1393 ел), Олы Елганың оешып кына килгән вакыты. Әбүбәкер мулла Кама суын үзенең чапанына утырып йөзеп чыккан. Моны кешеләр күреп калган. Мулланың бу илаһи көченә шаккатканнар. Күп тә үтми Әбүбәкер мулла авырып үлгән. Ләкин үзенең миссиясен үтәгән – авыл кешеләрен дингә китергән.

Өченче вакыйга турында Таһир хәзрәт Гайнетдинов сөйләде. Монысы – булган хәл, ләкин барыбер могҗиза элементлары белән өретелгән ул.

– Берничә ел элек мәчеткә бер мосафир килеп керде. Иплəп кенә исәнләште, безнең белән басып намаз укыды. Шуннан соң: «Аллаһка шөкер, әтинең теләге кабул булган», – диде. Совет чорында әтисе белән узып барышлый безнең авылга кереп, манаралы мәчет ишеге төбендә намаз укыганнар икән болар. Әтисе, Аллаһның барлыгына, берлегенә бик нык ышанган карт, гыйбадәтханәнең ашлама саклау урынына әйләнгәнен күргәч, утырып елаган. «Аллаһым, шушы мәчеткә иман нуры индер, кешеләр өчен изге урынга әйләндер, – дип, карт кат-кат дога кылган. – Мин монда намаз укучыларны күрәм. Ул көн киләчәк, улым, әйтте диярсең...» – дигән. Ул чорда яңадан мәчетләр халыкка әйләнеп кайтыр дип уйлау да чынга ашмаслык хыял кебек иде әле. Әти хаклы булган. Мәчетнең яңадан торгызылуында аның да өлеше бар, димәк, хәер-догасы кабул булган, – диде.

Иман йортының илаһи көче турында тагын бер хикәят: сүтелгән мәчетнең ае нәкъ кыйблага карап торган. Авылда беркайчан зур табигать гарасатлары булганы юк икән. Моны мәчетнең саклау көче белән бәйлиләр. Кыскасы, бу мәчет авыл өчен – олы бер тарих, изге, кадерле ядкарь...

Авылның аксакалы Исмәгыйль Мөхәммәтов, район җитәкчеләреннән рөхсәт сорап, иман йортын ашламадан арындырды. Аннан Исмәгыйль әфәнде мәчетнең җиргә баткан бүрәнәләрен фундаментка утыртты, манарасын рәтләттерде. Хәер, авыл кешеләре дә читтә калмады, акчасын да җыйдылар, эшләргә дә килделәр. Менә шулай күмәк көч белән авылга яңадан иман инде.

МОГҖИЗА!

Совет чорында күрше авыл кешеләре Олы Елганы «мәчетле авыл» дип йөрткән. Ни өчен дигәндә, тирә-якта манарасы калкып торган гыйбадәтханә бары Олы Елгада гына булган.

Халык телендә мәчет турындагы сәер, гайре табигый хәлләрне үз эченә алган хикәятләр дә йөри. Хакмы, уйдырмамы, төгәл фактлар юк, әлбәттә. Менә шуларның кайберләре... 1930 нчы елларда мәчетнең манарасын кисәргә дип авылга читтән кешеләр килә. Шулвакыт давыл чыга, күктә кап-кара болытлар куера. Килгән кешеләр, бу хәлне күреп, кире китәләр. Шулай итеп авылда мәчет манарасы торып кала.

Икенчесе: авылның беренче мулласы Әбүбәкер хәзрәт илаһи көчкә ия булган, имеш. Бу хакта Олы Елга авылы музее җитәкчесе Хәтимә апа Солтанова сөйләде:

Олы Елга авылы мулласы Таһир хәзрәт Гайнетдинов.

Авыл музее җитәкчесе Хәтимә Солтанова.



Мәчетнең эчке ягы.

1908 елда Олы Елгада икенче мәчет салына, тик аның манарасы киселә. Дин яңадан әйләнеп кайткач, иске бинаны сүтеп, аның урынына яңа таш мәчет эшләп куйганнар.

«БЕР ЕЛ ВАКЫТ БИРЕЛДЕ...»

Олы Елга авылының мәчетенә республика әһәмиятендәге архитектура һәйкәле статусы бирелгән. Татарстанда тарихи әһәмияткә ия булган 121 агачтан төзелгән архитектура объектының берсе ул. Тарихи мәчетне сүтеп, Вологда өлкәсендәге Кириллов шәһәренә алып китәчәкләр. Ныграк бүрәнәләр яңартылачак, ә черегәннәре урынына яңалары өстәп куелачак. Мәчетне төзекләндерү эше танылган архитектор, РСФСР дәүләт премиясе лауреаты Александр Поповка йөкләнгән. Үзеннән үзе сорау туа: ике мең чакрым ераклыкка алып китмичә, агач бүрәнәләрне Татарстанда гына яңартып булмыймы?

– Кызганыч, Татарстанда Александр Попов кебек борынгы объектлар белән эшләү осталары юк, – диде ТР Милли мирас объектларын саклау комитеты җитәкчесе Иван Гущин. – Шуңа да читтән кеше чакырырга мәҗбүрбез. Александр Владимирович остаханәсе Кириллов шәһәрендә, мәчет бүрәнәрен анда алып барырга туры киләчәк.



Оста Александр Попов

Тагын шунысын да әйтим: аның остаханәсе Россиядәге иң уникаль төзекләндерү үзәге. Гомумән, Александр Владимировичның киләчәктә Татарстанда яшәвен телибез. Бүген бу хакта сөйләшүләр алып барыла...

Татарстанда республика әһәмиятендәге архитектура һәйкәле статусы бирелгән, агачтан төзелгән 45 бина – мәчет-утар бар. Иван Гущин аларның барысын да берәм-берәм яңартып чыгачакбыз, дип ышандырды.

– Безнең комитет – әле яшь структура, узган елның көзендә генә эшли башладык, – диде ул. – Борынгы биналарны саклап калу өчен дәүләт күләмендә махсус программа эшләү – республикабыз тарихы өчен бик мөһим адым. Теге яки бу объектны төзекләндерү өчен башта проект документлары эшләнә. Аннары алар дәүләт экспертизасы аша уза, соңыннан гына дәүләт тарафыннан төзекләндерү эшләренә рөхсәт бирелә. Программа нигезендә быел без өч тарихи бинаны төзекләндерергә планлаштырабыз.

Оста Александр Попов белән дә сөйләшеп алдым. Бер ел дигәндә төзекләндерү эшләрен төгәлләргә уйлыйлар. Якынча 19 миллион сум акча кирәк булачак икән.

– Дөресен генә әйткәндә, Олы Елгадагы кебек кызыксынучан халыкны беренче тапкыр күрәм, – диде ул. – Мин инде Россиянең төрле шәһәрләрендә эшләдем. Күп җирдә битарафлылык белән очрашабыз. Ә монда бөтенләй икенче картина: кешеләр килә, кызыксына. Алар өчен бу мәчетнең ничек кадерле булуын аңладым. Шуңа да аны мөмкин кадәр зыян китермичә, ничек бар, шулай саклап калырга тырышачакбыз. Әлбәттә, бинаның аерым өлешләре яңадан эшләнәчәк: агач бит, черек урыннары шактый. Ә тулаем алганда, 140 еллык бина өчен әйбәт сакланган ул. Мәчетнең фундаментка утыртылган булуы зур роль уйнаган.

...Олы Елга мәчете белән бәйле хәлләр әнә шундый. Авыл кешеләре арасында төрле ым-шымнар да йөри: тарихи агач бүрәнәләр әйләнеп кайтырмы? Мәчетнең ае кире кыйблага каратып куелырмы? Миңа калса, монда шикләнер урын юк: бүрәнәләр кайтачак, әлбәттә! Киң җәмәгатьчелек, журналистлар әлеге төзекләндерү эшләрен күзәтеп тора.Мәчетне харап итүгә юл куймаслар. Ә кыйблага караган айга килгәндә, монысы инде үзебездән тора.

Борынгы мәчет яңадан тарихи ватанына әйләнеп кайтыр, халыкка иман нуры чәчеп, аны җил-давыллардан саклап торыр, дигән теләкышанычта калам.

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

Яхшы табиб **НИНДИ** була

НИ ӨЧЕН роллга соусны Татарстан майонезыннан ясыйлар

«КЕШЕЛӘРНЕ ЯРАТМАСАҢ, ТАБИБ БУЛЫП ЙӨРМӘ...»

Яхшы табиб нинди була? Бу һөнәр кешеләрендә кайсы сыйфатлар өстенлек итәргә тиеш? Медицина алга китте дисәк тә, яман шеш, хроник авырулар саны кимеми. Сәбәп нәрсәдә? Шул турыда Казандагы 7 нче шәһәр хастаханәсенең ашказаны асты бизе, бавыр һәм үт юллары авыруларын дәвалау үзәге җитәкчесе, Татарстанның һәм Россиянең атказанган табибы Равил Шамил улы Шәймәрданов белән сөйләштек.

Автор:
Руфия Фазылова

«ЧИТ ӨЛКӘЛӘРДӘН ДӘ КИЛӘЛӘР»

Равил Шамилович, авыруларны дәвалау белән бергә, табибларны да укыта: профессор, медицина фәннәре кандидаты ул. Хирургия өлкәсендә яңа технологияләр эшләп гамәлгә керткән өчен ТР Дәүләт премиясенә лаек булган. 2009 елда «Ак чәчәкләр» республика конкурсында «Ел табибы» номинациясендә җиңүче. Тагын аның дистәләгән дәрәҗәле исемнәре, зур җиңүләре бар. Тик боларның барысын да санау кирәк түгел дип исәплим. Эш исемнәрдә генәмени?

– 1992 елда эчке әгъзаларны дәвалау һәм диагностикалау буенча үзәк ачуга ирештек, – дип сөйләде 62 ел (!) дәвамында авырулар-

Фото: Лилиана Вәлитова

ны дәвалау белән шөгыльләнүче табиб. – Мин моны зур казаныш дип саныйм. Үзәкне ачу нәтиҗәсендә меңләгән кешенең гомерен саклап кала алдык. Әле дә бу үзәкнең җитәкчесе буларак атнага бер тапкыр консультация уздырам. Татарстаннан гына түгел, Чувашия, Мари Эл республикаларыннан, Киров өлкәсе һәм башка төбәкләрдән дә киләләр.

«БҮГЕН ДИАГНОСТИКА КӨЧЛЕ»

Нинди генә табиб белән сөйләшсәк тә, авырулар саны артуга бара, диләр. Равил Шамилович та шул ук фикерне әйтте:

– Хастаханәдә авыруларның кимегәне юк. Күзәтүләргә нигезләнеп шуны тәгаен әйтә алам: соңгы елларда яман шеш белән авыручылар саны арта. Тик аерым саннар китерергә кыенсынам, чөнки статистиканы алып бармыйбыз.

Нигездә, безнең пациентлар – өлкән яшьтәге кешеләр. Табиб булмаган кешегә дә аңлашыла: күбрәк яшәгән саен, чирләр дә арта бара.

Росстат мәгълүматларына караганда, 2018 елда Россиядә уртача гомер озынлыгы 73 яшьтән узып киткән. Тагын бер сәбәп: хәзер диагностика көчле. Элек халык эчем авырта, башым авырта, дип йөргән-йөргән дә үлеп киткән. Бүген исә диагнозы вакытында ачыкланса, бик күп авыруларны аякка бастырырга мөмкин.

«КАРТЛЫК ҖИТМЕШТӘН СОҢ БАШЛАНА»

Равил Шамиловичка 78 яшь. Яше олы булуга карамастан, әле һаман да бүлек җитәкчесе булып эшли. Көн саен никадәр җаваплы карарлар кабул итә. Тышкы кыяфәтенә генә түгел, акылына, һәр җөмләсен дәлилләп сөйләвенә дә сокланырлык. Моның серен Татарстанның һәм Россиянең атказанган табибы миңа ничек аңлата:

– Озын гомерлелекнең нигезендә, иң беренче чиратта, нәселдәнлек ята. Туганда ук кешенең генетикасы программалаштырылган була. Төрле кешедә – төрле геном (геннар җыелмасы). Сиксәннән артык яшәмәгән нәселләр бар, мәсәлән. Йөзгә кадәр яшәүчеләр күп булганнар да очрый.

Икенчесе – акыл белән уйлап, дөрес яшәү. Геннарың яхшы булып та, тәртипсез тормыш рәвеше алып барасың, үзеңне сакламыйсың икән, гомер кыскара. Бер дә икеләнмичә әйтә алам: күп кеше үзен аракы эчеп харап итә. Хәмер куллану организмны чын мәгънәсендә җимерә. Шуның белән бергә акылын да зәгыйфьли. Моның нәтиҗәсен дә күреп торабыз: кешенең тормышы күзгә күренеп тарала. Озак һәм сәламәт яшим дисәң, аракы белән мавыкмаска кирәк.

Дөрес туклану да – озак яшәүнең бер сере. Мин үзем сугыш чоры баласы. Ипи кадерен бездән дә яхшырак аңлаучы бармы икән?! Хәзерге яшьләргә сөйләсәң, тыңламыйлар да. Шулай ул: үз башына төшмәсә, кеше күп нәрсәне аңламый. Туйганчы ипи ашау – безнең өчен чынга ашмаслык хыял иде. Әби биш ир бала үстергән. Балаларының барысы да олы гәүдәле булган. Әбием, сугышка кадәрле елларны искә алып: «Малайлар сабаннан тирләп-пешеп кайта да, туйганчы ипи кисеп ашап, тагын кырга чыгып китә...» – дип сөйли иде. Шуны әбигә кат-кат сөйләтә торган идем. Мин, кечкенә балага, туйганчы ничек ипи ашап булганлыгын аңлау мөмкин хәл түгел, чөнки андыйны күргән юк...

Ач үссәк тә, безнең буын кешеләре ныграк. Мин моны шулай ук ризык белән бәйлим. Хәзер басуда кошлар да юк бит, төрле химикатлар куллану нәтиҗәсендә үлеп беттеләр. Ә шул кырларда үскән иген безнең табынга ризык булып килә. Әле җитештерүчеләр дә азыкка төрле химия куша. Без үсмер чакта авылның бер башында ипи пешерсәләр, аның исе бөтен урамнарга тарала иде. Аеруча иген өлгергән чорда. Хәзер ипинең исе дә юк. Башкасы турында әйтеп тә тормыйм. Ризык ашап агуланабыз...

Озын гомерле булуның өченче сере – физкультура. Профессиональ спорт турында әйтмим, ул, киресенчә, организм өчен авыр. Ә гади физик күнегүләр, шул ук җәяү йөрү, йөзү – сәламәтлек өчен файдалы. Бакчада эшләү, кар көрәү кебек авыр булмаган эшләрне дә сәламәтлеккә уңай йогынты ясый дияр идем. Мин, мәсәлән, көне буе аяк өстендә, гел физкультура. (*Көлә*).

Яшькә килгәндә, картлык җитмештән соң башлана, дип саныйм. Ул яшьне узган кеше буларак моны төгәл әйтә алам. Мәрхүм эти белән бәйле бер сөйләшү күңелдә саклана. Аңа 75 яшьләр булгандыр. Авылга кайткач, сәламәтлегеннән зарланып алды. Мин аның өлкән яшенә ишарә ясап: «И, эти, миңа да 50 тула бит инде», – дидем. Шулвакыт ул миңа ярымүпкәләп: «Син нәрсә сөйлисең, 50 яшь егет чак бит әле ул», – диде. Менә хәзер шуны уйлыйм да, этинең бик дөрес әйткәнлеген аңлыйм.

НӘСЕЛ ДӘВАМЧЫЛАРЫ

Атказанган табибның балалары әтиләре һөнәрен дәвам иткәнме? Нәсел дәвамчылары бармы? Бу сорауны бирми кала алмадым. Бар икән... балалар түгел, оныклар.

– Тормыш иптәшем Әлфирә белән бер ул, бер кыз үстердек. Улым Илдар бүген – халыкара класслы спорт мастеры, Россиянең атказанган тренеры. Фехтование буенча Олимпия резервы спорт мәктәбе директоры. Илдарны 10 яшендә фехтование мәктәбенә үзем алып бардым. Шуннан мавыгып кереп китте. Табиб булсын, дигән

идем, хыялым тормышка ашмады. КДМУда бер курс белем алгач, укуын ташлады. Дөресрәге, үзем мәҗбүр иттем. Эш менә нәрсәдә: Илдар университетта укыганда да профессиональ спортны ташламады. Көн саен тренировкалар, халыкара ярышлар... «Улым, ике куянның койрыгын берьюлы тота алмыйсың. Болай булса, икесенең берсендә дә уңышка ирешү насыйп булмас. Ныклы карарга кил: медицинаны сайлыйсыңмы, әллә спорт буенча китәсеңме?» – дидем. Ул икенчесен сайлады. Һәм үкенмәде. Спорт аның өчен – яшәү рәвеше дә, яраткан һөнәре дә.

Кызым Миләүшә дә минем эздән китмәде. КДУның тарих факультетын тәмамлады. Инде бөтен ышаныч – оныкларда... Бер оныгым КДМУда белем ала, минем дәвамчым булуын бик теләр идем. Икенчесе Германиядә белем ала. Тагын берсе бәләкәй әле.

«МЕДИЦИНАДА ТӘҖРИБӘ МӨҺИМ»

Соңгы елларда Равил Шамилович операцияләр ясамый. Моның сәбәбе бик гади – күз күреме начарланган. Шулай да 7 нче хастаханәдә эчке органнарга катлаулы операцияләрне аның киңәшеннән башка эшләмиләр.

– Медицинада тәҗрибә аеруча мөһим, – диде Равил Шамилович. – Интернеттан өйрәнеп, китап укып кына яхшы табиб була алмыйсың. Дәреслектә язылганча яки аерым билгеләр буенча авыруга диагноз куярга бик авыр, мөмкин түгел, дисәм дә була. Һәр чирнең үз нечкәлекләре бар. Мондый очракларда, һичшиксез, тәҗрибә ярдәмгә килә.

Операция ясаучы хирургның күзе генә түгел, фикер йөртүе, реакциясе дә бик ачык, үткен булырга тиеш. Анда бит көтелмәгән хәлләр бик еш килеп туа. Эмоцияләргә бирелмәскә, куллары калтырамаска тиеш. Ә картая-картая, теләмәсәң дә, андый хәлләр килеп чыга. Хирургның иң көчле, куәтле чаклары – 30дан 55 яшькә кадәрле дип саныйм. Алтмыштан соң үзгәрә башлыйсың. Әйе, яшь барган саен, табибның акылы арта, ә менә кул егәре кими. Операция вакытында куллар «автоматлашкан» була. Тора-бара менә шуны югалтасың. Машина йөрткәндәге кебек. Хирург ул арымаска тиеш, алайса көнгә әллә ничә операцияне ничек ясыйсың?

Җитмешне узгач, катлаулы операциягә алыну дөрес түгел, дип саныйм. Басым ясап әйтәм: катлаулысына. Без бит ашказаны асты бизенә, бавырга операцияләр ясыйбыз. Кайвакыт бармак юанлыгы кан тамыры белән дә эшләргә туры килә. Пациентның гомере миллиметрларда санала, дисәң дә була. Моның өчен хирургтан саф фикер, аек акыл, җитезлек сорала.

«ЭШКУАРЛЫККА КИТЕГЕЗ, ДИМ...»

Равил Шамилович белән палаталарга кереп чыктык. Татарда бер сүз бар – ипле. Менә ул нәкъ шундый кеше. Җай белән генә сөйләшә, нәрсәдер әйтеп, көлдереп тә ала. Кабинетына кергәч, эш өстәле янында эленеп торган «Гиппократ анты»на күзем төште. Равил Шамилович, минем уйларымны укыгандай: «Гомерем буе шунда язылганнарны үтәргә тырыштым», – диде.

– Табиб булу өчен, беренче чиратта, кешене яратырга кирәк. Аның авыртуларын, хәлен табиб үзе аша уздырмаса, ул асылда табиб түгел, шулай санала гына. Өч буын хирургларны укыттым. Бүген биредә мин тәрбияләгән өченче буын егетләр эшли инде. Аларга әле кырык та юк, чәчәк атып килә торган, иң матур чаклары. Коллективка яңа килгән яшь табибларны башта күзәтәм: авырулар белән үзләрен ничек тоталар. Ни кызганыч, бүгенге яшьләрнең психологияләре икенче. Моңа аптырыйсы да юк: телевизорны ачсаң да, интернетта да фәкать акча турында гына сөйлиләр. Шуңа күрә яшьләрдә бары бер максат – ничек акча эшләргә? Бу «чир» табибларга да күчте. Яшермим, коллегаларыма еш кына: «Син ник медицинага килдең? Эшкуарлыкка китәргә кирәк синә, һөнә-

реңне дөрес сайламагансың», – дим. Әлбәттә, яратмыйлардыр, тик каршы әйтергә батырчылык итмиләр. Дөрес сүзгә җавап та юк бит ул.

Табиб, беренче чиратта, кешелекле булырга тиеш. Әйе, профессиональлык та кирәк. Бу сыйфатларның икесе дә булса бик яхшы, тик ни кызганыч, бу хәл сирәк очрый.

Авыру табибка ышанырга тиеш. Шул чакта гына ул сиңа ачылып барысын да сөйләячәк. Пациент белән ике арада элемтә урнаштыру – уңышның яртысы...

«КИТАП УКЫМЫЙ КАЛГАН БЕР ГЕНӘ КӨНЕМ ДӘ ЮК»

...Равил Шамилович медицина өлкәсенә караган 200дән артык хезмәт авторы. Медицинадан тыш, әдәбият, тарих белән дә кызыксына. Өендә тулы бер китапханәсе бар икән. Эш бүлмәсендәге шкафында да дистәләгән китап тезелеп тора иде. «Китап укымый калган бер генә көнем дә юк» – диде ул.

Медицинага караган хезмәтләрдән тыш, Татарстанның һәм Россиянең атказанган табибы туган ягы – Мөслим районы Ташлыяр авылы тарихын да язган. Тиздән ул китап булып басылып чыгачак икән.

– Ничек барысына да өлгерәсез? – дидем, гаҗәпләнеп.

– Өлгерәм. Эш сәгатем иртәнге алтыда башлана минем. Ә авыл тарихы китабына килгәндә, өч ел яздым аны. Ул минем күптәнге хыялым, авылдашларга биргән вәгъдәм иде. Аллага шөкер, өстемнән бурыч төште.

... Яшерен-батырын түгел, бүген күпләр табибларны комсызлыкта гаепли, танышлыкка корылган мөнәсәбәтләр, кесә ягын кайгырту хәл итә барысын да медицинада, дигән инану урнашты җәмгыятьтә. Ә Равил Шамилович аерым консультацияләре өчен бер тиен акча алмый. Бу аның катгый таләбе. Гомумән, ул башкалардан шактый нык аерылып тора торган үзенчәлекле зат. Тел, милләт мәсьәләсендә дә – үз карашы. Татарлар белән фәкать татарча гына аралаша. «Русларга да кисәтү ясыйм, чөнки дөрес сөйләшмиләр», – диде әле ул. Татар телендә белем алган, гади авыл мәктәбен тәмамлаган булса да, күп еллар дәвамында рус телендә табибларга лекцияләр укыган, хәзер дә укыта. Никадәр фәнни хезмәт язган.

– Боларның нигезендә күп уку, үзеңне даими үстерү ята», – диде тәҗрибәле табиб.

Менә шундый кеше Равил Шамилович. Тәнне генә түгел, җанны да дәвалый торган табиб. Казандагы 7 нче шәһәр хастаханәсе өчен генә түгел, ә бөтен республика өчен зур хәзинә ул дисәм, һич тә арттыру булмас.

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА
ТАТАРСТАН
TATARSTAN
facebook.com/protatarstan
twitter.com/protatarstan
instagram.com/protatarstan
БЕЗНЕҢ ТӨРКЕМНӘРГӘ РӘХИМ ИТЕГЕЗ!
Реклама 16+

ЛЕОНИД БАРЫШЕВТАН
космик соустагы диңгез кыслалары

«ТАТАРСТАН» МАХСУС журналы өчен

«Татарстан» редакциясе кухнясында Космонавтлар көнен космостагы кебек бәйрәм иттек – табынга космонавтлар орбитада сыйлана торган нигъмәт куелган иде. Алар «Махеевъ» бренды ашамлыкларын җитештерә торган «ЭССЕН ПРОДАКШН АГ» ЯАҖ генераль директоры Леонид Барышев иң яратып әзерли торган ризыкның аерылгысыз өлешен тәшкил итә.

Автор:
Татьяна Вафина

БАШТА – «ИНИЦИАТИВА», АННАН – КЫСЛАЛАР

Башта без пешкән диңгез кыслалары сатып алып, аларны матур итеп төрле яктан фотога да төшергән идек. Әмма аш-су остабыз килде дә бу матурлыкны яраксызга чыгарды.

– Кысла чи булырга тиеш! – диде Леонид Анатольевич.

Һәм без дәррәү кубып дөрес кысла эзләгән арада, ул бу кулинария паузасына хәтта сөенде һәм инициативаны үз кулына алды.

– «Инициатива», дигәннән, нинди проект соң бу?

– «Алабуга инициативасы» проекты – коммуникацияләрнең бик нәтиҗәле системасы, – дип аңлатты ул. – Һәр кеше үзен борчыган проблема белән килә яки аны хәл итү юлын тәкъдим итә ала. Өч депутат иртәдән кичкә кадәр шәһәркүләм мәсьәләләрне тикшерә. Система җәмәгать эшлеклеләре, балалар, өлкәннәр, пенсионерлар белән эшләүне дә үз эченә ала. Юридик киңәшләрдән башлап, ярышларга һәм дусларча чәй эчүләргә кадәр барысын да. Бигрәк тә бергәләшеп чәй эчүләр сөендерә. Алабугадагы иҗади рухлы, тынгысыз-дәртле әбиләргә, туйганчы сөйләшер өчен, кайдадыр җыелырга кирәк икән бит. Кайвакыт без аларга экскурсияләр оештырабыз. «Әйдәгез, бергәләп Болгарга барыйк! Кем риза?» – дибез. Барысы да дәррәү ризалаша, һәм җыйнаулашып Болгарга китәбез. Алар өчен бу – куанычлы вакыйга. Подъезд төбендәге эскәмиядә узган-барганның гайбәтен сатып утыруга караганда күпкә әйбәтрәк бит. Безнең актив спорт ветеранныбыз бар, аңа тиздән 80 тула. Ул ветераннар белән сәламәтлек көннәре уздыра, ярышлар оештыра – аның инициативасы менә шундый. Кемдер балалар арасында ярышлар уздыра. Вакытны болай үткәрү Алабугада шактый популяр. Чөнки кешеләр үзләренең вакытын оештырганны, үзләре турында кайгыртканны ярата.

– Кире элемтә бармы соң?

– Чара ошаган икән – очраткач, һичшиксез бу турыда әйтәчәкләр. Ошамаса да әйтәчәкләр. Кайбер чараларда минем әнием катнаша. Кайткач, ничек рәхәт булуы турында шатлана-шатлана сөйли аннары.

Без социаль эшчәнлек белән шөгыльләнә торган структура төзедек.

Фото: Ната Смирнова

ТАТАРСТАН
СПУТНИК АГИТАТОР
ТАТАРСТАН
ЛЕНИНА

Безгә кирәк булачак:

- патша диңгез кыслалары (пешерелмәгән, чи булсыннар!) – 400 г;
- зәйтүн мае – 300 г;
- сарымсак – 1 баш;
- тоз, борыч – тәменчә;
- розмарин (бәбрия), салат яфраклары;
- багет – 1 данә;
- «Махеевъ» майонезы – 50 г;
- «Махеевъ» кетчубы – 50 г;
- «Махеевъ»ның «Терияки» соусы – 1 аш кашыгы;
- лимон.

Ул кызыклы да булырга тиеш иде. Моның өчен социаль проектлар конкурслары үткәрәбез, җиңгәннәрен – финанслыйбыз. Мәсәлән, ишегалдында балалар мәйданчыгы булдыру гына җитми бит әле. Аннары тәнкыйть ява башларга мөмкин – таганны дөрес урынга куймаганбыз, эскәмия тәбәнәгрәк яки биегрәк кирәк булган, әйтик... Шунлыктан без таганны алып киләбез, эш коралларын бирәбез, ә халык үзе өмәгә чыксын да, үзләренә, балаларына ничек уңай, шулай ясасын. Ягъни халык үзе катнашырга, инициатива күрсәтергә тиеш – проектның асылын аңлата торган әлеге сүз шунлыктан аның исеменә үк чыгарылган да. Һәм бу шәһәр мохитен чыннан да яхшырта.

ШӘҺӘР ТӨЗИ ТОРГАН ПРЕДПРИЯТИЕ

«Махеевъ» – шәһәр төзи торган предприятие, дип әйтергә дә була. Ирекле икътисадый зона төзелгәнчегә кадәрге Алабуганы алсак, бирәдә ике юнәлеш өстенлекле иде – нефтьчеләр һәм без. Хезмәткәрләр саны буенча баштарак нефтьчеләр беренче урында торса, хәзер без – беренче. Шәһәрдән китмәскә стимул булсын, дип тырышабыз. Дөресрәге, кире кайтырга стимул булсын, дип. Без республикада беренчеләрдән булып боулинг һәм 3D-кинотеатр төзедек. Чаңгы трассасын ачтык. Җәмәгать мәйданнарын төзекләндерү программасы Алабугага искиткеч матур парк бүләк итте.

Проблема шунда ки, кече шәһәрләр картая. Мәктәпне тәмамлаучыларның үз алдына зур максатлар куйганнары, амбицияләре зуррак колачка ия булганнары бирәдән китә. Аларның, белем алганнан соң, кире әйләнеп кайтуы кирәк. Моның өчен исә яшәү шартларының уңайлы булуы мәслихәт. Зур шәһәрләрдәге бөтен шартлар бирәдә дә булырга тиеш. Икътисадның үсүе, эш хакларының югары торуы, хезмәт күрсәтү базарының пәйда булуы зарур. Ирекле икътисадый зонада яшәүчеләр өчен без күпкатлы йорт төзедек. Фатирларны арзан бәядән арендага бирдек. Кешеләр акчасын бирәдә туздырсын өчен шулай эшләдек. Бу -тұләү сәләте тиешле дәрәҗәдә булучылар, инвесторлар өчен, югары квалификацияле хезмәт мигрантлары агылсын өчен салынган табышлы йорт мисалы. Алар яңа тормыш стилен формалаштыра. Бу инде кафеларның да, кибетләрнең дә югарырак дәрәҗәдәгеләрен таләп итә – безгә дә Казан дәрәҗәсенә якынаю өчен зарур шарт. Шәһәребездә уңайлы, рәхәт урыннар күп булып, кунак чакырганда йөзебезгә кызыллык килмәвен телибез. Әмма шәһәрнең туристлар хисабына гына түгел, үз кулланучылары хисабына да яшәве мөһим. Яхшы чәчтарашлар, оста пешекчеләр бирәдән китмәсен, үзебездә эшләсен өчен тырышырга кирәк. Укуын тәмамлагач, яшьләр туган шәһәрләренә кайтырга ашкынып торса, ничек шәп булыр иде.

– Сезнең кебекме?

– Мин бирәдә яшәргә күнеккән инде. Казанда да, Мәскәүдә дә, Петербургта да яши алмыйм. Миңа Алабугада яшәве рәхәтрәк. Хәзер инде яшем дә шундый – беркая да барасы килми.

ВАК ҮЗГӘРЕШЛӘР ФӘЛСӘФӘСЕ

– Бу ватанпәрвәрлекме?

– Бу – вак үзгәрешләр фәлсәфәсе. Шундый мәзәк бар. Әгәр сез үз йортыгыз янында Германиядәге кебек матур вә хозур булуны теләсәгез, иң арзанлы юлы – Германиягә күчеп китү. Яшәгән урыныңны камилләштерүнең кыйбатлырак ысулы – вак үзгәрешләр стратегиясе. Без бирәдә, «Алабуга инициативасы» аша, дуслар-танышлар аша, нәкъ шул стратегияне пропагандалыйбыз да инде. Бөтен кешегә дә шуны гына әйтә алам: син үзең ничек телисең, үзеңә ничек ошый, шулай эшлик, дим. Кешеләрне командировкаларга җибәрәм, чөнки йөз тапкыр ишетүгә караганда бер тапкыр күрү яхшырак. Анда һәр сантиметрның ничек каралган һәм төзекләндерелгән булуын күрсеннәр дә, үзләре дә шуңа өйрәнсеннәр. Немецларга моның өчен, ихтимал, өч йөз еллап вакыт кирәк булгандыр. Безнең бурыч исә – үзебез яшәгән гомердә нәрсәнедер яхшы якка үзгәртү. Бу тозлы кыяр турындагы мисал кебек – яңа өзеп алган кыярны тозлылары янына салсаң, ул да тозлана. Менә шундый «кыяр» командировкадан кайта да, бераздан күрәсең – йорты янында

бөтенләй башка төрле бакча пәйда булган. Яки нинди дә булса матур фонарь эленгән. Менә бу вак үзгәрешләр стратегиясе дип атала да инде. Үзеңнең хәлеңнән килгәнне эшлә. Шул рәвешле шәһәрдә яраткан урыннар пәйда була да. Һәм инде кичке сәгать сигездә утлар сүнеп, барысы да өйдә утыра торган кече шәһәрләр проблемасы үзеннән-үзе юкка чыга. Хәзер бездә президент программасы буенча эшләнә торган нәрсә – җәмәгать мәйданнарын үзгәртеп кору – шулай ук безне үзебезнең шәһәрләребезне, аның кайбер почмакларын, мәйданнарын, урамнарын яраттыруга юнәлтелгән, без кич урамда йөрергә курыкмаска тиешбез.

– Алабуга сездән уңдымы?

– Мин ул Алабугадан уңдым. Бу урынны гел яхшы якка үзгәртәсе килә. Күпләр үзләренең кече ватаннарын яратып искә ала, аны сагына, аңа ярдәм итә. Мәскәүдә яшәп, мәсәлән. Мин исә мондый хәйриячелекне аңламыйм. Бу чиркәү янында хәер бирүгә охшаган. Болай ярамый. Әгәр син шәһәргә ярдәм итәсең икән, гомереңне дә аңа багышларга тиешсең, аннары, урамнан барган саен, синең дә катнашың булган үзгәрешләргә куанырлык булсын.

СИРӘК РИЗЫК

Ниһаять, кирәкле кыслалар килеп җитте. Сорылар, якындагы диңгездән әле генә тотып кайткан кебекләр.

– Мин үзем берничә төрле генә ризык пешерә беләм. Һәм бик сирәк әзерлим, – ди Леонид Анатольевич, кыслалар белән хозурланып. – Бишүн елга бер тапкыр, ял иткәндә, миннән нәрсә булса да пешертәләр. Шул вакытта инде мин берәр тәмле ризык әмәлли алам. Бервакыт утрауда ял иткән идек, һәм андагы халык мине нәкъ менә шушындый кыслаларны пешерергә өйрәтте. Миңа тәме ошады, төрле соуслар белән тәҗрибәләр ясый башладым.

– Хәзер бу сезнең фирма ризыгымы?

– Фирма ризыгы булыр иде, тик ул бик сирәк әзерләнә. Мин бит әзерләгәнгә караганда күбрәк ашыйм. Тагын да ешрак авыз итәм, бигрәк тә кондәшләребез продукциясен кабып карарга яратам – үзебезнекенең яхшырак булуына тагын бер тапкыр инанып өчен. Яки нинди дә булса яңа ризыкны татып карау һәм аңа лаеклы кулланылыш табу өчен. Ризыкка килгәндә исә… Италиядә яки Испаниядә булырга туры килсә, җирле халык киңәше буенча яхшы ресторанга барабыз һәм төрле стейклардан авыз итәбез. Франциягә футбол буенча Европа чемпионатына баргач, ачылу тантанасында әкәм-төкәм белән сыйладылар – бу да ошады.

ХАТЫН-КЫЗ КУЛЫНА – МӘДХИЯ

– Ә өегездә нәрсә пешерәләр?

– Өйдә гадәттәгечә инде… Бәйрәмнәрдә бик тәмле зур бәлеш пешерелә. Самсаны да үз итәбез. Камыр ризыгына килгәндә, мин хатын-кызлар пешергән ризык барыбер тәмлерәк, дип саныйм. Әйе, ирләр арасында шеф-поварлар күбрәк, әмма минем татар халык ашларын хатын-кызлардан тәмлерәк пешергән ир-атны очратканым юк әле. Сезнең гөбәдия пешергән ир-атны күргәнегез бармы? Минем дә күргәнем юк. Моның өчен хатын-кыз кулы кирәк.

– Кыслаларга исә ир-ат кулы бик тә килешеп тора…

– Эш кыслада гына да түгел, ә соуста. Бер акыллы аш остасы әйткән бит: ит яки балыкны кем дә пешерә ала аны, ә менә аларга соусны хәстәрләр өчен тырышырга кирәк әле, дигән. Бу һәркемнең дә хәленнән килми.

ТАТАРСТАН МАЙОНЕЗЫННАН ЯПОН СОУСЫ

– Хәзер мин ясаячак соусны бары тик безнең ашамлыклардан гына әзерләп була. Тик аны япон ресторанында уйлап тапканнар. Мин бервакыт япон ресторанында сыйландым. Соуслары бик ошады. Пешекче янына килеп, соус ясау серләрен төпченә башладым. Ә ул безнең майонезны, кетчуп һәм терияки соусын күрсәтә – ролл өчен япон соусын шулардан ясый икән!

– Япон ризыгы өчен нигә нәкъ менә сезнең продукцияне сайлап алдылар икән? Майонез һәм кетчуп җитештерүчеләр бик күп бит.

– Әгәр мин сезгә, мәсәлән, кетчуп әзерләү үзенчәлекләрен аңлата башлыйм икән, мин бер диссертациялек сүз сөйли алам. Бу минем өчен бик куркыныч тема. Бервакыт дистрибьюторлар слетында миннән без чыгара торган конфет турында сөйләтмәкче булдылар, тик мин барыбер кетчуп хакында сөйләми булдыра алмадым. Чөнки бу кетчупны мин үзем уйлап таптым! Аңарда эре яшелчә кисәкләре бар. Бу – тере яшелчәләр! Технологиясе стандарт: без бу кетчупны пешерергә һәм, ул әчемәсен өчен, пастеризацияләргә тиеш. Әмма безнең көндәшләребез ничек кенә тырышмасын, аларның кетчуп яки лечоларының төсе карала. Башка бер генә лечо да безнекенә охшамаган, аларның йә төсе бүтән, йә яшелчә кисәкләре вак. Яшелчә кисәкләре дә эре булган, пастеризацияләгәндә төсе дә үзгәрмәгән технологияне уйлап табучы без – бердәнбер! Менә сөйләгәндә дә авызымда аның тәмен тоям… Космик тәм ул!

КОСМОСНЫ ҺӘМ КЫТАЙНЫ ЯУЛАУ

– Сезнең ашамлыклар нәкъ менә тәме өчен космоска җибәрелгәнме?

– Чынлыкта без үзебезнең тюбиклардагы горчица һәм керәннең орбитада булуын очраклы гына белеп алдык. Яңа елга космонавтларга Җирдән бүләкләр җибәргәннәр, безнең продуктлар да, тикшерү, сертификатлаштыру үтеп, космоска күчтәнәч булып очкан. Аннары без космонавтлар белән элемтәгә кердек, продукциянең аларга ошаганлыгын белдек. Шул рәвешле безнең ашамлыклар космик рационга эләкте. Аннары джемнар һәм кетчуп та өстәлде. Бу – Татарстандагы бердәнбер космоста булып кайткан ашамлыклар.

– Ярый, Галәмне яуладыгыз инде, хәзер нишлисез?

– Хәзер без кибет киштәләрен яулыйбыз. Шулай ничектер бер корреспондент минем ничек баеп китүем белән кызыксынды. Без бөтенхалык сайлавы нәтиҗәсендә бай кешегә әйләндек. Чөнки сайлау дигәнебез ул көн саен киштәләрдә бара. Ак-

часын кемгә бирергә – сатып алучы үзе сайлый. Әгәр синең ашамлыгың ошый, аны сайлыйлар икән – димәк, бай кешегә әйләнәсең. Сайламыйлар икән – баймыйсың. Бу – иң демократик юл.

– Ә кытайлар бу сайлауда кайчан катнаша башлаячак?

– Кытайлар майонез ашамый, аларның үзләренең соя соусы бар. Әмма алар безнең джемнарны һәм конфетларны ашый. Тик без алар өчен башка төрле конфет ясыйбыз. Бездә конфетны чәй эчәргә алалар. Аларда исә чәй эчү – үзе бер ритуал. Алар аны үзен генә, шикәрсез, печеньесыз, күмәчсез эчә. Конфетны да аерым ашыйлар, аерым бер ризык буларак. Шунлыктан аларның конфетлары бездәге кебек баллы түгел, бөтенләй башка төрле. Миңа ошамый. Ул тәмне ничек аңлатырга да белмим. Балсыз төчедер, мөгаен.

КЫСЛА БАТАРГА ТИЕШ

Леонид Анатольевич табага зәйтүн мае сала. Күп итеп, жәлләмичә.

– Май күп кирәк, – дип аңлата ул, табадан түгелергә торган май дулкынына ишарәләп. – Кыслалар майга тәмам батарга тиеш. Миңа якын килмәскә киңәш итәм, чөнки, мин кыздырганда, бөтен җир майга чума. Аннары озаклап җыештырырга кирәк.

– Хәзер инде сарымсак салабыз. Һәр бүлемен юка телемнәргә турыйбыз һәм кайнап торган майга чумдырабыз. Сарымсак үзенә күрә чипсыга әйләнергә тиеш. Аннары без аларны майдан җыеп алабыз. Сарымсаклы майда исә кыслаларны кыздырабыз. Әмма барысын да берьюлы түгел. Өчәр-дүртәр данәләп кенә. Шулай булырга тиеш. Кысланың бер ягы кызганда, икенче ягына тоз һәм борыч сибәбез. Аннары әйләндерәбез һәм икенче ягын тозлыйбыз-борычлыйбыз.

БЕЗНЕҢ КЕБЕК ЯСЫЙ АЛМЫЙЛАР!

– Сезнең продукциягә охшатып ялган ашамлык җитештерүчеләр бармы? Контрафакт белән ничек көрәшәсез?

– Яңа гына эшли башлаган елларда «Махеевъ»ка охшатып ясаучылар булгалады. Казанда «Тасмада» кемдер кечкенә цех ачып, безнең брендныкы кебек пластмасса чиләкләр ясый башлауга, аларның эзенә төштеләр. Матбугатта бик каты шау-шу купкан иде ул чакта... Шуннан соң без шактый вакыт продукциябезне сата алмый интектек, аны барысы да ялганга саный иде. Бүген исә төрү материалына һәм җитештерүгә кертелгән инвестицияләр бик югары. Беркем дә ялган майонез ясарга алынмый, чөнки моннан табыш алып булмый. Хәзерге пакет пресслаучы машиналар Испаниядә 770 мең евро тора. Салымнарны, кайтарту чыгымнарын да кушсаң, миллионга якын җыйнала. Эретеп ябыштыру машинасы да бик кыйбат тора. Төрү материалын, савытларны, әлбәттә, охшатып ясыйлар. Бүгенге көндә безнең бренд төсләрендә ясалган майонез каплары әллә никадәр. Кайвакыт кайберәүләрне бераз куркытып та алабыз. Күптән түгел генә судта дәгъвалаштык, дизайннарын алыштырырга мәҗбүр иттек.

ЙӘ БЕТТЕҢ, ЙӘ КАЛДЫҢ!

– Сез җитештерүне 20 ел элек башлагансыз. Бу бит 1998 ел булган – куркыныч заман, дефолт, бөтен җитештерүләр ябылган чак... Ә сез кинәт кенә майонез чыгара башлагансыз... Башка сыймый бу хәл.

– Минем дә финанслар белән бик авыр чак булды ул. Йә каласың, йә бетәсең, дигәндәй. Яшь идем. Акылсыз идем. Өлкәнрәк һәм акыллырак булсам, мөгаен, бу эшкә һич тә алынмас идем. Яшь чакта шундый җүләрләнү була бит ул, эшнең ахыры ничек буласын башта ук уйлап бетермисең. Моннан да начаррак булмас әле, дип фикер йөртәсең. Мин ул вакытта хатыным белән бергә сәүдә академиясен тәмамлап кына килә идем әле. Укуның икенче елына акчаны көч-хәл белән түләдек, айлык бюджетны тиенләп санап киттек – метрога шулкадәр, ашауга – шулкадәр... Ул вакытта мин Макдоналдста иртәнге ашны ашау турында хыяллана гына идем. Хыялым тормышка ашты, хәзер мин анда көн саен иртән кереп сыйлана алам. Ял көннәрендә, иртән, чиратлар булмаган чакта, барам да ашыйм, хыялыма һаман тугры булып калам. Ә академиядә мин инде ул чакта өченче югары белемемне ала идем. Никадәр белемлерәк булсам, шулкадәр күбрәк акча эшләячәкмен, дип уйлый идем. Тик бөтенләй башка җирдә акча эшләргә насыйп булган икән бит. Барлык укыганнарымнан КАМПИда җитештерү белән идарә итүгә өйрәнүнең генә кирәге чыкты.

1. Агызабыз!

2. Турыйбыз!

3. Кыздырабыз!

4. Сөзеп алабыз!

5. Тозлыйбыз-борычлыйбыз!

6. Кыздырабыз!

7. Тотып алабыз!

8. Теләкләр телибез!

Редакция ZaVarka кулинария студиясенә рәхмәтен белдерә

Реклама

Күз алдына китерә аласызмы, кеше, совет институтына килеп, ничек майонез ясалуы хакында сораша. Миңа җүләргә караган кебек карыйлар иде. Ике атна эчендә барысын да туйдырып бетердем. Мөмкин булганның барысын да табып укыдым, өйрәндем, ятладым... Аннары барысы белән дә дуслашып беттем. Аннары алар янына үземнең технологомны китереп: «Өйрәтегез әле моны!» – дигәч, «Безнеңчә, майонез турында синнән дә күбрәк белүче юк хәзер!» – диделәр.

БЕЗ МАЙОНЕЗ ЯСАЯЧАКБЫЗ!

– Ә ни өчен нәкъ менә майонез ясаудан башларга булдыгыз?

– О-о-о-о, бу бик озын хикәят. Хәтерләсәгез, СССРда бәйрәмнәргә майонез табу шактый катлаулы иде. Без азык-төлек белән сәүдә иттек. Мин аларны Мәскәүдән үзем алып кайта идем. Чиратта торырга, тәэүләрен көтәргә кирәк иде. Кайвакытларда шунда кунып калырга да туры килгәләде. Бер кичне цех эченә кертүләрен үтендем. Керткәч, технологларны сорауларым белән аптыратып бетердем – майонез ничек, нәрсәдән ясала. Ул чакта Интернет юк иде бит әле. Китапханәгә барып, майонез турында булган бөтен китапларны алып укыдым. Рецептларын табып, күчереп алдым. Ике атналап майонез мәсьәләсен өйрәнгәч, Алабугага кайттым да: «Егетләр, без майонез ясаячакбыз! Мин аның турында бөтен нәрсәне дә беләм хәзер!» – дидем. Аңлашыла ки, компаньоннарым ул чакта миңа ышанмады. Берденбер кеше – Вадим Махеев ризалашты. Башкалар баш тартты, без икәү партнер булып калдык. Цехка урын тапкач, туганнар һәм дуслар ремонт ясарга булышты. Әмма ул чакта берсе дә бу проектка әллә ни өмет багламады. Сәүдә итү ышанычлырак иде. Монда исә җиһазлар сатып алу өчен мин үземнең «девяткамны», Вадим «Газель» машинасын сатты, әти-әниләрдән бурычка алдык. Ремонтка акча калмады, теләнеп йөрдем – кемнән плитка, кемнән буяу таптым. Беренче майонезны ясауга ук, сертификат артыннан йөгердем. Миңа: «Син каян килеп чыктың соң?» – диләр иде. Проект, рөхсәт кирәк икән. Сертификат алу эпопеясы башланды.

ЕРТЫК ЧАЛБАРЛЫ ШАШКАН КЕШЕ

– Ягъни без эш барышында бөтен нәрсәгә акренләп төшендек, – дип дәвам итә безнең пешекчебез. – Нәкъ дефолт булган зонага эләктек. Тик без бернәрсә дә югалтмадык, чөнки бер нәрсәбез дә юк иде. Без эшләп тапкан бөтен акчаны җитештерүгә кертә бардык. Вадим белән шундый фикергә килдек: ертык чалбардан йөрсәк йөрибез, әмма Россиядә беренче булган ашамлык ясыйбыз. Чөнки бу киштә әлегә буш, базар төпсез мичкә кебек, һәм безгә бу мөмкинлекне берничек тә ычкындырырга ярамый. Шулай итеп шәһәр артыннан шәһәрне яуладык. Кредитлар юк иде, бөтен эшләп тапкан акчаны җитештерүгә кертә бардык. Бөтен элемтәләрне барладык. Воронеж маен сатуыбызны искә төшереп, шул кешедән бер мичкә май җибәрүен үтендем. Ул исә 20 тонна җибәрә алам, диде. Бу майны салырга урын эзли башладык. Арендага алынган цех подвалында үзебезгә кирәкле күләмдә савыт ясаттык. Шул эретеп ябыштыручы, теләсә кайсы проблеманы шунда ук хәл итәргә сәләтле минем кебек дуамал кешене беренче тапкыр күрәм, дигән иде.

БЕРЕНЧЕЛӘР

– Без башлаганда барысы да арзанлы совет чималында эшли иде. Без исә иң заманча немец җиһазлары сатып алдык, һәм шул вакыттан бирле начар сыйфатлы продукт ясарга хакыбыз юк, дип исәплибез. Без күп нәрсәдә – беренче. Бездән соң хәзер бөтенесе штефанда эшли... Без беренче булып майонезны чиләккә салдык. Аннан майонезны дой-пакка салдык, хәзер исә вольпакка – ул заводта, мөгаен, миңа һәйкәл куйганнардыр, чөнки без аларга бөтен бер базар ачтык. Россиядә барлык инновацияләрне без керттек, аннары бездән соң бөтенесе шуны кабатлады гына. Джемнар турында аерым сөйләргә кирәк. Кайнатканда җиләк шартламаска тиеш иде. Өйдә вареньe кайнатканда, җиләкләрнең бер өлеше шартлап ярыла. Бездә исә бөтен җиләк тә бөтен килеш кала – чөнки пар башкача бирелә. Бу да – безнең ноу-хау. Ул Россиядә башка беркайда да юк.

МАЙОНЕЗ АШАП ТА... СЫЛУ КАЛУ РЕЦЕПТЫ

Барлык кысаларны майдан сөзеп алып, тәлинкәгә матур итеп тезеп куйгач, Леонид Анатольевич (игътибар!) аларны мыеклары күмелгәнче тагын майга чумыра.

– Шулай кирәк! – дип тынычландыра ул безне. – Бу майга күмәчне манып ашыйбыз – бик тәмле ул!

– Ә кысланы кая манабыз?

– Әлбәттә инде, соуска. Аны әзерләү – бу рецептның иң мөһим өлеше бит. Майонез алабыз. Аңа кетчуп кушабыз. Аннары әз генә «Терияки» соусын өстибез – ул әчелек бирә. Аннары ярты лимонны сыгабыз. Болгатабыз. Күп итеп борыч сибәбез. Тагын бер кат болгатабыз. Тагын борыч сибәбез. Татып карагыз әле... Космик тәм! Телегезне йотарлык!

Бармакларыбызны ялый-ялый, кызыксынабыз – калорияле соуслар һәм майга манылган күмәч яраткач, ничек шундый төз булып калып була соң?

– Кышын – чаңгы, җәен – велосипед. Минем норма – атнасына 100 километр.

Менә ул – дөрес ризыкны дөрес куллану! Һәм майонез яратып та сылу калуның сере! ■

ЛЕОНИД БАРЫШЕВТАН КУЛИНАРИЯ КИҢӘШЕ:

– Тәмле аштан соң корсакны май басмасын, дисәгез, атна саен чаңгыда 100 километр йөрүне гадәткә кертегез. Җәен исә чаңгыны велосипедка алыштырыгыз.



МӘДИНӘ ТИМЕРҖАНОВА: «ТНВДА «ТАТАРСТАН ЯҢАЛЫКЛАРЫН» ҮЗ КҮЗЕҢ БЕЛӘН КҮРҮ ЯХШЫРАК!»

Мәдинә Тимерҗанова – «Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясендә иң оператив һәм ышанычлы мәгълүмат өчен җавап бирүче кеше. ТНВ телеканалында ул мөһим вазыйфаларның берсен – «Яңа гасыр» ТРК» АҖ генераль директорының информацион хәбәрләр буенча урынбасары вазыйфасын били.

Бүгенге заман яңалыклары ничек эшләнә соң? Бу жанрда профессиональ булу нидән гыйбарәт? Әңгәмәдәшебездән боларның барысы турында да сораштык.

– Мәдинә Фатыйховна, ТНВ телеканалы яңалыкларын «республиканың төп яңалыклары» дип атау гадәткә кергән. Бу фикер нәрсәгә нигезләнә?

– «Республиканың төп яңалыклары» – бу гыйбарә юкка гына сайланмаган. ТНВда нәкъ менә медиакиңлекнең төп юнәлешләрен билгеле һәм трендлар тудыра торган республика яңалыклары туплана һәм шул темадагы көн тәртибе тикшерелә.

Әмма шул ук вакытта безне «зур» яңалыклар контекстында «кечкенә» кеше язмышы да кызыксындыра. Монысы иң мөһиме. Чөнки шул рәвешчә генә бөтен глобаль нәрсәләрнең безнең тормышта ничек чагылуын, тормышның ничек корылуын аңларга була: югарыдан өндәү булса, түбәннән, кешеләрдән интерактив кабул итү – безнең өчен әһәмиятле шарт. Яңалыклар өчен бу гаять мөһим!

– «Татарстан яңалыклары»ның редакция сәясәте ни рәвешле төзелә?

– Мәгълүматны тапшыруда иң мөһиме – объективлык. Бу, гомумән, безнең эшчәнлекнең асылы. Ул телетамашачы өчен дә мөһим, аеруча – экранга яңалыкларын чыгаручы редакциянең үзе өчен дә. Һәр вакыйганы (бигрәк тә анда конфликт булса) без һичшиксез төрле яклап күрсәтәбез – конфликтның ике ягында торучыларга да үз фикерен әйтү мөмкинлеге бирәбез, аңа эксперт бәясен, башка төрле карашны кушабыз. Һәм бу тапшыруның объективлыгын гарантияли. Чөнки һәр конфликтта, кем дигәндә, ике як бар. Плюс тагын бер караш – закон ягыннан бу ничек карала, мәсәлән. Шулай итеп, без бөтен фикерләр чылбырын карап чыгабыз.

Эфир материалына кул кую – бу бик зур җаваплылык. Безнең редакциядә барысы да төгәл билгеләнгән: кем нәрсә өчен җавап бирә. Яңалыклар – ул команда уены.

– «Татарстан яңалыклары» командасы ничек туплана? Ул кешеләр – кемнәр?

– Барысының да сынау срогы бар, ул тәмамлануга ачыклана да инде: «безнең» кешеме, әллә юкмы. Шул ук вакытта яңа кешегә үз потенциалын ачу өчен бөтен шартлар да тудырыла, ә аның эше бар нәрсәне үз урынына куя…

Бездә остазлык эшенә мөнәсәбәт бик җитди. Яңалыклар – гомумән, үзе бер мәктәп, үсешнең башлангыч базасы ул. Нәкъ менә бирердә телевидение кухнясын мөмкин кадәр тиз үзләштерергә була. Әгәр без кешенең хезмәткә сәләтле, эш сөючән булуына ышансак, аның урыны «Яңалыклар»да икәнен аңлыйбыз! Чөнки ул – иң авыр эш, телевидениедә иң катлаулысы.

– Яңалык сюжетын төзү процессы ничек бара? Телевидение «кухнясы» ишеген беркадәр ачып күрсәтсәгез иде…

– Яңалыклар»ны төшерүче төркем командасы катгый структурлаштырылган, функцияләр буенча аның үз иерархиясе бар.

Сюжетлар өчен идеяләр керү чыганаклары күптөрле. Дәүләт каналы буларак, безнең өчен алар – Президентны да исәпкә алып, «барлык төр һәм гаскәрләрнең», министрлык һәм ведомстволарның матбугат хезмәтләре. Болар, шулай ук, башка чыганаклар да – Интернет кебек, мәсәлән. Бездә шулай ук социаль челтәрләр мониторингы да кулланыла.

Тагын бер чыганак – ТНВ сайтындагы «Яңалыкларның кайнар линиясе» төймәсе. Бу WhatsApp аша +7 (987) 420–01–01 номерына вакыйгалар, проблемалар турында хәбәр итү, вакыйгалар урыныннан фото һәм видеолар җибәрү өчен тамашачыларның үзләренә бирелгән мөмкинлек. Бүгенге көнгә кешеләр җибәргән хәбәрләр буенча байтак сюжетлар төшердек инде.

Ахыр чиктә үзеңнең күршең, танышың, хәтта транспортта очраклы рәвештә янәшә туры килгән кеше дә сюжет нигезенең чыганагы була ала. Мәгълүмат табуда без талымлы түгел!

– Ләкин теләсә нинди вакыйга «Яңалыклар» сюжеты була алмыйдыр бит?

– Беләсезме, яңалык турында көнбатыш журналистикасыннан килгән шундый билгеләмә бар: әгәр берәүне эт тешләгән икән – бу яңалык түгел. Ә менә кеше этне тешләсә – бу инде яңалык! Шуңа күрә, бинһая күп материал арасыннан нәрсәдер сайлаганда, идеалда шундыйрак вакыйганы эзлисең.

Әмма баланс саклау да мөһим, үз-үзен хөрмәт иткән яңалыклар редакциясе беркайчан да тоташ «сарылык» ягына тәгәрәмәс. ТНВ яңалыкларындагы редакция сәясәте үзе үк моны чикли.

Безнең формат – республиканыкы, шуңа да проблемага киңрәк карыйбыз: бу ситуациягә нәрсә китергән, тагын нинди караш-фикерләр бар, мондый проблемалар Татарстанда ничек хәл ителә һ.б.

– Мәдинә Фатыйховна, сез әле генә «Яңалыклар» – телевидениедә карьера ясау өчен яхшы плацдарм, дигән идегез. Ә кемнең булдырачагын алдан чамалап буламы?

– Бу өлкәдә карьера ясарга сәләтлеләр яңалыкны «мәгълүмат» буларак» кына кабул итми, андый кешеләрдә бик югары иҗади компонент бар. Һәм без шуны үстерергә тырышабыз: әйтик, аерым рубрикаларны нәкъ менә хезмәткәрнең үзенә тапшырабыз. Аннары алар проектларга кадәр дә үсеп җитә.

– Ә инде бу «кош балаларын» үстереп, канатларын ныгытканнан соң, «оядан очырып җибәрү» кызганыч түгелме?

– Юк, кызганыч түгел. Бу сүз, гомумән, ничектер… минеке, үземнеке генә дигәндәй килеп чыгамы соң. Син инде кешенең профессиональ яктан өлгергәнлеген, форматның кысаларын киңәйтергә әзер булуын аңлыйсың. Безнең «Яңалыклар» тиешле профессиональ дәрәҗәгә туры килсен өчен, моны эшләргә кирәк.

Ә «Татарстан яңалыклары» программасының барлык сюжетларын, телевизордан тыш, TNV.ru сайтында, Youtube.comда ТНВ каналында, шулай ук ТНВ каналының социаль челтәрләрендә күрергә мөмкин. ■

Реклама 16+ Фото «Яңа гасыр» ТРК» АҖнән алынды

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

Затлы мирас **КАЙДА** саклана

Асия Садыйковага **НИ ӨЧЕН** япон Императоры орденын тапшырганнар

Галәм кешесе туган Татарстаны өчен **НӘРСӘ** эшләгән

Кече ватан патриотлары **КЕМ** турында сөйли

Тәвәккәл халык **КАЙДА** яши

КАЗАН ТӘХЕТЕНДӘ – КАСЫЙМ ХАННАРЫ ҺӘМ ЯДЕГӘР ХАН

«ТАТАРСТАН» МАХСУС журналы өчен

Алтын Урда таркалганнан соң барлыкка килгән дәүләтләрдә хан тәхетен Чыңгызыйлар нәселенә караган шәхесләр биләп торган. Мәскәү идарәчеләре тарафыннан Касыйм ханлыгыннан китереләп, Казан тәхетенә утыртылган бертуган Шаһгали һәм Җангали турында узган язмаларыбызда, ханлыкның сәяси тормышына бәйле рәвештә, бераз мәгълүмат биргән идек инде. Хәзер алар турында тәфсилләбрәк сөйләрбез. Казан ханнарына багышланган мәкаләләр циклын Ядегәр хан белән тәмамлыйбыз, әмма журналыбызның киләсе саннарында Казан ханлыгы һәм аннан соңгы чорларда яшәгән башка күренекле шәхесләребез турында сөйләшүне дәвам итәрбез әле.

Автор:
Фаяз Хуҗин

Кабат исегезгә төшереп үтим: күп кенә тарихчылар тарафыннан Казан ханлыгына нигез салучы дип исәпләнә торган Алтын Урда ханы Олуг Мөхәммәд, 1437 елда Кече Мөхәммәд тарафыннан тәхетеннән куылганнан соң, нишләптер Казан вилайятенә түгел, бәлки рус җиренә, Биләү (Белёв) шәһәре тирәсенә кача. Аның бер улы Ока елгасы буенда, хәзерге Рязань җирлегендә, тарихка үзенең исеме белән кереп калган Касыйм ханлыгына нигез сала. Касыйм ханнары, Мәскәү кенәзләре белән төзелгән килешү шартларында каралганча, атлы гаскәрләре белән Рус дәүләтенең көньяк чикләрен сакларга һәм рус кенәзләрненең (1547 елдан – патшаларының) Казанга каршы оештырган яуларында катнашырга тиеш булалар.

КАЗАН ТӘХЕТЕНДӘ – ШАҺГАЛИ ХАН

(1519–1521)

Шаһгали – 1512–1516 елларда Касыйм ханы булып торган Шәех-Аллаһиярның улы. Әнисе – Нугай морзасы Ибраһимның кызы Шаһисолтан. Шаһгали 1506 еллар тирәсендә туган һәм руслар даирәсендә тәрбияләнгән. 1516 елда, әтисе үлгәннән соң, 10 яшьлек үсмерне тәхеткә күтәрәләр. 1518 елның декабрендә, Казан ханы Мөхәммәд Әмин вафатыннан соң, Мәскәү кенәзе Василий III аны Казанга җибәрә. Әлбәттә, руслар өчен әле балигълык яшенә дә җитмәгән Шаһгали бик кулай кандидатура була. 1519 елның 1 мартында Мәскәүдә Казан делегациясе катнашында Шаһгалине тәхеткә утырту тантанасы була. Шаһгали дә, Булат Ширин җитәкчелегендәге делегация әгъзалары да Казанда Мәскәү мәнфәгатьләрен сакларга ант биреп, бер атнага сузылган күңел ачулардан соң, Казанга кайтып китәләр.

Биредә яңа ханны шатланып каршы алмыйлар, әлбәттә. Рус елъязмачысы сүзләренә караганда, Шаһгали, яшь кенә булуына карамастан, ярыйсы ук тулы гәүдәле, кыска муенга утыртылган олы башлы, кыска аяклы, иңсәләренә кадәр асылынып торган озын колаклы, маймылныкына тартым куллы һәм хатын-кызларныкына охшаш, әмма ямьсез йөзле, күңел чиркандыргыч бер кемсә була. («Татарларны мыскыллау өчен патша аны махсус сайлагандыр, күрәсең», – дип яза, ачы көлеп, рус елъязмачысы).

Фиринат Халиков рәсемнәре

Казан чолганышта.

Табигый ки, югары һәм түбән катлау кешеләре арасында Шаһгалинең абруе булмый. Аңа әле хан роленә керергә дә мөмкинлек бирмиләр: Шаһгали исеменнән Мәскәү илчесе Федор Карпов идарә итә. Элегрәк югары урыннар биләп торган Казан түрәләре ризасызлык белдерәләр. Русларга каршы оппозиция оеша һәм аның вәкилләре Кырым ханы белән бәйләнешкә керәләр. Шаһгали моны белеп тора һәм, үзенә каршы торучыларга акыллы гына: «Күреп торасыз ич, Мәскәү Казанга караганда көчлерәк, без аны берничек тә үзебезгә буйсындыра алмаячакбыз, Кырым ханына да ышаныч юк, ул да безне үзенә буйсындырырга тели», – дип җавап бирә.

Шаһгали һәм Явыз Иван Казан янында.

Ни генә булмасын, казанлылар Бахчасарайга яшерен делегация юллыйлар һәм Казан тәхетенә Кырым ханы Миңлегәрәйнең улы Сәхибгәрәйне җибәрүләрен сорыйлар. 1521 елның язында Сәхибгәрәй 300 кешелек гаскәре белән Казанга юнәлә, ә Кырым һәм Нугай гаскәрләре Мәскәү чикләренә үтеп керә. Сәхибгәрәй отряды Казанга килеп керү белән шәһәрдә мәхшәр башлана – казанлылар Шаһгалигә каршы күтәреләләр, касыймлыларның һәм мәскәүлеләрнең йортларын җимереп ташлыйлар, 5 меңләп кешеләрен үтерәләр. Шаһгали үзе хатыны, 300 кешелек гаскәре һәм рус илчеләре белән Казаннан чыгып кача, Мәскәүгә кайтып егыла.

Сәхибгәрәй Казан тәхетендә 1521–1524 елларда утыра, 1524 елда ул, тәхетен туганнан туган энесе Сафагәрәйгә калдырып, Бакчасарайга кайтып китә. Сафагәрәй ханлык белән 1532 елга кадәр идарә итә. Кырым ханнары идарә иткән чорда Казанда 1487 елдан ук башланган Мәскәү протектораты бетерелә, әмма бу хәл белән Василий III хөкүмәте килешергә теләми, Казан эшләренә тыкшына, Сафагәрәйгә каршы оппозиция оештыра. Нәтиҗәдә Сафагәрәй тәхетен калдырып китәргә мәҗбүр була.

КАЗАН ТӘХЕТЕНДӘ – ҖАНГАЛИ ХАН

(1532–1535)

Ул – Шаһгалинең бертуган энесе, 1516 елда дөньяга килгән. 1519 елда абыйсы Казанга киткәч, Василий III фәрманы белән өч яшьлек сабыйны Касыйм тәхетенә утырталар. Ул идарә иткән чорда (әлбәттә, хакимлек Мәскәү түрәләре кулында була), 1531 елда, татар полклары рус гаскәрләренең Кырым ханлыгына каршы яуларында катнаша.

1532 елда Мәскәү хөкүмәте Сафагәрәйдән соң бушап калган Казан

Колшәриф мәчете янында соңгы сугыш.

тәхетенә яңадан Шаһгалине утыртмакчы була. Бу хәбәрне ишетеп канатланган Шаһгали тиз арада гаскәре белән Мәскәүдән Түбән Новгородка чыгып китә. Ләкин Казан бу кандидатурага кискен рәвештә каршы чыга – өнәп бетермиләр аны. Тәхетне Җангалигә тапшырырга ризалашалар һәм Шаһгалине кире Мәскәүгә чакыртып алалар.

Казанда Мәскәү протектораты яңадан торгызыла дияргә була, чөнки 15 яшьлек хан Мәскәү хуҗалары сүзеннән чыкмый. Дөрес, Җангали идарә иткән чорда дәүләт эшләрендә аның регентшасы сыйфатында Гәүһәршад-ханбикә һәм карачы-бәк Булат Ширин хөкүмәте зур роль уйный башлый, әмма ахыр чиктә алар да Мәскәү яклы төркем мәнфәгатьләрен күз алдында тотып эш йөртәләр.

1535 елның июлендә (фәнни әдәбиятта башка төрле даталар да китерелә), Мәскәү хөкүмәтеннән никахка рөхсәт сорап, Җангалине нугай морзасы Йосыф кызы Сөембикәгә өйләндерәләр. Шул ук елның 25 сентябрендә Булат Ширин җитәкчелегендәге хөкүмәткә якын кешеләр Җангалине тәхетттән куалар. Озак та үтми, 18 яшен яңа гына тутырган ханның үле гәүдәсен табып алалар.

Темабыздан артык читкә китмичә, тагын Шаһгалигә әйләнеп кайтыйк әле. Ул, әлбәттә, тәхеткә утыртылган Җангалигә бик көнләшеп карый. Касыйм ханы итеп куйсалар үзен, бер хәл иде әле, бөтенләй «эшсез» калдырдылар ич. Һәм ул, үзенең Казандагы тарафдарлары белән, уңайлы очрак килеп чыкса, хан тәхетенә аның кандидатурасын яклап чыксыннар дигән уй белән, яшерен сөйләшүләр алып бара башлый. Сизгер хөкүмәт агентлары бу «серне» шунда ук Василий III галиҗәнапләренә җиткерәләр. Бөек кенәз Шаһгалине Мәскәүдән куа, ә 1533 елның гыйнварында аны хатыны Фатыйма-солтан белән Белоозерога сөргенгә үк озата.

Казанда хан булып торган Җангали үлеменнән соң Шаһгалинең хәле җиңеләя. Яңа патша Иван IV (дөресрәге, аның исеменнән Елена Глинская хөкүмәте) тәхеткә «юньлерәк» кеше эзли. Нәкъ шул вакытта Мәскәүгә Казан делегациясе килеп җитә. Шаһгалине тоткынлыктан азат итүләрен, алай гына да түгел, Казанга хан итеп җибәрүләрен сорыйлар. Елена Глинская бу үтенечне «максатка яраклы» дип таба. Әмма Җангали фаҗигасеннән соң казанлылар тәхеткә яңадан Сафагәрәйне чакыралар. Шаһгалине исә Елена Глинская хөкүмәте, Белоозеродан кайтарып, Касыйм тәхетенә утырта.

ТӘХЕТ БУШ ТОРМЫЙ...

Сафагәрәй – акыллы сәясәтче, дипломат һәм хәрби җитәкче, озак уйлап тормыйча, бөтен көчен Мәскәү дәүләтенә каршы көрәшкә юнәлтә. Рус җирләренә яу чабулар башлана. Шул ук вакытта ул үз янына кырымлыларны гына туплый, җирле халыкны, түрәләрне кыерсыта. 1546 елда казанлылар Сафагәрәйне тәхеттән куып җибәрәләр һәм, яңа хан сорап, Мәскәүгә мөрәҗәгать итәләр. Иван IV күпсанлы гаскәр белән Казанга Касыйм ханы Шаһгалине җибәрә. Рус гаскәрләрен башкалага кертмиләр, ә Шаһгали исә дәүләт белән бер генә ай чамасы идарә итеп кала – Сафагәрәй, нугайлар булышлыгы белән тиз арада шактый күп гаскәр җыеп, көтмәгәндә Казанга кайтып төшә һәм инде өченче тапкыр хан тәхетен яулап ала. Кызганыч, ул һаман элеккеге эчке сәясәтен дәвам итә, кырымлыларга каршылык күрсәтүчеләрне эзәрлекли. Ахыр чиктә Сафагәрәй хөкүмәте халыкның теләктәшлеген югалта. 1549 елда аны үтереп ташлыйлар. Сафагәрәйнең яшь кенә улы Үтәмешгәрәйне хан итеп куялар, ә аның исеменнән Сөембикә идарә итә.

Казанда хакимлек иткән Кырым ханнарының мөстәкыйль сәясәт алып баруларына ачуы чыккан Иван IV 1549 –1550 елларда Казанга ике зур һөҗүм оештыра, әмма алар уңышсыз тәмамлана. Шуннан соң ул ханлыкны бөтенләй юк итәргә җентекләп әзерләнә башлый. 1551 елның язында Казан җиренең Тау ягында, Зөя тамагында, рус крепостена нигез салына. Шул яктагы халыкны патшага тугрылык сакларга ант иттерәләр. Казанга илтүче су юллары киселә, башкала чолганышта кала. Кырым гарнизоны шундый авыр шартларда шәһәрдән чыгып кача, башкала бөтенләй саксыз кала. Башкалада Ходайкол углан һәм Нурали Ширин җитәкчелегендә яңа хөкүмәт төзелә һәм ул Зөя (Свияжск) каласындагы Мәскәү илчеләре белән сөйләшүләр башлый. Килешү төзелә, анда тәхеткә кабат Шаһгалине утырту карала. Үтәмеш хан һәм

Сөембикә Мәскәүгә әсирлеккә бирелергә тиеш була. Килешүдә хәтта Шаһгалидә дә ризасызлык тудырган тагын бер шарт була: ханлыкның чувашлар һәм марилар яши торган Тау ягын Мәскәү дәүләтенеке итеп танырга.

11 августта Сөембикә белән Үтәмешгәрәйне Мәскәүгә озаталар, хан тәхете Шаһгалигә кала. Тау ягына кагылышлы бәхәсле мәсьәлә тиз арада корылтайда каралырга тиеш була.

ТӘХЕТТӘ – ШАҺГАЛИ. ӨЧЕНЧЕ ТАПКЫР!

13 августта Шаһгали һәм аның гаскәре Казансу тамагына килеп җитә. 14 августта биредә корылтай – халык җыелышы башлана. Корылтайда күренекле казанлылардан Кол Шәриф, Нурали Ширин, Ходайкол катнаша. Бәхәсләшү озакка сузыла, әмма көн тәртибенә куелган төп мәсьәлә – Тау ягын русларныкы итеп тану-танымау – Мәскәү файдасына хәл ителә.

Шунысы кызык: корылтайда кабул ителгән шартнамәгә карамастан, Шаһгали Тау ягын русларга бирү белән һич тә килешә алмый. Хан булып алганнан соң бер ике атна да үтми, ул Мәскәүдән шул мәсьәләне яңадан карау өчен Казанга илчелек җибәрүләрен сорый. Шаһгали, казанлыларның каты басымы астында, рус патшасыннан Тау ягын үзенә кайтаруын, һич булмаса, шул җирләрдә җыела торган салымны Казанга җибәрүен таләп итә. Илчелек, чыннан да, Казанда булып китә, әмма Шаһгалинең бер генә үтенечен дә канәгатьләндерелми.

Ә рус хөкүмәте кыюланганнан-кыюлана: тизрәк Казан ханын Мәскәү наместнигы белән алмаштырырга омтыла. Зөя каласына елышкан рус яклы казанлылар бу проектны яклап чыгалар. 1552 елның февралендә Мәскәү илчесе Алексей Адашев Шаһгалине тәхеттән куу һәм аның урынына Иван IV билгеләгән наместникны кую өчен Казанга килә. Шаһгали тәхеттән ваз кичәргә мәҗбүр була. Наместник итеп Зөя каласы воеводасы кенәз Семён Микулинский билгеләнә. 6 мартта Шаһгали хәрби гарнизонын Казаннан алып чыга һәм Зөя крепостена килеп урнаша. Шул ук көнне халыкка Казан ханлыгының Мәскәү дәүләтенә кушылуы турында рәсми рәвештә хәбәр ителә.

9 мартта кенәз Микулинский үзенең гаскәре һәм тулы бер свитасы белән Зөя каласыннан Казанга юнәлә. Килеп җитә, әмма капкалар ябык була – аны шәһәргә кертмиләр. Чапкын Отучев исемле Казан бәге Микулинскийга катгый рәвештә: «Казанны сугышсыз бирмибез», – дип игълан итә.

Казанда Ходайкол хөкүмәте урынына яңа, Чапкын Отучев хөкүмәте төзелә. Казан үзенең мөстәкыйльлеген саклап калу өчен сугышка әзерләнә башлый.

Хан тәхетенә Әстерхан ханзадәсе Ядегәр-Мөхәммәд Касыйм улы чакырыла. Ул 1542–1550 елларда Мәскәүдә яши, патша хезмәтендә була. 1550 елда русларның Казанга оештырган явында катнаша, аннан соң хәрби хезмәтне ташлый һәм Нугай Урдасына китә. Казан тәхетенә Кол Шәриф һәм Чапкын Отучев тарафыннан чакырыла. Кыска гына вакыт эчендә ул шәһәрне саклау эшендә үзен яхшы оештыручы буларак таныта: шәһәр ныгытмалары төзәтелә, сугыш кораллары җитештерү җайга салына. Сафагәрәй башлаган Төньяк таш башняны төзү дәвам иттерелә.

50–60 меңлек рус гаскәре (шуларның 3 меңе Шаһгали татарлары) 23 августта Казанны чолгап ала һәм шәһәр ныгытмаларын штурмлый башлый. Дошманга каршы казанлыларның 20 меңгә якын сугышчысы (шуларның 3 меңе нугай атлылары) көрәшә. Нәтиҗәсен беләсез – 2 октябрь фаҗигасе. Каһарманнарча көрәшеп һәлак булучыларның саны бихисап.

ХАННАРЫБЫЗНЫҢ СОҢГЫ ЯЗМЫШЛАРЫ

Казанны алганнан соң Шаһгали Касыйм шәһәренә кайта һәм гомеренең соңгы көннәренә кадәр шунда ханлык итә. Иван IV аны Сөембикәгә өйләндерә. 1557–1558 елларда Ливон сугышында катнаша. 1567 елның 20 апрелендә 61 яшендә вафат була. Татар тарихына тискәре шәхес, сатлыкҗан буларак кереп калган.

Үтәмешгәрәй хан 1551 елдан соң, әнисеннән аерып алып, Мәскәүдә, патша сараенда тәрбияләнә. 1553 елда чукындырыла, Александр дип исемләнә. 1566 елның 11 июнендә 20 яшендә вафат була. Мәскәү Кремленең Архангельский соборында күмелгән.

Ядегәр хан 1552 елның 2 октябрендә әсирлеккә эләгә. Гомеренең соңгы елларын Мәскәүдә үткәрә. 1553 елда тантаналы төстә чукындырыла, Симеон исемен ала. Мария Андреевна Кутузова исемле бай хатынга өйләнә. 1565 елда вафат була. Мәскәүнең Чудов монастырендә күмелгән.

1552 елгы октябрь вакыйгасы.

ЗАТЛЫ МИРАС

Серле җир бу. Әгәр биредәге кәгазь, җиһазлар телгә килсә, сөйләгәннәрен йотылып тыңлар идек. Алар соңгы VII–IX гасыр эчендә халкыбыз тарихынданиләр булганын яхшы белә, чөнки алар – чорның тере шаһитлары. Сүзем Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының (ТӘһСИ) Язма һәм музыкаль мирас үзәге турында. Күпләр аны «Мирасханә» дип белә.

Автор:
Руфия Фазылова

ИШЕКЛӘР АЧЫК!

«Мирасханә» архив оешмаларыннан аерыла. Әйе, тегесендә дә, монысында да тарихи, борынгы ядкарьләр, документлар саклана. Тик «Мирасханә» хезмәткәрләре шуларны саклау белән бергә, фәнни-тикшеренү эшләре дә алып баралар.

Сүзне әлеге үзәкнең оешу тарихыннан башларга кирәктер. XIX гасырда, мәгърифәтчелек дулкынында, татар тарихын, мәдәниятен һәм яшәешен өйрәнү өчен галимнәрдән торган төркемнәр төзелә. 1921 елда Мәгариф халык комиссариаты каршында Академик үзәк оештырыла. Газиз Гобәйдуллин, Мөхетдин Корбангалиев, Гали Рәхим, Сәид Вахиди, Хуҗа Бәдигый кебек татар галимнәре, язучылары мирасыбызны барлау һәм өйрәнү эшендә зур көч куя – экспедицияләргә чыгып, халыкта сакланып калган кульъязмаларны җыялар, туплыйлар.

1937 елның 16 апрелендә ТАССР ның ҮБК Президиумы Татар теле һәм әдәбияты фәнни-тикшеренү институты булдыру турында карар кабул итә. Институт үзенең эшчәнлеген 1939 елда башлап җибәрә, шушы еллардан башлап сакланып калган материаллар акрынлап әлеге институтка күчерелә. Шул чорда аерым бер фондлар формалаша. 1940 елда Г.Тукай иҗаты, аннан Фатих Әмирхан буенча аерым материаллар, кульъязмалар галимнәр кулына килеп керә. Алар туплана-туплана, акрынлап фондлар, коллекцияләр барлыкка килә.

1967 елда институтка Галимҗан Ибраһимов исеме бирелә. Институтның фәнни-тикшеренү эшчәнлеге киңәя барган саен, аның үз архивын булдыру ихтыяҗы барлыкка килә. Моны истә тотып, институт җитәкчелеге 1970 елның 21 гыйнварында «СССР Фәннәр академиясенең документаль материалларны җыю, саклау һәм файдалану советына» әлеге мәсьәлә буенча мөрәҗәгать итә. Һәм 1971 елның 4 маенда институтта архив булдырырга дигән карар кабул ителә. Әлеге карар нигезендә 1972 елның мартында институтның үз архивы оештырыла. Бүгенге көндә

Фото: Лилиана Вәлитова

ул – Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге.

«Мирасханә»дә сакланган иң борынгы документларның берсе XIII гасырга карый – «Сахих әл-Бохарый» кулъязмасы. Ул институт фондына Әхмәдһади Максуди материаллары белән килеп кергән.

– Хәзерге вакытта «Мирасханә»дә 200 дән артык фонд бар, – дип сөйләде институтның Язма һәм музыкаль мирас үзәге җитәкчесе Илһам Гомәров. – Бу илле меңнән артык саклау берәмлеге дигән сүз. Әлеге документлар, китаплар, кулъязмалар гарәп, фарсы, иске госманлы һәм башка телләрдә язылган. Безнең төп бурычыбыз – шушы мирасны системага салу, фәнни яктан өйрәнү, аны халыкка җиткерү, җентекләп төзелгән тасвирламасын булдыру. Ягъни документның тарихы, техник билгеләре ягыннан – кәгазь төре, язу карасы, күчерү урыны турында нинди мәгълүматлар бар, боларның барысын да өйрәнеп, исәпкә алып, кулъязмаларны барлау, теркәү. Барлык материалларны тәрҗемә итеп, электрон форматка күчерү бурычын да куйдык алдыбызга.

– Ә бирегә килеп, ул документлар белән танышырга ярыймы? – дим җитәкчегә.

– Әлбәттә. Һәм киләләр дә. Тарих, тел белгечләре, укытучылар, студентлар, гади кешеләр – барысы өчен дә ишекләр ачык. Соңгы вакытта эшләр тагын да җәйләнде – аерым чорга караган документларны, язучыларның кулъязмаларын татарчага тәрҗемә итәбез. Булган хәтле материаллар белән сайтта да танышып була.



– Тарих, тел белгечләре, укытучылар, студентлар, гади кешеләр – барысы өчен дә ишекләр ачык, – ди Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге җитәкчесе Илһам Гомәров.

Бүген барлык язмаларның 15-20 проценты сканерланган инде. Фондлар якынча шул ук күләмдә даими тулыландырылып торганга, бу сан һаман бер чамада тибрәнә икән. Хәер, сканерлап алдың да эш бетте түгел: ун ел саен ул дискларны яңартып торырга туры киләчәк.

– Сканерны 2016 елда дәүләт программасы ярдәмендә алдык, – диде җитәкче. – Бик яхшы җиһаз ул, китапларга, документларга зыян китермичә генә эшли ала, «контактсыз планетар сканер» дип атала. Шулай ук кулъязмаларны тузаннан арындыра, чистарта торган җайланмабыз да бар. Сканер аша уздырганчы, материаллар иң элек шул җайланма аша үтә.

ТУКАЙНЫҢ БИЛГЕСЕЗ ХАТЫ?

«Мирасханә»дә бүген дистәдән артык кеше хезмәт куя. Эш өстәлләренә күз төшереп алдым: һәр кешенең каршында компьютер тора, иске китаплар, кулъязмалар ята. Егет-кызлар (коллектив чагыштырмача яшь) шуларны тәрҗемә итеп, кулъязмаларның күчермәләрен алып утыралар. Башкарылган эшләрне, ягъни без бүген аңлый торган телдә «яңарып» өлгергән кулъязмаларны китап итеп чыгаралар, шулар нигезендә конференцияләр оештыралар икән.

Югарыда әйтелгәнчә, «Мирасханә»нең рәсми сайты бар. Борынгы кулъязмалар, татар әдәбияты,





«Мирасханә»дә сакланган иң борынгы документларның берсе XIII гасырга карый – «Сахих әл-Бохарый» кулъязмасы. Ул институт фондына Әхмәдһади Максуди материаллары белән килеп кергән.

Институт хезмәткәрләре, Татарстан районнарыннан тыш, Россиянең милләттәшләребез яшәгән башка төбәкләренә, чит илләргә дә гыйльми экспедицияләргә чыгалар.

тарихы белән кызыксынган кешеләр сайтка кереп, документлар белән таныша ала. Тик әлеге сайт рус телендә генә алып барыла. Дөресен генә әйткәндә, мин моңа гаҗәпсендем.

– Сайт татарча да булачак, – дип аңлатты Илһам Гомәров. – Без сайтыбызны әле узган елның азагында гына эшләтеп җибәрдек. Ул ике телдә дә алып барылачак. Хәер, анда хәзер үк татарча текстлар шактый. Әдипләребезнең язмаларын нинди телдә язылган, шул телдә сайтка урнаштырабыз. Рус телендәге документларны русча бирәбез, татарчаларын – татарча.

Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге соңгы 3–4 елда гына да, фондларында булган материалларына таянып, берничә татар әдибенең иҗатына багышлап китап чыгарган. Анда халыкка әле билгеле булмаган кулъязмалар, фотосурәтләр дә бар.

– «Тукай энциклопедиясе»н чыгаруны зур казанышыбыз дип саныйм, – диде Илһам Гомәров. – Мәшһүр шагыйребезнең 130 еллыгына багышлап, «Казан Кремле» музей-тыюлыгы белән бергәләп, «Тукайга сәяхәт» күргәзмәсен оештырдык. Соңрак, шуның дәвамы итеп, дүрт йөз сигез битле күргәзмә каталогы нәшер ителде. Хәзерге көндә институт хезмәткәрләре Тукайның тормышын һәм эшчәнлеген колачлаган өч томлык хезмәт язу белән мәшгульләр. Беренче кисәк әдипнең Җаек чорын колачласа, икенче, өченче кисәкләрдә Җаектан Казанга күчкәннән соңгы тормышы бәян ителәчәк.

Тукай иҗаты турында сүз чыккач, тагын бер мөһим вакыйганы әйтми калу ярамас. «Мирасханә»гә милләтебезнең йөзе булган шагыйрьнең әле халыкка чыкмаган хаты «кайткан» икән. Әдәбиятчылар 1907 елда Тукайның Уральскидан Казанга – Гыйльметдин Шәрәфетдин улы Шәрәфкә* язган хаты барлыгын ачыклый. Эзләнә торгач, ул хатны журналист, Тукайның дусты Кәрим Сәгыйдиның оныгы Эльмира Тисенко кулында икәнлеген белеп алалар. Зыялы нәселнең дәвамчысы, бер дә каршы килмичә, хатны «Мирасханә»гә тапшыра.

– Хат шактый таушалган иде, – диде Илһам Гомәров. – Казан Кремле, хакимиятләребез ярдәмендә шуларны тергезә алдык. Алар күргәзмәгә дә куелды.

«ҮЗЕБЕЗНЕҢ ЙӨЗ...»

Әлбәттә, борынгы кулъязмалар бер Казанда – «Мирасханә»дә генә түгел. Чит илләрдә, шул ук элеккеге союздаш республикаларда да андый үзәкләр бар. Тик бездәгесе аларныкыннан шактый аерыла. Кай ягы белән соң?

– Дөресен генә әйткәндә, безнең кулъязмаларга бераз сокланып, гаҗәпсенеп тә карыйлар, – диде Илһам Гомәров. – Чөнки алардагы мирасның 90 проценты гарәп телендә язылган: дини трактатлар, рисаләләр, ислам дине мәсьәләләренә кагылышлы кулъязмалар. Ә бездә исә андыйлар белән беррәттән, иске татар телендә язылган материаллар да күп. Әйтик, сәяхәтнамәләр, көндәлекләр, шәкерт дәфтәрләре бар. Тарихтан беләбез: китап күчерү белән бергә, шәкертләр, мәдрәсә тормышындагы кайбер кызыклы вакыйгаларны да язып барганнар. Дөнья хәлләрен дә бәян иткәннәр. Гади халык арасында таралган шигырьләрне дә теркәп куйганнар. Һәм шул ук вакытта дини мәсьәләләргә кагылышлы әйберләрне татарча язганнар. Бу безнең өчен зур мирас та, күрсәткеч тә! Күп кенә язмаларыбыз мөселман дөньясында кулланылышта йөргән. Без аларны белеп кенә бетермибез, чөнки ул хакта сөйләмиләр, алар онытылган. Болгар чорында да язма мирасыбыз булган. Тик тарихи бәрелешләр, зур фаҗигаләр аркасында аларның бик күбесе югалган.

«Мирасханә»дәге күпчелек кулъязмалар XIX гасырга карый икән.

– Мәрҗани иҗат иткән вакыт татар әдәбиятында аерым бер күтәрелеш чоры була, – дип сөйли Илһам Гомәров. – Шуңа да ул чор әдәбиятын даими өйрәнәбез. Мисал өчен, «Мирасханә» хезмәткәрләре Мәрҗанинең әлегә кадәр гарәп телендә генә булган ике әсәрен тәрҗемә итте. Эшне алга таба да дәвам итәчәкбез.

Институт хезмәткәрләре, Татарстан районнарыннан тыш, Россиянең милләттәшләребез яшәгән башка төбәкләренә, чит илләргә дә гыйльми экспедицияләргә чыгалар. Аннан шактый бай мәгълүмат алып кайталар. Алар сөйләвенчә, тарихи документлар, борынгы китапларның кадерен белмичә, чүплеккә чыгарып ату очраклары да еш очрый икән.

...Архивтагы материаллар белән танышканнан соң, шундый нәтиҗәгә киләсең: борынгы бабаларыбыз мөселман дин тәгълиматына үзләреннән зур өлеш керткән. Монысы бер. Икенчесе – гасырлар чылбыры өзелмәгән. Алтын Урда чорыннан башлап, бүгенге көнгәчә әдәби әсәрләребезне барларга, шул рәвешле, ул чор кешеләренең уй-фикерләрен тоемларга, аңларга, әдәби телнең нинди эволюция кичерүен күздән кичерергә була. Күңелне борчыган ягы да бар: «Мирасханә» кебек файдалы, затлы урын барын республикабызда күпләр белми. Монысы әлеге дә баягы безнең тыйнаклыгыбыздан киләдер. Югыйсә дөньяга чыгарырлык, күрсәтерлек мирасыбыз зур, бай да бит. Юк шул, гадәттәгечә, эндәшмибез.

*Гыйльметдин Шәрәф (1885–1943) – күренекле татар мәдәният һәм җәмәгать эшлеклесе, нәшир, матбагачы. Ул Казанда оешкан беренче татар «Матбагаи Шәриф» типографиясе, аннан «Мәгариф» дип аталган басмаханә һәм нәшрият җитәкчесе була. Тукай әсәрләренең зур өлеше (14 китабы) шушы нәшриятта басылган.



1907 елда Тукайның Уральскидан Казанга – Гыйльметдин Шәрәфетдин улы Шәрәфкә язган хаты.

«ХӨРМӘТЛЕ ГЫЙЛЬМЕТДИН ШӘРӘФ ӘФӘНДЕ!

Тарафыңызга, заказной бандероль уларак, «Әшгаре мәҗмуга»мне йибәрдем. Шигырьләр мөкаддим-мөаххир басылуын рәкымләр илә яздым. Үзеңез аерырсыз. Зинһар, яхшылап тәсхих идеп басыңыз. Азсынсаңыз, ушбу арада тагы бәгъзе тәхрират йибәрермен. Үзеңез дикъкатьләп карап чыгыңыз да, нәшер итәргә разый булсаңыз, миңа тизлек берлә 50 тәнкә акча йибәреңез. Ихтимал, андыйн соң Казанга үзем барып, китабымны лично тәсхих идеп бастырырмын. Әгәр разый булмасаңыз, китабны кире үземә кайтарыңыз. Инде мин Сезгә бөтенләй тапшырдым. Ничә мәртәбә бастырсаңыз да рөхсәт.

Җаваб көтәм. 7нче июньдә мәктүбеңезне алдым. Шартыңызны кабул итәмен, димешсез.

Бәндәгез Г. Тукаев»

ШӘКЕРТ ДӘФТӘРЛӘРЕ

Кульязма. Шәкерт дәфтәре. XX гасыр башы. Татарстан Фәннәр академиясе Г.Ибраһимов ис. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге. Фонд № 39, сак. бер. № 446.

Габдерәхим Утыз Имәнинең өченче буын оныгы Мөхәммәтҗан бине Мөхәммәтгалимнең шәкерт дәфтәре. 1973 елның 28 июнендә Сарабиккол авылында табылган.

Дәфтәрдә төрле әсәрләрдән («Гыйльме хәл», «Пәйгамбәрләр тарихы» һ.б.) өзекләр, Коръән сүрәләре һәм догалар, шигъри текстлар тупланган.

Фотографиядәге биттә түбәндәге язма:

Имтихан мәҗлесендә укылыр
Имтихан мәҗлесендә менә шушыны әйтәләр:
Динем Ислам динендә, нәбием Мостафадыр
Нәселем Адәм нәселедер, белмәк кирәк кардәш.
Җәнабе Хак хәзрәте әгәр кылса кодрәте
Юкдан без (н) е яратты, белмәк кирәк кардәш...
Рәсүлуллаһ юлында аерылмаек кардәшләр,
Укыб гамәл кылаек, тырышаек кардәшләр.
Мәҗлесемез башланыр, белүчеләр шатланыр,
Афәрин, тәхсин алыр, дога кылың кардәшләр.



Кульязма. Шәкерт дәфтәре. XX гасыр башы. Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов ис. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге. Фонд № 39, сак. бер. № 782

Куакбаш авылы мәдрәсәсендә укыган Габдрахман Вилдан углының шәкерт дәфтәре. Катыргы тышлы. Китап тулы, барлык кәгазьләре дә сакланган – 117 бит. Китап 1911нче елда Куакбаш авылының I нче мәхәлләсе мәчете каршында Мөхәммәдфазыл мелла Гыймадетдин углы мәдрәсәсендә язылган. 1976 елда Гомәр Сәлманов тапшырган. Т

ТАССР 100 ЛЕТ ЕЛ

100 ЕЛ ПОРТРЕТ ТАРИХ

100 ел – үз эченә берничә буын кешеләренең язмышын сыйдырган җитди дата ул. Бу кешеләрнең һәрберсе үз тормыш юлын үткән, үз тарихын кичергән, димәк ки, Татарстанның да 100 еллык гомере аларныкыннан үрелгән дигән сүз. 2020 елгы юбилейга без ныклы адымнар белән атлап барабыз.

«Гасыр портретлары» проекты каһарманнары әлеге 100 еллык вакыт аралыгының төрле этапларына карыйлар. Аларны нәрсә берләштерә соң? Барысы да – Татарстанда яшәп һәм эшләп, үз ватаны өчен тырыш хезмәт куйган. Көчләреннән, әмәлләреннән килгәнчә, әмма һәрберсе дә – зур ярату, дәрт, теләк белән. Татарстанның 100 еллык олы тарихы нәкъ менә шушы гади кешеләр башкарган эшләрдән һәм тудырган вакыйгалардан гыйбарәт. Без олы тарихны тәшкил иткән кечкенә тарихларны берәмтекләп җыярга булдык – 1920 елдан башлап, 2020 елга кадәр. 100 ел – 100 портрет – 100 тарих.

100 ел – 100 портрет – 100 тарих.

ГАСЫР ПОРТРЕТЛАРЫ. ТОРГАН САЕН ЗУРРАК ХЫЯЛЛАР БЕЛӘН ЯШӘҮЧЕ

Владимир Жаворонков 33 яшь

«Бар да бик гадәти һәм тормыштагыча – башка сайлау мөмкинлегем булмады чөнки». ТР Сәламәтлек саклау министрлыгының баш штаттан тыш белгече – онколог Владимир Жаворонков язмышын ни өчен медицина белән бәйләве турындагы сорауга әнә шулай җавап бирә. «Бөтен туган-тумачаң табиблар булып, аларның үзен корбан итү белән чиктәш хезмәтен көннән-көн күзәтеп торасың да, теләсә нинди бәйрәм мәҗлесендә профессионал бәхәсләр шаһитына әвереләсең икән, синең тормыштагы юлың үзеннән-үзе билгеләнә», – ди ул. Әмма, ничек кенә билгеләнгән булмасын, ул юлдан атлап китү барыбер җиңел бирелми, ди. Биш ел элек республика онкодиспансеры баш табибы Владимирга оештыру-методика эшләре буенча үзенең урынбасары вазыйфасын тәкъдим итә. Бу нәрсә дигән сүз? Владимирның табиблык практикасына вакыты калмаячак, дигән сүз, әлбәттә. Әмма ул җитәкче вазыйфасында күбрәк кешегә файда китерә алачагына өметләнеп, ризалаша. Жаворонков уңышлы җитәкче булып чыга: моны онкодиспансерның уңышлары һәм масштаблы проектлары раслап тора. Алар «Россия лидерлары» Бөтендөнья конкурсында да җиңеп чыктылар, әнә. «Безнең хастаханәнең проектлары гаять күп, ул проектлар белән чын мәгънәсендә горурланабыз. Аларның барысы белән дә кем идарә итә, диярсез – монысы икенче мәсьәлә, чөнки команда берәгәйле эшләгәндә, андый якларны уйламый башлыйсың. Шәхси ирешүләр дә – команда эшеннән башка мөмкин түгел», – дип ышана Владимир.

Туган елы – 1985

БУ ЕЛДА – ТАТАРСТАНДА

1985 елның март ае. СССРда КПСС ҮКның генераль секретаре постын Михаил Горбачев били. «Иптәшләр, безнең барыбызга да үзен үзгәртеп корырга кирәк булачак», – ди ул. Партактив җыелышы вакытында әйтелгән бу сүзләр хәлиткечкә әверелә. Илне кризистан алып чыгу буенча яңа планда икътисадый як та, социаль якт та мөһим роль уйный. Иң киң яңгырашка ия булганы, җәнҗаллысы, мөгаен, исерткеч эчемлекләргә каршы кампания булгандыр. Хәмер кулланган өчен партбилеттан колак кагарга да мөмкин була ул чакта. Массачыл рәвештә йөзем куаклары киселә, шәраб һәм аракы җитештерүче заводлар профилен алыштырырга мәҗбүр була. Әмма халык бу хәл белән җиңел генә ризалашмый: самавыр авызыннан үзләре ясаган аракыны агызып уздырган хәмерсез туйларны ул заман кешеләре әле һаман да хәтерли. Астан җитештереп сатуларны. Алыпсатарларны...

Шешә ышанычлы валюта аналогына әверелә. Әмма ил халкы гына түгел, ә аның бюджеты да җәфа чигә: миллиардлаган сумнарга «юкара», сыра кебек җиңел эчемлекләрнең булмавына бәйле дә... Казанда ул елларда «Кызыл Шәрык» сыра заводы эшли, аны Германия белән Чехословакия белгечләре төзегән була. Ел саен заводта 6,5 миллион декалитр сыра чыгарыла, 1985 елдан исә җитештерү күләме икеләтә кими, җайланмалар, эшсез калып, тузан җыеп ята башлый. Горбачевның исерткеч эчемлекләр куллануга каршы оештырылган кампаниясе зур ризасызлык уятуын дәвам итәчәк әле. Аны хәзер дә уфтанып искә алалар. Ә менә ун еллардан соң Стэнфорд университеты тикшеренүчеләре төркеме шундый нәтиҗәгә килә: кырыс һәм гаять популяр булмаган ысуллар кулланып, Горбачев ул елларда СССРдагы үлем чиген киметүгә ирешә. Ә менә аракыга каршы кампания пыран-заран килгәч, бу чик тагын югары күрсәткечләргә таба сикереш ясый.

ТУГАН ТАТАРСТАНЫ ӨЧЕН НӘРСӘ ЭШЛӘГӘН:

Яман шешне 85 % очракта дәвалап була, ди белгечләр. Әлбәттә, иртә стадиядә табылса. Бу чиргә профилактика ясарга да мөмкин, диләр! Онкология белән авырмас өчен хәтта тормыш рәвешеңә гап-гади үзгәрешләр кертү дә йогынты ясый ала икән. «Кисәтелгәнсең, димәк, кораллангансың» – бу гыйбарә буш урында гына барлыкка килмәгән, билгеле.

2016 елда ТР Сәламәтлек саклау министрлыгы «Шешләргә белем ярдәмендә каршы тору» проектын башлап җибәрде. Проект үз эченә социаль рекламаны да ала, белгеч-онкологларның республиканың эре сәүдә үзәкләренә чыга торган махсус акцияләрен дә. Проектта меңләгән татарстанлы катнашкан. Кайберләрендә табиблар чирне яралып кына килгән хәлендә «эләктереп алган». Жаворонков бу мәгърифәтчелек эшенә инде берничә ел дәвамында кураторлык итә. Моның белән генә чикләнеп калмыйча, эшен колачлырак итәргә дә тырыша. Һәм проект яңа юнәлеш ала – мәгърифәтчел, диярге дә буладыр аны. Онкологлар мәктәп укытучыларын һәм анда эшләүчеләрне тикшереп кенә калмый, ә махсус лекцияләр дә уздыра. Әлеге формат – Владимирның «Россия лидерлары» проектындагы бәйге эше, ул аны җиңүгә алып килә. «Мин безнең онкология өлкәсендә хезмәт куйган шәхесләрнең күркәм традицияләрен дәвам итәргә телим, – ди Жаворонков. – Үз эшем өчен оят булмаслык итеп эшлисем килә. Әлеге теләк – эчке этәргечем дә, дәрт бирүче учагым да. Мөгаен, шуңа да мин торган саен зуррак хыяллар белән яшимдер...»

ГАСЫР ПОРТРЕТЛАРЫ. ИМПЕРАТОР ОРДЕНЫ БЕЛӘН БҮЛӘКЛӘНӘ

Асия Садыйкова *68 яшь*

Асия Йосыф кызы Садыйкованың йөрәге ике тигез өлешкә бүленгән – бер өлеше мәңгегә туган Татарстанына багышланган булса, икенче өлеше бөтен барлыгы белән – Япониянеке.

Асия Садыйкова – физика һәм математика фәннәре кандидаты, КМТТУ (КХТИ) доценты, «Сакура» Татар-япон мәгълүмат-мәдәният үзәге» Автоном коммерцияле булмаган оешмасы директоры, «Россия–Япония» җәмгыяте идарәсе әгъзасы. Күптән түгел генә Япония императоры аны ике ил арасында дуслык күпере төзеп, үзара аңлашу мөмкинлеге тудыра торган мөнәсәбәтләр корганы өчен Күтәрелеп килүче Кояш ордены белән бүләкләде. Орден 2019 елның апрель башында Мәскәүдә Япониянең Россиядәге илчесе Тоёхис Коудзуканың рәсми резиденциясендә тапшырылды.

Туган елы – *1951*

БУ ЕЛДА – ТАТАРСТАНДА

1951 елда дөньяда шактый күп кызыклы хәлләр була. Лондонда җир шарындагы беренче супермаркет ачыла. Швециядә җәмәгать урыннарында үбешү тыела. Космоска беренче совет ракетасы Р-1 очырыла. Аның бортында галәм киңлегенә беренче тере җан ияләре – Цыган һәм Дезик исемле этләр чыга. СССРда шулай ук СССРның Милли Олимпия комитеты төзелә һәм Халыкара Олимпия комитеты Советлар Союзын 1952 елгы Олимпия уеннарында катнашырга чакыра. СССРның туп белән хоккей буенча өченче чемпионаты нәкъ менә шундый күтәренке спорт рухында уза. Ул беренче тапкыр бер бөҗралы турнир рәвешендә үткәрелә. Беренче төркемнең матчлары 1951 елның гыйнварында Архангельскида булып уза. СССР чемпионы дип «Динамо» (Мәскәү) командасы табыла, әлеге команда җиде матчта җиңү яулый. Берәттән Казанда икенче төркемдәгеләр турниры уздырыла. Киләсе сезонда югары дивизионда уйнау хокукын Ригадагы ОДО һәм Казандагы «Крылья Советов» төркемнәре яулап ала. Икенче төркемдә 29 уен уйнала (икенче урынга лаек булып, иң көчлеләр классына путевка алачак команданы ачыклар өчен өстәмә матч таләп ителә), 119 туп кертелә. Өстәмә матчта 4:0 исәбе белән «Крылья Советов» (Казан) Калинин исемендәге завод (Калининград) командасын җиңүгә ирешә.

Шулай итеп, Рига һәм Казан командалары киләсе сезонда беренче төркемдә чыгыш ясау хокукына ия булалар.

ТУГАН ТАТАРСТАНЫ ӨЧЕН НӘРСӘ ЭШЛӘГӘН:

– Фәнни һәм системалы якын килүгә нигезләнеп, халыкара хезмәттәшлек өлкәсендә җәмәгатьчелекнең дәүләт органнары белән уңышлы эш алып бару моделен кертә (Япония белән хезмәттәшлек мисалда). Япония ягыннан бу модель иң шәпләрнең берсе буларак танылa.

– Казанда япон телен югары уку йортларында укыту программасын эшләтеп җибәрүгә көч куя, моны башкарыр өчен Япония илчелеген җәлеп итә.

– Дәүләт органнары белән хезмәттәшлектә Татарстанда япон мәдәнияте фестивале һәм «Татарстан – Япония» дип исемләнгән бизнес-семинарлар оештырыла.

– Зур чыгымнар сорамаслык итеп Японияда Татарстан Республикасы рәссамнарының күргәзмәләрен уздыруга ирешә. Күргәзмәләр белән берәттән, югары уку йортлары өчен белем бирү программалары буенча да презентацияләр уздырыла. Төркиядә, Мароккода, Иорданиядә, Сүриядә, Ливанда, Мисырда, Белоруссиядә һәм Испаниядә 8 күргәзмә гөрләп уза. Япониянең NHK телерадиокорпорациясе Татарстан Республикасы турында япон телевидениесендә төрле программалар чыгуны тәэмин итә.

ГАСЫР ПОРТРЕТЛАРЫ. ГАЛӘМ КЕШЕСЕ



Фото: Альберт Муклаков

Александр Иванов

67 яшь

Александр Иванов бөтен гомерен яраткан шөгыле – чүкеп ясауга багышлый. 1978 елдан башлап, ул үз хезмәтләреннән коллекция тупларга керешә. Панно өчен сюжетларны үзе уйлап таба һәм металлга күчерә. Останың кайбер әсәрләре, күпсанлы кечкенә, хәтта ки зәркәнче генә эшли алырдай детальләрдән гыйбарәт булуына карамастан, озынлыгы буенча икешәр метрга җитә. Александр 120 дән артык эш авторы. Аларны беркайчан сатмаган да, бүләк тә итмәгән. Әмма даими рәвештә күргәзмәләр оештыра – анда останың эшләрен теләгән кешеләр килеп карый һәм соклана ала.

Туган елы – 1952

БУ ЕЛДА – ТАТАРСТАНДА

1952 елда безнең Галәмдә үзебез генә түгел икәнлегебез ачыкланды. Көнбатыш Германия өстеннән очканда, Америка сержанты Хьюз оча торган тәлинкә күрә. Бу хакта АКШ президентына доклад юллана. Черчилль НЛО турындагы мәгълүматны төгәл 50 елга яшереп саклый торган итәргә боера, чөнки ул, аның фикеренчә, җәмәгатьчелектә курку һәм башбаштаклыклар уятырга мөмкин. Әмма яшерү нияте барып чыкмый. Бу хакта белеп алган Сталин ракета-космос системалары конструкторы Сергей Королевны чакырып ала һәм аңардан бу хакта фикерен сорый. «Оча торган тәлинкәләр», иптәш Сталин, – ди галим-конструктор, – илебезгә күзгә күренеп тора торган хәвеф белән янамый».

Шуннан соң иле тынычланып кала. Тәлинкәләр турында уйлап бимазаланмагач, ул, аңлашыла ки, күкрәп алга ыргылыш ясый. 1952 елда ТАССР да өр-яңа нефть чыганагы табыла. Ул бүгенгә кадәр иң продуктив урынчалыклардан исәпләнә – Әлмәт турында бара сүз. Әлмәттә, чыганак барлыгы ачыклануга ук, Бораулаучы кадрлар өчен мәктәп ачып җибәрәләр, анда елына 100 ләгән бораулау, манара-монтажлау осталары, нефть белән газ табып алу буенча операторлар, электр-ябыштыручылар, монтажлаучылар, слесарьлар һәм нефть өлкәсенә караган башка белгечләр әзерләнә.

ТАТАРСТАН ӨЧЕН НӘРСӘ ЭШЛӘГӘН:

– Минем күпчелек эшләрем үзебезнең татар тематикасына – милли тематикага багышланган, – ди Александр. – Аларны циклларга бүлеп чыктым: Болгар ханлыгы, Казан ханлыгы, бүгенге Татарстан, татар халык әкиятләре, Тукай әкиятләре. Башка темалар да бар, билгеле, әмма аларның һәммәсе дә мин яратып өлгергән, үз иткән татарча техникада башкарылды һәм башкарыла. Гәрчә үземне нинди дә булса бер милләткә генә карый торган кеше дип исәпләмәсәм дә. Җир йөзендә милләтләр бихисап бит. Ә мин – Галәм кешесе. Эшләремне тудырганда күкрәк тутырып сулыйм, чын мәгънәсендә яшим, шуннан артык тагын ни кирәк?

ТОРМЫШНЫҢ ИКЕ МАГИСТРАЛЕ

Бүген резонанс тудырган, кешеләр китап кибетләреннән эзләп алып укыган әсәрләрне, Көнбатыш манерасына ияреп, бездә дә бестселлер дип атау гадәткә керде. Исемен алай атамасалар да, андыйлар бездә гомер-гомергә җитәрлек булган. Әйтик, Шәриф Хөсәеновның «Мәхәббәт сагышы» повесте. Хәбир белән Мәдинә тарихы – заман геройларыннан Гөлшаһидә һәм Мансурныкы белән бер чылбырда торган мәхәббәт кыйссасы ул. Ә инде драматургиясенә килсәк, «Зөбәйдә – адәм баласы», «Чулпан», «Профессор кияве», «Әни килде» пьесалары заманында театр дөньясын шаулаткан, сәхнәдән төшмәгән премьералар...

Фотолар Г. Камал театры архивыннан, «Шәриф Хөсәенов» җыентыгыннан алынды.

Әзерләде:
Луиза Янсуар

«СЕРЛЕ КЕШЕ», ЯКИ АЛЬТЕРНАТИВ ЯЗУЧЫ

Чор, заман тематикасы-проблематикасын үзәккә алып, аның чуалган төеннәрен чишеп күрсәтү белән беррәттән, мәңгелек, ә димәк ки, һәрбер чор кешесе өчен дә актуаль булган нәрсәләр турында сөйли бу әсәрләр. Шәриф Хөсәеновның психолог буларак осталыгы да үзенекен итә – ул кешеләрнең холык-фигыльләре, гамәлләренең тирәнтен сәбәпләре, күңел халәтләре белән бик нечкә тоеп эш итә. Шуңа да без, кайсы гына чорда яшәмик, аның Зөбәйдәсенең гасабилануларына ышанабыз, Ананың сабырлыгына сокланабыз, Сәмигулланың кысмыр беркатлылыгына шаккатабыз, Мәдинәнең соңгы очрашуда, Хәбирне үлеп яратса да, ни өчен аңардан китүенә аклау табабыз...

Гомере буена табиб булып эшләгән һәм язучылар «тусовка»сында кайнашуны тормышындагы төп максат-бурыч итеп куймаган Шәриф Хөсәенов фигурасы башкаларныкыннан шактый аерылып тора. Юкка гына язучы Фәнис Яруллин үзенең аңа багышланган эссесын «Серле кеше» дип атамагандыр. Ул эсседа сурәтләнгән вакыйгалар язучы-драматургның характерына, «менә монысы – бу ишектән, монысы – икенчесеннән» дип, кайбер ачкычлар бирә.

Шәриф беренче карашка тупас булып күренергә мөмкин. Ләкин аның күңелендә балалык ята. Ул матурлыкка соклана, тик, янында кеше торганын күрсә, исе китмәгән кеше кебек, йөзенә битарафлык чыгара иде.

Фәнис Яруллин

Ул һәрвакыт перифериядә торган, үзе дә теләмәстән, күпмедер дәрәҗәдә альтернатив агымга караган иҗатчы булган, дигән фикер формалаша каләмдәшләренең Шәриф Хөсәенов турындагы истәлекләре белән танышкач. Һәм бу аның табиб профессиясенә – икенче өлкәгә нисбәтле булуына гына да бәйле түгелдер, миңа калса. Ә башкачарак уйлавына, фикер йөртүенә, язучылык даирәсенә дә читтән караш ташлау мөмкинлегенә ия булуына, бәлки. Шуңа да язучылар арасына барып кергәндә, ул «үзгә кеше», «читтән кергән» кеше булып күренгәндер. Үзе исә, бу мөнәсәбәтне тоемлаганга, битарафлык битлеге артына яшеренгәндер...

Хәер, зыялылыгы, затлылыгы белән дә күпләрдән аерылып торган, диләр Шәриф Хөсәеновны. Меломан, театрал, эстет... Гөлләр үстерә. Гөлләр күргәзмәсенә сирәк төрләр белән катнашып, җиңүләр яулый.

Шәрифнең үсмер чагы.
Зөһрә апасы һәм Гали абыйсының кызы Фирая белән.

«Шәриф Хөсәенов Казан театрларының һәммәсенә бик рәхмәтле булды. Ул Әнине беренче уйнаган Галимә Ибраһимованы бик яратты. Качалов театрында Әнине мәшһүр Валентина Павлова уйнады. Ә Тинчурин театрында куелган тамашада Әни ролен Исламия Мәхмүтова уйнап күрсәтте. Шәриф ул көнне Исламияне күтәреп кенә йөртте.

Шундый талантыбызга бездә әллә ни кадер-хөрмәт булмады. Шәрифнең Язучылар берлеге тарафыннан гел читтә тотылуы һаман аңлашылмый. 3–4 ел саен Мәскәүдә съездлар була торган иде. 30–40ар татар төялә дә китә бәйрәмгә, төялә дә китә. Алдан сайланган делегатлар, янәсе. Берсендә мин шул сайлауда тавыш күтәрдем: «Делегат булучылар! Сез бит инде бу юлдан туеп беттегез, берегез баш тартыгыз әле делегатлыгыгыздан, җибәрегез әле үз урыныгызга Шәрифне! – дидем. – Ичмасам, безнең бердәнбер илкүләм танылган драматургны СССР язучылары күреп калыр иде». Әй көлделәр, әй мыскыл иттеләр мине. Әлбәттә, берәү дә үз урыныннан баш тармады. Шәриф үзе бу бәхәсне белми дә калды. Чөнки ул язучылар җыенына йөрми иде. Бөтенесе: «Ул безне санга сукмый, врачлар арасында үзен иркенрәк хис итә», – дип уйлый иде. Шәриф исә, тыштан сер бирмәсә дә, үзенә карата күрсәтелгән игътибарны бик ярата, аңа бик тирәннән шатлана иде. Язучылар берлегендә җаваплы эшләрне Фәрваз Миңнуллин башкарганда, Шәрифкә «Почет билгесе» ордены бирделәр. Шул ук Фәрваз тырышлыгы белән аңа фатир да бүлделәр. И-и, аның ул чакларда шатланып йөргәннәрен күрсәгез! Сабый бала да ул кадәр шатлана алмыйдыр әле!

Камал театрына якынрак иде ул. Әсәрләрен сәхнәләштерү генә түгел, аны якын итү, үз күрү Шәриф Хөсәеновны бу театр коллективына ныграк тартты. Бәхеткә, аларны олылый белде».

Кояш Тимбикова истәлекләреннән.

ЯҢА ТЕМАЛАР, ЯКИ БӘХЕТЛЕ БИЛЕТ

Драматург, язучы, публицист Шәриф Хөсәенов 1929 елның 26 ноябрендә Татарстанның Буа районы Өчмунча авылында дөньяга килә. Туган авылында башлангыч мәктәпне тәмамлаганнан соң, җиде классны күрше Килдураз авылында укый, аннан 1947 елда Буа шәһәренең Мулланур Вахитов исемендәге урта мәктәбен тәмамлый. Казанга килеп, Казан дәүләт медицина институтының дәвалау-профилактика факультетына укырга керә. 1953 елда институтны тәмамлап, Казан шәһәре хастаханәләренең берсендә табиб булып эшли башлый. 1960–1962 елларда Мәскәүдә СССР Язучылар берлеге каршындагы Югары әдәби курсларда укый, әмма язмышын профессиональ язучылык хезмәте белән бәйләми. Казанга кайтып, яңадан табиблык эшенә керешә һәм гомере буена медицинага тугры кала.

Язучы-драматург буларак, Шәриф Хөсәенов киң катлам укучыга һәм тамашачыга «Профессор кияве» (1952) исемле комедиясе белән танылa. Шәһәр зыялылары, эшче яшьләр тормышына нигезләнеп язылган һәм гаилә, әдәп-әхлак, мәхәббәтнең бәһасе турындагы мәсьәләләрне үз эченә алган бу пьеса 50 нче еллар татар драматургиясенә яңа темалар, образлар, каһарманнар алып килүе белән үзенчәлекле. Андагы ситуациянең тормышчан булуы да күпләрнең игътибарын җәлеп итә. 1952 елда пьесалар буенча уздырылган республика бәйгесендә ул икенче урынны ала һәм, рәсми оешмаларның шактый кискен каршылыгына карамастан, идеологик яктан беркадәр кыскарту-төзәтүләргә дучар ителеп, шул ук елны Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт Академия театрында сәхнәгә куела. Яза гына башлаган һәм әдәби даирәләрдә әле танылып та өлгермәгән автор өчен театр һәм әдәбият дөньясына чын мәгънәсендә бәхетле билет була бу.

Драматургның бу беренче уңыштан соң иҗат иткән драма әсәрләре – «Зөбәйдә – адәм баласы» (1961) трагикомедиясе белән «Әниемнең ак күлмәге» (беренче исеме – «Әни килде», 1968) драмасы тагын да зуррак уңыш казана. Әлеге пьесалар, русчага һәм элеккеге СССР халыкларының унҗиде милли теленә тәрҗемә ителеп, илнең кырык сигез театрында куела. Һәр төбәк матбугатында куелган спектакльләргә резонанс бик көчле була. Бу пьесаларны заманча реаль яңгырашлы, җитди эчтәлекле, яңа тема һәм проблемаларны күтәргән әсәрләр дип табалар.



Өлкән апасы Мәгъсумә һәм аның кызы Роза белән.

Тәүге һәм бердәнбер мәхәббәте Зөлфә белән Ленинградта очрашкач.

Армиядә хезмәт иткән чактагы хезмәттәш дусты белән.

Яшь язучыларның III Бөтенсоюз киңәшмәсе. Шәриф Хөсәенов (икенче рәттә уңнан өченче) ишеткәннәрен теркәп бара.

«Без мәктәптә укыган чакта ук Шәриф Хөсәенов танылган шәхес иде, аның «Профессор кияве»н без авылдан авылга йөреп карадык. 1956 елда без, Мәскәү театр училищесына укырга керер өчен, Камал театрына җыелдык. Безне котларга, озатып калырга дип ике ир-егет килде. Икесе дә бик пөхтә, матур киенгән. Икесе дә төп-төз. Артык пөхтә киенгәне композитор Рөстәм Яхин булып чыкты, анысы тыйнак кына, сүзсез генә басып торды. Яхшы киемнәрен юри бераз кыйшайтыбрак кигәне, мут күзлесе, кырыс тавыш белән сөйләүчесе, үзенә нык ышанган кыяфәтлесе драматург Шәриф Хөсәенов иде. Шәриф абый, барыбызны да җитди карашы белән күздән кичерде дә, Дунай янына килеп:

– Шәп егет алгансыз! Буе, сыны, төсе-бите чибәр... Котлыйм сезне, сез укып кайтуга мин яңа пьесамны өлгертермен. Рөстәм абыегыз аңа музыка язар... Сезгә уңышлар телибез, – кебегрәк сүзләр сөйләгәне хәтердә калган.

Чыннан да, вакытлар узгач, «йомычкалылар» (Мәскәүдәге Щепкин исемендәге мәктәпне тәмамлаган артистлар – авт.) Шәриф абыйның спектакльләрендә еш уйнадылар. Ул пьесаларда уйнап, алар дан казанды».

Рабит Батулла истәлекләреннән.

Шәриф Хөсәеновның «Бирнәле кыз», «Чулпан», «Егерме ел үткәч», «Туган көнең котлы булсын, Кадрия!», «Генеральная уборка» (русча язылган), «Безнең подъезд төбе» кебек телевидение өчен язылган кече күләмле пьесалары да бар. «Егерме ел үткәч» дигәнен Мәскәү телевидениесе күрсәтә, ул «Искусство» нәшрияты бастырып чыгарган «Бер актлы совет пьесалары антологиясе»нә дә кертелә.

Тәнкыйтьчеләр фикеренчә, Шәриф Хөсәеновның пьесалары композицион яктан оста корылган булуы, кеше образларының җетә сурәтләнүе, конфликтның яхшы эшләнгән булуы белән аерылып тора. Тормышта, яшәештә совет системасы кысаларында килеп туган әхлакый мәсьәләләрне кискен куеп хәл итүе белән үзенчәлекле. Шәриф Хөсәенов иҗатка килгән генә елларда әле «кызыл режим» хөкем сөрә. Әмма ул, татар әдәбиятының икенче бер классигы Әмирхан Еники кебек үк, курсны гомуми проблемаларга һәм мәңгелек асылга таба ала, беркайчан да рәсми идеология рупоры булмый. «Кызыл» тематикадан бигрәк, кешеләрнең холык-табигатенә үтеп кергән әхлаксызлык, әшнәчелек, торгынлык елларында киң таралыш алган бюрократизм, мещанлык, эгоизм кебек сыйфатлар борчый аны. Ул табигате белән саф булган адәм баласының җәмгыятьтәге киртәләргә юлыгып, эчтән бозылуы, черүе турында сүз алып барырга ярата. Аның Зөбәйдәсе, әгәр дә тирәннәнрәк уйлап карасак, безнең һәммәбезнең беренчел садәлеген сагынып сөрән салуы, ачыргаланып кычкыруы ул...

Мещанлык турында

«Гидра кебек яшәүчән нәрсә бит ул мещанлык! Һәр турамыннан бер яңа гидра үсеп чыга.

Менә минем бер танышым. Өй тулы келәм һәм палас – түшәмгә генә элмәгән. Театрга йөрми. Телевизор караштыргалый. Төслесен, әлбәттә! Әле бала тумаган – аңа инде пианино алып куйдылар. Хрустальнең модада икәнен белеп алгач, бөтен өен хрусталь белән тутырды. Сервантка сыймады – карават астында ята. Кунаклар килгәч, барысын да чыгарып күрсәтә ул аларның, әлбәттә.

Юләр түгел, аңлый ул. Эчендә буш икәнен дә белә. Тик тәрбиялим димә инде аны. Киресенчә, ул үзе башкаларны «тәрбияләргә» мөмкин. Миңа килгәч, ул чыраен сытып, беләсезме, ничегрәк сүз башлый:

– Син нинди институт бетердең әле? Икеме? Ә мин менә өч класс бетердем. Тик миндә...

Икенче иптәшләр машина алды. Аннан машинага утыртырга шәп нәселле эт тә кирәк булды. Бик зур мәшәкать белән, озак чират көтеп, ниһаять, колли овчаркасы сатып алдылар. Коньякка барып кайттылар. Тәрәзәдән колли карап бара инде! Хәзер алар өчен бар да бик мөһим: выжылдатып кайтып кергәнне кем күрде, кузгалып киткәндә кем карап калды?

Менә кримплен күлмәкләр чыкты бит инде. Бер уйласаң, матур, киеп туздыра торган да тү-

Яшь язучыларның III Бөтенсоюз киңәшмәсендә катнашучы Татарстан делегатлары. Утырганнар (сулдан): Р. Төхфәтуллин, Г. Бәширов, Х. Госман, Р. Шәйхетдинов; икенче рәттә: Х. Камалов, Ш. Хөсәенов, Ю. Малевинский.

гел. Мин үзем дә шул шаукымга бирелеп костюм алып ташлаган идем. Кыш көне кисәң – туңдыра, җәй көне – эссе. Дөрес, мине тынычландырдылар – киеп йокласаң да була, таушалмый дип. Тик мин алай бай түгел, киеп йоклар өчен 180 сумлык костюм алырга!

Ә тормыштан шатлык табуны мин мещанлык дип санамыйм. Мин менә кактуслар үстерәм. Сезнең өчен кактус берни дә түгелдер. Ә миндә аның 600 ләп төре бар. Шуларга бер «Жигули» акчасы кереп киткәнен белгән кешеләр мине юләргә саный...»

Шәриф Хөсәенов белән Рәфикъ Юныс әңгәмәсеннән.

ӘДӘБИ БЕСТСЕЛЛЕР, ЯКИ «МӘХӘББӘТ САГЫШЫ»

Шәриф Хөсәеновның гомере буена йөрәгендә йөрткән мәхәббәте Зөлфә турындагы легенда әдәби мохиттәгеләр өчен яхшы таныш. Рәйсә Юсупова, язучының архивларына нигезләнеп, матбугатта аның актриса Рауза Уральская белән хатларын да бастырды. Бу мәхәббәт тарихы, актер Шәүкәт Биктимеров сөйләвенчә, «Профессор кияве»н әзерләгәндә яралган булган, әмма озак дәвам итмәгән. Дөрес, арада дуслык, иптәшлек тойгысы сакланып калган. Рауза Уральская хатларында язучыга булган тирән ихтирам, соклану ярылып ята: «Мин сине язасың дип ишеттем. Ничек әйбәт! Мин бик-бик шатмын. Язмаска синең хакың юк. Яз, син язарга тиеш, чөнки табигать сиңа бөтенесен дә, бөтенесен дә биргән! Мин сиңа уңышлар телим. Шайтаныма олак, диярсең, билгеле, әмма хат яз...» – дигән юллар бар аларның берсендә.

Зөлфәне гадәттә Шәриф Хөсәеновның «Мәхәббәт сагышы» әсәре героинясы Мәдинәнең прототибы дип кабул итәләр. Шәриф Хөсәеновның гомерлек дусты – Казан медицина институтында бергә укыган сабакташы Суфия Мифтахова искә алганча, Рауза исә – Баязитованың прототибы. Ә менә Хәбирне язучы дусты Рөстәм Яхиннан күчереп «язган» дип фаразлыйлар. Шулай итеп, бер әсәрдә тулы бер галерея җыела, дисәк тә була. Суфия Мифтахованың «Шәриф белән Зөлфә арасындагы мәхәббәт Рауза аркасында чәлпәрәмә килде», – дигән сүзләрен теркәп калдыра Рәйсә Юсупова истәлекләрендә.

Егерме ике яшендә Камал сәхнәсендә беренче пьесасы куелу шаукымыннан башы әйләнгән Шәриф Хөсәеновның үз чалымнарын да «укый» алабыз лабаса романда. Фактларга караганда, Шәриф Хөсәенов барысын да төгәл кертеп җибәрә әсәр тукымасына: Зөлфә, Мәдинә шикелле үк, кияүгә чыгып, Ерак Көнчыгышка китеп бара. 1956 елда алар яңадан күрешәләр дә кабат аерылышалар. 1957 елда Рауза Уральская вафат була. «Мәхәббәт сагышы» исә укучы кулына 1958 елда килеп керә. «Үзем белән Зөлфә язмышын, дөресрәге, язмышларның башын Хәбир белән Мәдинә образлары аша сөйләдем инде...» – ди бу хакта язучы үзе. «Кадерле кешеңнең исемен кычкырып йөрмисең аны, ул йөрәктә саклана», – дигән сүзләре дә бар аның.

Суфия Мифтахова Шәриф Хөсәеновның бу ике мәхәббәтенә кагылышлы тагын бер эпизодны искә ала: шулай берсендә, институтны тәмамлаучылар очрашуында, Зөлфә Шәриф Хөсәенов турында сораштыра. Бу хакта Шәриф Хөсәеновның үзенә әйткәч, ул Зөлфә кияүгә чыккач, ничек тетрәнүен, Рауза үлемен бик авыр кичерүен ассызыклап, китапка ымлый: «Яраларны ачасым килми... Алар икесе дә шушында...»

Зөлфә Хәбибуллинаның Приморье краеннан язылган беренче хатында 1955 елның 20 май числосы торса, очрашуга чакырып Казаннан язылганында – 1956 елның 28 феврале саны. Менә ул хаттан өзек:

«Исәнме, Шәриф!

Мин һаман синең белән очрашу хакында хыялланып яшәдем.

Табын корып күңелле очрашулар уздыру – шул чорның матур бер гадәте. Сулдан уңга: Аяз Гыйләҗев, Илдар Юзеев, Шәриф Хөсәенов.

Табиб Шәриф Хөсәенов (артта, сулдан беренче) коллегалары белән.

Инде менә андый мөмкинлек туган иде. Әмма очрашуның минем өчен ни-нәрсә икәнен уйлап, мин бу хыялымнан баш тарттым. Тик ерактан гына булса да сине бер күрү теләге миннән көчлерәк булып чыкты. Һәм шушы кечкенә генә теләгем өчен дә язмыш мине аямады: без кара-каршы очраштык (хәтерләмим, синең сәламләвеңә җавап бирдемме икән).

Минем сине күрәсем килә. Вакыт таба алсаң, билгеле. Минем өчен бердәнбер җайлы көн – ул бүген. Иртәгә ирем Рөстәм киләчәк, гәрчә минем аңардан яшерен серләрем юк – почти юк...

Җавабыңны көтәм.

Сәлам белән, Зөлфә».

Бу хатлардагы өслүб, фикер сөреше – Мәдинә хатына бик тәңгәл.

«Шәриф шук иде, җор сүзле, чәнечкеле телле, үртәшергә яратты. Боларның барысы да – бер ширма: үзенең йомшак күңелле, игелекле, рәхим-шәфкатьле, намуслы, миһербанлы булуын яшерер өчен битлек кенә. Ул һәр көзне капчыгы-ние белән көнбагыш сатып ала иде. Кыш дәвамында песнәкләрне сыйлый. Балконында очына-очына, сызгыра-сызгыра көнбагыш чүпләүче шул песнәкләрне сәгатьләр буе күзәтүе, ул чактагы уйчан-сагышлы карашы – йөрәк төбендә. Ә эчке дөньясына ул берәүне дә якын җибәрмәде».

Марсель Сәлимҗанов.

«Шәриф абый бик тә үзенчәлекле шәхес иде. Зәвыклы шәхес. Табиб буларак, аны табиблар да, авырулар да бик хөрмәт итәләр иде. Авыручылар табиб Шәриф Хөсәеновка язылырга тырышалар. Аның үзенең дәвалау алымнары бар иде кебек. Ул, дарулар алырга рецепт язуга караганда, авыруларга күбрәк психологик яктан тәэсир итүне хуп күрә иде. Әйтик, ул хаста кешене «песием»ләми, аңа кырысрак булырга тырыша.

Бер хастаханәдә кырык ел табиб булып эшләгән Шәриф ага врачлар арасында бик зур абруй казанган шәхес иде.

Ул музыка, опера өлкәсендә алыштыргысыз тәнкыйтьче. Юк! Бер генә операны да калдырмый, кат-кат тыңлый, бигрәк тә чит илләрдән килгән җырчыларны тыңлый. Шәриф ага татар операсындагы кимчелекләр, җитешсезлекләр турында олыдан кубып, рәнҗеш катыш ачыну белән сөйли иде. Халык тарафыннан танылган атаклы җырчыларны да ул күз алларында да, артларында да тәнкыйтьли иде. Җырчы берәр урында «әтәч» кычкыртса, залдан ук чыгып китә торган иде. Дөрес башкармаган өчен ул Җик Мәргәнне җырлаучы атаклы артистның тетмәсен тетеп ташлады:

– Алла биргән тавышыңа гына ышанып ятасың, эшләмисең, тырышмыйсың, акча түләп килгән халыкка син «карт әтәч» пешереп бирәсең. Йөрмә җырчы булып. Син бу партияне тарталмыйсың!

Гомумән, Шәриф ага сәнгатьчеләргә дә, язучыларга да бик кырыс, таләпчән булды. Ул ташламалар ясый белми иде. Шуңа күрә аның дуслары да күп булмады. Язучылар белән якыннан аралашмады, ул аны болай аңлата иде: татар язучылары арасында югары сәнгать, фәлсәфә турында сүз куерта алырлык әзерлекле кешеләр аз.

Язучыларның күбесенең әсәрләрен ачы тәнкыйтьли, интеллектуаль булмаган язучыларны җене сөйми. Ул үз фикерен кемнең кем булуына карамастан ярып сала иде.

Шәриф абыйның өе тулы чәчәк аткан кактуслар иде. Аларга багып сокланмаган кеше булмагандыр. Аеруча сокланган кешегә ул:

– Ошадымы? Ошаса, мин аны сиңа бүләк итәм! – ди торган иде.

Китәргә җыенгач, кунак сораса:

– Мин аны сиңа биреп җибәрә алмыйм, чөнки син кактус тәрбияли торган кеше түгел, ул синең өеңдә тончыгып үләчәк! Торсын шушында, мин аны үзем тәрбияләп торырмын. Килгәләгәндә сокланырсың. Кабат чакырсам! – ди.

Башка берәр кунак озак кына шул гөлгә карап сокланып торса:

– Ошадымы? Ошаса да мин аны сиңа бүләк итә алмыйм... Чөнки мин аны инде Аяз Гыйләҗевка бүләк иттем! – ди.

Аның бөтен матур кактуслары «бүләк ителгән» иде».

Рабит Батулла истәлекләреннән.

«Әни килде» иң шәп татар пьесаларының берсе. Шәриф үзе дә: «Аннан начаррак әйбер язарга хакым юк, ә яхшырак итеп мин инде яза алмыйм», – ди».

Марсель Сәлимҗанов.

«ЧӘЧӘКЛӘРГӘ КҮМЕЛЕП КИТӘМ...»

Шәриф Хөсәенов тормышындагы ике магистраль – табиблык һәм язучылык. Ул аларга гомере буена бертиң тугры булып кала. Матбугатта юмористик, сатирик хикәяләре, публицистик мәкаләләре белән дә чыгыш ясап тора. Аның җәмгатьчелектә шау-шу кубарган проблемаларга карата язылган

«Зөбәйдә – адәм баласы», «Әни килде» спектакльләреннән күренешләр.

«Мин бәхетле, сәхнәдә, тамашачым каршында, чәчәкләргә күмелеп китәм...» – ди драматург соңгы премьерасында.

мәкаләләре, сәяси-иҗтимагый мәсьәләләр буенча Михаил Горбачевка, Никита Хрущевка, «Огонек» журналына язган хатлары да мәгълүм.

Шәриф Хөсәенов 1979 елда «Почет билгесе» ордены белән бүләкләнә. Ул «Татарстанның атказанган табибы» дигән мактаулы исемгә дә лаек.

1999 елның июнь аенда Шәриф Хөсәеновны Республика клиник хастаханәсенә салалар. Аяз Гыйләҗевның тормыш иптәше Нәкыя Гыйләҗева истәлекләрендә иренең Шәриф Хөсәенов янына баруы турында яза. «Шәриф һаман шаярып сөйләшә әле ул», – дигән була ул чакта инде үзе дә авырлык белән генә йөргән Аяз Гыйләҗев, хастаханәгә барып кайткач. Хастаханәдән драматургны өенә алып кайту хәстәрен Камал театрының ул чактагы директоры Шамил Закиров күрә. Тиз арада Шәриф Хөсәеновның «Әни килде» әсәрен яңадан сәхнәгә әзерлиләр, 70 яшьлек юбилей хәстәрен күрә башлыйлар. Юбилей, чынлап та, киң колач белән уза.

Шәриф Хөсәенов 70 яше туларга биш ай кала, 1999 елның 7 июлендә Казанда вафат була. Гомере буе кактусларны чәчәк аттырган әдипне чәчәкләргә күмеп озаталар...

«Спектакль тәмам. Тамашачы Авторны чакыра. Тамашачы Авторны көтә. Һәм менә ул... үләр өчен кыя башын салган бөркет кебек, үзе өчен кыяга әверелгән сәхнә түрендә, үз гаиләсенә әйләнгән театрында, дуслары, артистлар арасында, чәчәк бәйләмнәре уртасында, үзен аягүрә каршылаучы тамашачысы каршында – горур башын тагын да югарырак чөйгән.

Ә дүрт-биш минуттан соң сәхнә артында, сеңлесе Наза ханым белән Суфия ханым аның манма су булган күлмәген сыккан арада, үзенең дусты – режиссер Марсель Сәлимҗановка ул: «Мин бәхетле, слушай, сәхнәдә, тамашачым каршында, чәчәкләргә күмелеп китәм бит, – диярргә һәм: – Шушылай, минем кебек, аяк өсте үлүче, йә, тагын кем бар?!» – дип шукланып алырга да көч табачак».

Рәйсә Юсупова истәлекләреннән.

Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин драматургны һәм Камал театрының иҗат коллективын «Әни килде» спектакле премьерасы белән котлый. 1999 ел.

ИГЪТИБАР: ХӘВЕФЛЕ ЗОНА!

2019 елгы китап премьералары арасында бу ике китап шактый нык аерылып тора. Нон-фикшн жанрында язылып, халыкара резонанска ия булулары белән генә түгел, юк, беренче чиратта, алардан килгән сигнал беләндер. «Игътибар: хәвефле зона!» дигән мөһер сугылган аларга гүя.

«АНЫ МИҢА АК ТӨС ХӘТЕРЛӘТӘ...»

НАДИЯ МУРАД. ПОСЛЕДНЯЯ ДЕВУШКА. ИСТОРИЯ МОЕГО ПЛЕНА И МОЁ СРАЖЕНИЕ С ИСЛАМСКИМ ГОСУДАРСТВОМ.

Без бүген чагыштырмача тыныч тормышыбызга бернинди тышкы факторлар янамаган заманда яшибез шикелле тоела. Беренче карашка, бу чынлап та шулай. Баш очында бомбалар шартлап тормый, авыр физик хезмәт белән изелмибез, иртәгә кем ишек шакыр да, кемне бүтән кайтмаска алып чыгып китәрләр икән, дип сискәнмибез. Дөрес, башларыбызны смартфон экраннарыннан сирәк күтәреп, әйләнә-тирә дөньяга күз ташлаудан читләшә башладык. Ә ул дөньяда, асылда, төрле хәлләр бар...

Надия Мураднның 2016 елда, ә рус теленә тәрҗемәдә 2018 елда дөнья күргән китабы җәмгатьчелектә зур шау-шу кубарды. Безнең «тынычлык» дигән иллюзияләребезнең чынлап та иллюзия генә икәнлегенә янәдән инандырды. Надия Мурад тарихына кадәр без инде Интернеттагы яңалыклар тасмалары аша Ламия Аджи Башар турында ишетеп белә идек. 18 яшьлек Ламия Аджар ДАИШ (Россиядә тыелган ислам дәүләте – ред.) контрольдә тоткан территориядән дүрт мәртәбә качарга тырыша. 2016 елның мартында, ниһаять, үз теләгенә ирешә: 20 яшьлек Катерина һәм 8 яшьлек Алмас белән алар территориядән качып чыгып китәләр. Әмма Ламия үзе генә исән кала, аның белән качкан ике кыз, минага эләгеп, һәлак була. Ламиянең йөзе шартлаудан барлыкка килгән җәрәхәтләрдән төзәлеп, мәңгегә җөйле булып кала, ул бер күзеннән дә мәхрүм була. Гыйракның төньяк районнарына барып чыккан кызны курд хәрби көчләре гаиләсе белән кавыштыра. ДАИШ (Россиядә тыелган ислам дәүләте – ред.) территориясендә хәрбиләр кулында Ламиянең 9 яшьлек сеңлесе кала. Хәзерге көндә Ламия – Германиядә.

Кайбер езидларга ДАИШ (Россиядә тыелган ислам дәүләте – ред.) әсирлегенә эләгеп, хәрбиләрнең җенси коллары ролен үтәргә дучар ителгән кызларын һәм хәрби тренировкалар уздырыла торган лагерьларда үлемгә хәстәрләнгән улларын сатып алу бәхете елмая. Әмма моның өчен зур акчалар һәм көч, яхшы элемтәләр таләп ителә. Акчалар күчерелеп тә, колларны азат итүләренә бернинди гарантия юк. Төгәл саннар – шулай ук. Моны боевиклар үзләре генә беләсә...

> 2016 елның җәендә БМО ның Махсус комиссиясе, Сүриядәге, Гыйрактагы хәлләрне анализлап, ДАИШ (Россиядә тыелган ислам дәүләте – ред.) езид халкына карата кылган гамәлләрен массачыл геноцид дип таныды.

ДАИШ (Россиядә тыелган ислам дәүләте – ред.) террористлар оешмасы әгъзалары Гыйракта җенси коллар сату эшен нигездә популяр булган ябык мессенджерларның каналлары аша башкара. Әйтик, менә шушындый игълан: «Гыйффәтле кыз. 12 яшьтә. Бүгенге бәясе – 12 500 доллар. Тиздән сатылачак. Алырга ашыгыгыз». Фото да урнаштырылган, әлбәттә. Шунда ук корал һәм хәрби эпикировка сату турында да язышалар. Боларына җитдирәк якын киләләр, монысы бит җенси уеннар гына түгел. Икешәр-өчәр балалы яшь аналарны сату турында да хәбәрләр «йөргәли»: нибары 200 долларга гына. Балалар, үсә төшкәч, тренировка лагерьларына озатыла, шуңа алар да күрсәтелгән хакка керә. Хуҗа аларны үзенә күрә аванс белән сатып ала, дигән сүз.

2014 елда езидлар этносының меңләгән вәкиле ДАИШ (Россиядә тыелган ислам дәүләте – ред.) боевикларына әсирлеккә төшә. Мондагы кызларның кайберләре кача, аларга гарәп һәм курд контрабандачылары ярдәм күрсәтә, 130 лап хатын-кызны ай саен хәвефсез урынга чыгаралар. Әмма монысы да һәр яктан хәтәр эш: чөнки һәр сатылган хатын-кызның – хуҗасы, шулай ук боевикларның җенси колларны исәптә тоткан махсус базасы бар. Блокпостлар аша узганда, хатын-кызны танырга, кабат хуҗасына кайтарырга бик мөмкиннәр. Ә инде кайтарылган очракта аны авыр җәза көтә.

2014 елда ДАИШ (Россиядә тыелган ислам дәүләте – ред.) территориясендәге чираттагы езид – Надия Мурад кача. Очраклы кешеләр ярдәме белән ул Киркукка барып чыга – качкыннар лагерендагы абыйсы белән күрешә. Соңрак Дахук лагерена эләгә. Ә аннан, үзе кебек башка 1000 качкын белән бергә, Германиягә юл ала. Надия Мураднның эшен халыкара конфликтлар белән шөгыльләнүче атаклы Британия юристы Амаль Алмуддин (ир фамилиясе буенча Амаль Клуни) кабул итә. Чыгышы белән ливанлы булган Амаль нәкъ менә этник конфликтлар буенча махсуслаша. Надия эше халыкара резонанс ала. Амаль, дөньякүләм танылган тормыш иптәше Джордж Клуни бәйләнешләрен дә эшкә җигеп, Надия ситуациясен бөтен җир йөзендә белүләренә ирешә. Надия Мурад китабына кереш сүзне дә Амаль Клуни үзе яза.

> *Надия Мурад минем өчен клиент кына түгел, ә дус та. Безне Лондонда беренче тапкыр таныштырганда, ул миннән аның адвокаты булуымны үтенде. 2014 елда ДАИШ (Россиядә тыелган ислам дәүләте – ред.) боевиклары аларның Гыйрактагы авылына бәреп керә. Надия әле ул вакытта 21 яшьлек студент кыз гына була. Надия үз күзләре*

Автор:
Луиза Янсуар

Фотолар: https://www.livelib.ru/ һәм https://www.goodfon.ru/ сайтларыннан алынды

белән әнисен үтерүләрен күрә, аның абыйларын атарга алып китәләр, үзен исә боевиклар бер-бер артлы сатып ала һәм мәсхәрәли.

Мәсхәрәләр алдыннан Надиягә дога укырга боералар, бизәнергә кушалар. Ул миңа тәнендәге тәмәке басып көйдергән эзләрне, кыйнаудан, җәберләүдән калган җөйләрне күрсәтте. Боевиклар аны «пычрак кяфер» дип мыскыллый торган була. Алар езидларны һәм аларның «дөрес түгел» динен тиздән җир йөзеннән сөрәчәкләре турында әйтеп мактана.

Надия – ДАИШ (Россиядә тыелган ислам дәүләте – ред.*) махсус әзерләнгән базарлар аша кайчак нибары 20 долларга гына саткан меңләгән езид хатыннарының берсе. Аның әнисе җәберләп үтерелгән олы яшьтәге 80 езид хатынының берсе, бу хатыннарны уртак кабергә тутырып күмәләр. Надиянең алты абыйсы – бер көн эчендә атып үтерелгән йөзләгән езид ирләре исәбендә.*

Надия миңа сөйләгәннәр – чын геноцид. Ә геноцид бер дә юктан, буш урыннан гына килеп чыкмый ул. Аны алдан уйлап, җентекләп планлаштыралар. Геноцид башлар алдыннан ДАИШ ның (Россиядә тыелган ислам дәүләте – ред.*) «Фәтваны өйрәнү департаменты» езидлар мәдәниятен яхшылап анализлап чыга һәм мондый нәтиҗәгә килә: езидлар, курдча сөйләшә торган, Изге Китаптан мәхрүм халыкларның берсе буларак, кяфер дип саналырга тиешле. Димәк, аларны әсир итеп алу һәм ДАИШ (Россиядә тыелган ислам дәүләте –* ред.*) вәкилләре тарафыннан нинди дер максатларда файдалану да шәригать кануннарына туры килә торган гамәл. Димәк, көч куллану бу очракта аклана, хәтта ки хуплана да, диган карашта тора департамент вәкилләре.*

Мин, Надия белән танышканнан соң, аның тавышы ачылганга, рухы калкыганга сөенәм. Надия тавышы – XXI гасырда геноцидтан интеккән тулы бер халыкның, этносның, һәр мәсхәрәләнгән хатынның авазы булып яңгырый. Бу тавышны буарга теләүчеләр теләгәнә ирешә алмады. Ул кем булырга икәнен үзе хәл итте. Надия – мәхшәрдән исән калучы. Бүген инде – Нобель премиясе лауреаты. БМО илчесе. Һәм шушы китап авторы.

Китапның титул битенә акка кара белән язып куелган: «Барлык езидларга да багышлана». Эксмоның Truestory («Правдивая история») сериясендә дөнья күргән китабы өчен 2018 елда Надия Мурадка Нобельнең «Тынычлык миссиясе» премиясе тапшырылды. «Мин җир йөзендәге мондый тарихка дучар булган соңгы хатынкыз булырга телим», – дип игълан итте Надия Мурад. Америка хакимияте белән Евросоюзга ярдәм сорап мөрәҗәгать иткән тәвәккәл бу ханым бүгенге көндә халыкара терроризм турында ачыктан-ачык сөйли, очрашуларга йөри, лекцияләр укый. Дөньяны бу мәсхәрәдән коткарырга телим, ди ул, безнең заманда шушындый хәлләрнең бөтен җир шарындагылар күз алдында эшләнүе һәм кешеләрнең белмәмешкә салынуы, күзләрен яшерүе – моны туктатырга кирәк.

Китапның җете һәм калку тасвирланган детальләргә корылган булуы шаккатыра: авыр да аны укуы, рәхәт тә. Үтә нечкә, лирик дулкында башланып киткән бу тарих тыенкы рәвеш ала, салкын акыл белән ясалган анализ белән керешеп китә. Үзен ничек мәсхәрәләүләрен язганда, Надия Мурад кием, интерьер детальләрен сурәтли – җентекләп, һәр җебенә, һәр бөртегенә, һәр табына кадәрле. Һәм син үзеңне шул мыскылланган хатынның үзаңына күмелгәндәй хис итә башлыйсың: бәлки, кеше андый шартларда, түзәр, акылдан шашмас өчен, уен башкага күчереп кенә котыла аладыр. Нәрсәгәдер юнәлтеп: әйтик, киемдәге сүтеккә, бөтерелгән җепкә... Йоклар өчен бәтиләр санарга, аларны башта, күз йомып, күзалларга кушалар иде бит балачакта...

Бу китап кешенең Ватанына чын мәгънәсендә дан җыры да, һәйкәле дә. Мине һәрчак Эмир Кустурица фильмнары белән Наринэ Абгарян китаплары сокландыра. Һәр икесе сугыш җәберләгән туган төбәкләрен шулкадәр яратып сурәтли ки – анда барып яшисе, һәр ташына орынасы, агачлардагы бөреләрнең исен тоеп карыйсы килә башлый. Җир йөзендә ул мәсхәрәләнгән урыннардан да матуррак берни юк шикелле... Бүген котылгысыз тизлектә үз йөзен сөртеп, гомумигә көйләнеп барган цивилизациянең бер тузан бөртеге кадәр генә кечкенә халкы – езидларны – Надия бар матурлыгында күрсәтергә омтыла. Менә бу – минем туганнарым, мин – шушы халыкның бер баласы, мин бу җир шарындагы искиткеч матур келәмнең бер бизәге, ди ул. Һәм без асылда җәбер вакыйгаларын укыганда түгел, ә аңа кадәрге тыныч тормышны сурәтләгәндәге детальобразлардан, фикер сөрешеннән аңлап алабыз: нинди зур җинаять бара без яшәгән дөньяда. Һәм без дәшмәвебез белән һәммәбез дә – анда катнашучылар...

«Аллаһ езидларны саклаячак», – дип кабатлый иде әнием безгә һәр көнне.

Без суешлар турындагы тарихларны ишетеп, тыңлап кына үстек, алар безгә куркыныч әкият булып кына тоела иделәр. Без бик бердәм идек, хәтта авылдагы ниндидер гауга, ызгышлар да бу бердәмлекне барыбер җимерми. Безнең авылда яшәүчеләр бер-берләренә кунакка йөрешә, керәп утыра, урамда гәпләшеп тора, – әйтерсең, һәммәбез дә – зур бер гаилә. Башка авыллардан килүчеләр безнең авыл турында: «Кочо караңгыда яктылык таратып утыра», – диләр иде. Минем Кочодан кала башка бер генә җирдә дә яшисем килгәне булмады. Мин Кочоны яраткан кебек башка бер генә җирне дә ярат мыйм. Мин картаймыш көнемә кадәр анда яшәсәм, нинди бәхетле булыр идем, дип уйладым һәрчак. Аны «Синджарның Парижы» дип атаганнарын да хәтерлим.

Егерме бер ел буе һәр иртәне мин мичкә көлчә чапылдаткан тавышка һәм үлән кушылган майның хуш исенә уяндым. Бу ис

һәм тавыш әнинең янәшәдә булуына ишарәләүче билгеләр иде. Әле караңгы булса да, аны ерып, тандырга киләсең, кулыңны җылытасың, сөйләшеп китәсең – мәктәп, туйлар, үзара талашулар, дуслашулар турында... Пешкән көлчәнең көйгән читләрен сындыра-сындыра, әнигә үскәч Кочода парикмахерская ачачагым турында сөйли идем.

Миңа әниемне һәрчак бер төс хәтерләтә. Ак төс ул. Тагын – әйбәт мәзәк, ул аны түмен белеп сөйли иде. Тавис (езидларның изге символы – ред.) – безнең өчен кадерле символ, кыска гына догалар, аларны мин, ул кошны күргән саен, гел пышылдый идем. Һәр иртәдә ул таң белән уяна да көлчә пешерә.

Безне кояшка таба борылып, дога кылырга өйрәткәнен хәтерлим. Иң ихлас догаларны мин храмда түгел, ә суган басуында укыганмындыр. Безнең халык доганы Аллаһ кайда да кабул итә дип ышана.

«Аллаһ езидларны саклаячак», – ди иде әнием...

«НӘРСӘ УЛ ХОЛОКОСТ?»
ТАРА ВЕСТОВЕР. УЧЕНИЦА. ПРЕДАТЬ, ЧТОБЫ ОБРЕСТИ СЕБЯ.

2018 елдагы Эксмоның тагын бер көтелгән басмасы – Тара Вестоверның үз язмышына багышланган «Ученица» әсәре. Дөрес, тәрҗемәдә ул мәгънәсен шактый югалта, дөресрәк тәрҗемә «Образованная» булыр иде, дип ассызыклый китап күзәтүчеләре белән тәнкыйтьчеләр. Инглизчә вариантта ул укучыга Educated исеме белән тәкъдим ителә.

Тара Вестовер исеме соңгы елларда киң җәмәгатьчелектә шактый еш яңгырый башлады. Китап сөюе һәм елга төгәл 50 китап укуы белән дан казанган миллиардер Билл Гейтсның бу язучыны атавы да хәлиткеч роль уйнады булса кирәк. Гейтстан еш кына нинди китапларга өстенлек бирүе турында сораштыралар. 2018 елда аның шәхси рейтингында беренче урында торучы китап Тара Вестоверныкы булып чыкты.

> «Минем быелгы исемлегем шактый эклектик, – диде Билл Гейтс, – әмма кызыклы һәм мәгънәле». Бу китапларны, шул исәптән «Ученица»ны да, ул Америка колледжларын тәмамлап чыгучыларга бүләк итте.

Нәрсәсе белән җәлеп итә соң бу әсәр? Беренче чиратта – Тараның биографиясе белән. Тара Вестовер 1986 елның сентябрендә Айдахо штатында, зур булмаган бер шәһәрчектә туа. (Бу урында хәтергә ирексездән Гас Ван Сетның кабатланмас һәм үзенчәлекле атмосферага күмә торган «Мой личный штат Айдахо» фильмы килә...) Бу шәһәрчектә барлыгы 234 кеше яши торган була. Тара биографиясендәге иң мөһим факт: ул туган гаилә – мормоннар гаиләсе. Үтә дә принципиаль мормоннар гаиләсе, дип төзәтмә кертү дөресрәк булыр. Бу гаиләдә дәүләткә карата соң дәрәҗәдә скептик караш хөкем сөрә. Дәүләт мәгарифенә дә, медицина хезмәтенә дә. «Федераллар» дигән сүз Тара өчен сабый чагыннан иң куркыныч сүз була. Алардан качу һәм эзәрлекләнү – аның дөнья моделе. Әтисе балаларга федералларның ничек итеп алар кебек ирекле һәм дөрес яшәүчеләрне юкка чыгарулары турында сөйли. Кайдадыр еракта түгел, ә күршедә генә. Әнә, мәсәлән, Тара балалары белән уйнаган берничә йорт аша күрше гаиләне, ди әтисе, федераллар камап алган да, гаилә башлыгын атканнар. Бу көннән үзләренә дә килергә мөмкин булуы турында даими хәтерли Тара, ул җиткәч, ничек итеп тауларга качып, анда яшәргә һәм исән калырга, дип план кора.

Әтиләренең идеологиясе буенча аларга авырырга ярамый, чөнки авырсалар, медицина ярдәме сорап, хастаханәгә бару тыела. Вестоверлар гаиләсендә балалар беркайчан да табибка бармый, аларны өйдә әниләре дәвалый. Альтернатив медицина тарафдары булган гаилә башлыгы балаларга туу турындагы таныклыкның да хаҗәте юк, дигән карашта тора. Шуңа Тара 9 яшенә кадәр Америка балалары базасында гомумән булмый. Теркәлмәгәч, аның барлыгын да белмиләр. Ә инде әнисе белән әбисе, талаша-талаша, ниһаять, баланы рәсми рәвештә теркәргә кирәк, дигән фикергә килгәч, аның төгәл туган датасын искә төшерә алмый интегәләр.

Тара, абыйлары һәм апалары шикелле үк, беркайчан да мәктәп бусагасын атлап керми. Аны укырга олы абыйсы өйрәтә. Әмма бу эзлексез укыту системасы аның белемгә омтылган зиһенендә ак тапларны шактый күп калдыра. Кызның укыйсы бик килә. Әмма аларның өйләрендә дәреслекләр дә, китаплар да булмый. Дәрес, имтихан тапшыру, инша язу – бу төшенчәләрне Тара гомумән белми үсә. Телевизор да юк. Алар – табигать балалары, ирекле затлар. Әтиләре өчен бу – какшамас канун. Күп еллардан соң, туган йортыннан чыгып китеп, дөньяда, тормышта үз лаеклы урынын тапкан Тара, әтисенең шәхесен анализлап, болай яза:

Без әтием белән храмга карап торабыз. Ул – Алланы күрә, мин – бары тик гранитны гына. Аннан без карашларыбызны бер-беребезгә күчерәбез. Ул – каһәрдән кала башка бернәрсәгә дә лаек булмаган бер хатынны күрә, мин – бәхетсез бер картны. Инанулары һәм канунннары белән үзен дә, тирәсендәгеләрне дә соң чиккәчә җәберләгән бәхетсез картны. Әмма ул барыбер тантана итә. Шул чакта мин Санчо Панса сүзләрен хәтергә төшерәм: «Илләр гизүче рыцарьны туктаусыз кыйныйлар, әмма ул үзен барыбер император итеп хис итә».

Тара Вестовер китабына төрлечә бәя бирергә була. Ул үзенә дә, язганына да тамгалар суктыру тарафдары түгел. Моны әңгәмәләрдә кат-кат ассызыклый. Бәя бирүне дә кирәкле шәй дип тапмый, нигездә. Аның максаты, киресенчә, күпмедер дәрәҗәдә акланугарак йөз тотмыймы икән әле – ул бит бу системаны җимереп чыккан зат, әтисенә һәм аның иманына «бу минем иманым түгел» диярргә базган гыйсъянчы. Әмма ничек кенә булмасын, бу – үзе дә ваемламыйча, балачагында даими рәвештә рухи җәрәхәт алып үскән кеше язмышының ватыклардан җыелган кыек көзгесе. Тукай да «Исемдә калганнар»да бәя бирмәскә омтыла, әмма һәр деталь, һәр вакыйга аның ярасы булып сөрән сала.

Укый гына башлаганда, син беркадәр романтика тоясың, вакыйгаларга ияләсең, геройларны читтән күзәтәсең. Әмма акрынлап Вестовер безне үзенең эчке үзаңына бөтереп алып кереп китә дә, син аның күзләре белән караганыңны, ул тойганнарны физиологик дәрәҗәдә тойганыңны абайлап аласың. Аның эчке җәрәхәтләреннән яңгырап торган авырту баштанаяк күмеп китә: юк, җөйләнмәгән алар, һаман да кан саркый, һаман да тартыша алар, сызлый. Бу тарихта шулкадәр көчле рәнҗү ярылып ята. Кичерәсе ничек кенә килмәсен, үзен ничек

кенә ышандырмасын, рәнҗү беркая китмәгән. Хәтер дә үзенең теркәүче ролен башкаруын дәвам итә, шуңа детальләр торган саен җетеләнә, рефлексия маятнигы колачын җәя бара.

Әтисенең аларны сак булырга әйдәве артында да асылда бары тик үз эгоизмы гына торганлыгын ваемлаган олы Тара әнә шул бәләкәй кызның – үзенең – берни аңламавын, белештермәвен дә кичерә алмый хәтта. Егылгансың, җәрәхәт алгансың икән – үзең гаепле, авыргансың икән – димәк, син ниндидер ярамаган гамәл кылып, фәрештәләреңне качыргансың, алар сиңа, кирәк чакта, ярдәм итә алмаган... Укый-укый бу логика акылдан яздырыр чиккә китереп җиткерә. Керфекләрен тушь белән буяган үсмер кызын «фахишә» дип атау да, абыйсының бу кызны еллар буе кыйнавы, мәсхәрә итүе дә, чүплек базындагы бер «эш» вакытында яралангач, кечкенә Тараның үзен гаепле итеп табуы, беренче тапкыр тетрәнү кичерүе дә... – бу манипуляцияләр чытырманын ерып чыга алган кешенең ничек итеп акылы зәгыйфьләнмәве зур соклану тудыра.

Двигатель сүнде һәм әтинең авыр адымнары миңа таба якынлашты.

– Нәрсә булды? – дип сорады ул, бер тезенә төшеп.

– Егылдым, – дидем мин, еламаска тырышып. Суларга һава җитми иде. Аркам үтереп авырта, әйтерсең, мине тере килеш урталай ярганнар.

– Йә, ничек булдыра алдың инде син моны? – дип сорады әти. Тавышындагы канәгатьсезлек өтеп алды. Мин үземне бернәрсәгә дә яраксыз кеше итеп тойдым.

«Бу хәл булмасын өчен барысын да эшләргә тиеш идем, булдыра алмадым, булдыра алмадым...», – диган уй бораулады миемне. Әти җәрәхәтне карады: алагаем зур кадак аягымны әйбәт кенә ярган иде. Ул аны тартып алгач, аягымда зур тишек аларып калды. Әти фланель күлмәген салды да, аккан канны каплады.

– Бар өйгә. Әниең канны туктатыр, – диде ул.

Мин чатанлап өйгә юнәлдем. Әти карап калды. Ул күздән югалгач, үләнгә аудым. Бөтен тәнем калтырый, үпкәләремә һава керми, диярсең, сулый алмыйм. Мин үземнең ник елаганымны аңлый алмаудан гаҗиз идем. Юк, авыртудан түгел. Мин бит исән. Бар да әйбәт булачак. Фәрештәләрем дә үзем белән икән. Алар мине коткарып кала алдылар бит, әнә. Ник соң мин тәнемдәге бу калтырауны баса алмый иза чигәм?!

Китапның инглиз телендәге атамасы гаять символик мәгънәгә ия: җәбер галәменнән ычкынып, укып, белем алып, үз галәмеңне төзер өчен, өр-яңадан туарга кирәк. Юкка гына әнисе кендек әбисе булып йөрми ләбаса Тараның. Ул яңадан туар өчен, коточкыч авырту бәрабәренә булса да, карыннан чыгып, бар көченә һаваны суларга кирәклеген яхшы белә. Суларга кирәк, ә аннан яшәп китәр өчен мөмкинлекләр артканнан-арта...

Үсмер яшенә җиткәч, Тара дәреслекләр сатып ала һәм үзлегеннән укый башлый. Мормон балаларын кабул итә торган колледжка барып эләгә. Беренче тапкыр чын дәреснең ни икәнен 17 яшендә белә.

Мин урманнан тотып алып кергән кыргый җәнлек кебек идем. Паникада булмаган бер генә мизгелемне дә хәтерләмим. Курыкмаган мизгелемне. Нәрсәнедер дөрес эшләмәм, диган уй эчтән кимерә дә кимерә. Ялгыш адымнан, ялгыш сулаудан да курка идем хәтта. Җәзадан. Аудиториядәге бөтен нәрсә дә котымны ала: боларны элек беркайчан да күргәнем юк лабаса...

Тарих буенча беренче дәрестә Холокост турында берни белмәве белән барысын да шаккатыра Тара. Коллык турында берни дә белмәве белән. Акрынлап ияләшә: тырышып-тырмашып көн-төн укый, үзен искиткеч яхшы студент буларак таныта. Тараның омтылышы һәм үсеше шулкадәр көчле була ки: имтихан күрсәткечләре Гарвардка яки Кембриджга юл ача. Хәтта – сайлау мөмкинлеге белән. Кембриджга ул Гейтс фонды стипендиаты буларак килә, аны бик тә уңышлы тәмамлый. 2014 елда 27 яшендә докторлык диссертациясе яклый, фәнни дәрәҗә ала. Әмма бу вакытта фән докторы Тара Вестоверның әле мәктәпне тәмамлавын раслаучы таныклыгы да булмый. Аның фәнни эше XIX гасырның утопиягә корылган берләшмәләренә багышланган була.

Хәзерге көндә Тара Вестовер үзе дә укыта. 2011 елда гаиләсе аңардан тулаем баш тарта. Китабы басылып чыканнан соң, «Ученица»ны дөньяның бик күп телләренә тәрҗемә иттеләр. Хәзер ул очрашуларга, күргәзмәләргә еш йөри, мормоннар тормышы турында сөйләгәндә, еш кына болай дип кабатлый:

Сез кемнедер үзәгегез өзелеп сагынырга мөмкинсез, әмма, шул ук вакытта, аны күрмәс өчен әллә ни бирергә дә әзерсез. Иң кыены – яхшы нәрсәләр турында язу иде. Югалтуларым турында. Мин әниемнең көлүен югалттым, без яшәгән җирдәге тауларның хозурлыгын. Аларны миңа берни дә алыштыра алмый. Мин үземне әле һаман да яраткан кешесенең туена килгән кунак кебек хис итәм.

ЯНӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

Реклама 16+

Безнең Инстаграмда – «Татарстан»ның йөрәге!

МАХСУС ПРОЕКТ

— *41нче чыгарылыш* —

Татарстан юбилярлары

Шамил Гафаров, ТР Премьер-министры урынбасары – ТР Министрлар Кабинеты Аппараты җитәкчесе, майда үзенең 50 яшьлек юбилеен билгеләп үтә.

Үз сүзендә торучы кеше

Сергей Демидов,
Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы башлыгы

– Хөрмәтле Шамил Хәмитович! Шәхсән үз исемемнән һәм Алексеевск районы халкы исеменнән күркәм вакыйга – 50 яшьлек юбилеегыз уңаеннан ихлас, җылы котлауларыбызны кабул итеп алыгыз!

Дәүләт хезмәтендә эшләгән елларда коллегаларыгыз Сезне киң күңелле, һәр гамәле төгәллек һәм эзлеклелек белән аерылып торган һәм башкарылган җаваплы җитәкче буларак белә. Җентекләп эшләргә күнеккән, актив тормыш позициясенә ия булган һәм үз эшенә ихлас бирелгән кеше буларак, Сез һәрвакыт уңышка ирешәсез. Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты җитәкчесе булып хезмәт итү елларында Сез үзегезне республиканың чын патриоты итеп күрсәттегез. Республика үсешенә, татарстанлыларның тормышын яхшыртуга юнәлдерелгән күпсанлы проектларны гамәлгә ашыруда зур уңышларга ирешеп, ныклы оештыру сәләтенә ия булуыгызны да раслап киләсез. Сезнең кебекләр турында халыкта «үз сүзендә торучы кеше» диләр. Күп еллар дәвамында республика иминлеге хакына Сезнең белән бергә эшләвебезгә без бик шат һәм моның белән ихлас горурланабыз.

Сезгә озын-озак еллар киләчәктә дә ныклы сәламәтлек, иминлек юлдаш булсын, барлык күркәм эшләрегез һәм ниятләрегез тормышка ашсын.

Фото Алексеевск муниципаль районы матбугат хезмәтеннән алынды

Компетентлылык һәм булышлык

Рөстәм Нуриев,
Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы башлыгы

– Хөрмәтле Шамил Хәмитович, Сезне Ютазы районы халкы исеменнән күркәм юбилеегыз белән тәбрикләргә рөхсәт итегез!

Бүгенге көн кискен сынауларны һәм кырыс таләпләрне шактый күп куя, аларны җиңү өчен җитәкче эшлекле, актив һәм инициативалы кеше булырга тиеш. Ә чын ир заты үзен һөнәри эшчәнлегендә тулысынча күрсәтә алганда гына чын-чынлап бәхетле. Профессионал буларак та, лидер буларак та әлеге сыйфатлар Сезгә хас.

Сез – үз сүзендә тора торган, булдыклы кеше. Сезгә мөрәҗәгать иткәндә һәрвакытта да аңлау, ярдәм табачагыбызга, Сезнең компетентлылыгыгызга ышанырга була. Бүген татарстанлыларның имин-мул тормышы, һичшиксез, Татарстан Хөкүмәтенең һәм республика муниципаль берәмлекләре вәкилләренең җайга салынган уртак эшчәнлегенең нәтиҗәлелегеннән тора. Һәм уртак эшчәнлекнең уңышлы тормышка ашырылуында, әлбәттә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты җитәкчесе буларак, Сезнең өлешегез гаять зур.

Сезне чын күңелдән туган көнегез белән котлыйм. Әлеге көн туганнарыгыз һәм якыннарыгыз янәшәсендә матур бәйрәмгә әверелсен, Сезгә шатлык-сөенеч һәм күтәренке кәеф бүләк итсен! Ныклы сәламәтлек, озын гомер, иминлек һәм уңышлар юлдаш булсын Сезгә!

Фото Ютазы муниципаль районы матбугат хезмәтеннән алынды

Яңа җиңүләр юлында

Азат Нигъмәтуллин,
Казан башкарма комитеты җитәкчесенең шәһәр төзелеше сәясәте буенча беренче урынбасары

Фото Казан башкарма комитетыннан алынды

– Хөрмәтле Шамил Хәмитович! Барлык Казан төзүчеләр җәмәгатьчелеге исеменнән һәм шәхсән үз исемемнән Сезне юбилеегыз белән тәбрикләргә рөхсәт итегез!

Республика гражданнары иминлеге турында көн саен кайгыртучанлык күрсәтеп, чишелеш юлларын дөрес оештырып, Сез каршыгызда торган бурычларны үтемле хәл итәсез. Нәкъ менә шуңа да Сез күп еллар дәвамында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты җитәкчесе кебек мөһим вазыйфаны башкарасыз да.

Сезнең кебек максатчан һәм энергияле шәхескә юбилеегыз уңышлы җиңүләр юлында һәм тирә-юньдәгеләрнең рәхмәтен ишетүдә чираттагы этап булып кына тора. Шәһәр һәм республиканың тотрыклылыгына һәм чәчәк атуына шул исәптән Сезнең фидакарь хезмәтегез һәм үз эшегезгә бирелгәнлегегез нәтиҗәсендә дә ирешелеп килә.

Зирәклек, эшне җиренә җиткереп оештыра белүегез Сезнең белән эшләп караган һәр кешегә яхшы билгеле. Сезнең закон мәсьәләләрендәге тел тидермәслек абруегыз да тирән хөрмәт уята. Бай тәҗрибәгез иң катлаулы бурычларны хәл итәргә һәм киләчәккә ышаныч белән карарга мөмкинлек бирә. Туган җир белән тыгыз элемтә, ныклы холык, шулай ук иң күркәм кешелек сыйфатлары Сезне исеме олы хәрефтән язылырга тиешле шәхес итеп күрсәтә.

Шамил Хәмитович! Сезгә алга таба да коллегларыгыз йөзендә – ышанычлы фикердәшләрне, ә өегездә имин тыл һәм гаилә җылысы табуыгызны телим. Сезгә бәхет, уңышлар һәм ныклы сәламәтлек юлдаш булсын!

Казанышлар юлындагы уңышлар

Леонид Анисимов,
«Грань» ЖЧЖ генераль директоры

Фото «Грань» ЖЧЖ нән алынды

– Хөрмәтле Шамил Хәмитович!

Сезне «Грань» ЖЧЖ төзелеш компаниясе коллективы һәм шәхсән үз исемемнән тормышыгыздагы күркәм вакыйга – юбилеегыз белән тәбрик итәм.

Премьер-министр урынбасары – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты җитәкчесе вазыйфасында җаваплы хезмәтегез елларында Сез хезмәттәшләрегез, партнерларыгызның гына түгел, ә республика халкының да ихтирамын яуладыгыз.

Бүген Татарстанда һәр гражданинга лаеклы тормыш шартлары булдыруга хезмәт итәргә тиешле шактый күп максатчан программа тормышка ашырыла. Хезмәтне оештыруга дөрес якын килә, алга карап эш итә белү, фидакарьлек һәм зур тырышлык Сезгә теләсә кайсы катлаулылыктагы бурычларны чишәргә, төбәкнең стратегик үсеше планын уңышлы рәвештә гамәлгә ашырырга мөмкинлек бирә.

Татарстан Республикасы сәнәгатьнең күп тармакларында, IT-сферада, социаль өлкәдә лидер төбәк позициясен саклап килә, бу Сезнең тырышлыгыгыз нәтиҗәсе дә. Республикада тормыш сыйфатын күтәрү һәм кешеләрнең иминлеген арттыру өчен бик күп нәрсәләр эшләнә: сәнәгать һәм авыл хуҗалыгы җитештерүе күләмнәре арта, җәмәгать урыннары үзгәреш кичерә, торак, социаль объектлар төзелеше – даими үсештә.

Тормыш юлыгызда Сезгә рухи яктан якын хезмәттәшләр, ышанычлы дуслар, чын фикердәшләр очрап торсын. Иң катлаулы бурычларны кыю рәвештә тормышка ашырганда таяныч булырдай кешеләрнең дә һәрдаим очравын телим. Фидакарь хезмәтегез алдыгызга куелган максатларга ирешергә булышсын, актив тормыш позициягез, тәвәккәллегегез белән кушылып, киләчәктә дә зур һөнәри уңышлар насыйп итсен!

Тынгы белмәс шәхес

Рәфкать Кантюков,
«Газпром трансгаз Казан» ҖЧҖ генераль директоры

– Хөрмәтле Шамил Хәмитович! Шәхсән үз исемемнән һәм «Газпром трансгаз Казан» Җәмгыяте коллективы исеменнән Сезне юбилеегыз белән котлыйм! Сезгә алдагы көннәрегезнең даими рәвештә күркәм вакыйгалар, күтәренке кәеф, күңелле сюрпризлар китереп торуын телим.

Даими үсеш кичергәндә генә чын уңышка ирешергә мөмкин икәнен яхшы аңлап, Сез бөтен көчегезне һәм энергиягезне камилләшүгә юнәлтәсез. Әйтергә кирәк, һәрвакытта да тиешле нәтиҗәгә ирешәсез һәм үз фикерегезне принципиаль рәвештә яклый беләсез. Сез республикада җитәкче һәм профессионал буларак лаеклы рәвештә ихтирам казандыгыз.

ТР Премьер-министры урынбасары – ТР Министрлар Кабинеты Аппараты җитәкчесе кебек җаваплы вазыйфада эшләү уңышлар һәм гамәлгә ашырылган проектлардан гына тормый, ул борчулар һәм авырлыкларны да үз эченә ала. Күпләгән мөһим республика проектларын даими рәвештә гамәлгә ашыруны көйләү һәм контрольдә тоту җиңел бирелми. Ләкин өстенлекле юнәлешләрне билгели белү һәм оештыру сәләтегезне эшкә җигү нәтиҗәсендә боларның барысына да уңышлы ирешеп киләсез.

Фидакарьлегегез, белемегез һәм тәҗрибәгез Сезгә алга куелган барлык бурычларны да җиренә җиткереп башкарырга мөмкинлек бирә. Болардан тыш, Сез чын профессионал гына түгел, Сез – туган ягыгызның патриоты да. Сезгә хас энергия, перспективаларны күрә, төгәл һәм киңкырлы фикер йөртә белү – зур соклану уята торган сыйфатлар. Сезнең белән аралашу кәефне күтәрә һәм алга яңа бурычлар куярга этәргеч бирә.

50 яшь – ул үткәннәргә бәя бирергә һәм тупланган тәҗрибәгә таянып алга атларга мөмкинлек тудыра торган күркәм вакыт.

Сез, хөрмәтле Шамил Хәмитович, тынгысыз, бернәрсәгә дә битараф булмаган шәхес. Сезгә ныклы сәламәтлек, күтәренке кәеф һәм дәрт-дәрман телим! Бай тәҗрибәгез һәм теләсә нинди авыр хәлләрдә дә нәтиҗәле чишелешләр таба белү сәләтегез киләчәктә дә Сезгә ышанычлы юлдаш булсын!

Тирән хөрмәт, изге теләкләр Сезгә!

Фото «Газпром трансгаз Казан» ҖЧҖнән алынды

Яңа идеяләр һәм күркәм ачышлар юлдаш булсын!

Дамир Кәримуллин,
«КМҖБ» АҖ
генераль директоры

– Хөрмәтле Шамил Хәмитович!

«Казан моторлар җитештерү берләшмәсе» АҖ коллективы исеменнән һәм шәхсән үз исемемнән Сезне юбилеегыз белән тәбрик итәм!

Республикабызның социаль-икътисадый үсеше, аның бүгенгесе һәм киләчәге күп очракта Татарстанның иминлегенә үзләреннән лаеклы өлеш кертүче беренче затлардан, министрлык, оешмалар, предприятиеләр җитәкчеләреннән тора. Сезгә хас кыйммәтләр системасы, принципиальлегегез, фикер сөрешегезнең киңлеге Татарстанның инновацияле үсеше кыйбласына, аның киләчәккә омтылышына туры килә.

Хәл ителергә тиешле бурычларның барлык якларын күрә һәм төрле хәлләрдә нәтиҗәле чишелеш юллары таба белүче профессионал булуыгызга карата тирән ихтирамымны белдерәсем килә. Сез төрле дәрәҗәләрдә, киңкырлы эшчәнлегегезнең төрле өлкәләрендә хезмәттәшлек итүче кешеләр арасында хөрмәткә лаек булдыгыз. Сез үз үрнәгегездә бары тик ныклы характерга ия булу, эзлекле гамәлләр башкару, өстенлекләрне билгели белү һәм, әлбәттә, тирән белемнәргә таяну нәтиҗәсендә танылуга ирешү мөмкинлеген исбатладыгыз.

Шамил Хәмитович, 50 яшьлек юбилеегыз көнендә Сезгә киләчәктә дә уңышлар телисе килә. Республика иминлеге хакына хезмәт һәм төбәкне үстерү буенча мөһим мәсьәләләрне хәл итүдә Сезгә яңа идеяләр, күркәм ачышлар һәм бетмәс-төкәнмәс энергия юлдаш булсын!

Реклама
Фотолар «КМҖБ» АҖ нән алынды

Профессиональлек һәм ныклы характер өчен рәхмәт

Рәүзил Хаҗиев,
«Татэнерго» АҖ
генераль директоры

– Хөрмәтле Шамил Хәмитович! «Татэнерго» АҖ нең күпсанлы коллективы һәм шәхсән үз исемемнән юбилеегыз белән котлыйм!

Сезнең эшләгән елларыгызны күздән кичерсәк, нәрсә күрәбез? Барысы да – республика иминлеге хакына фидакарь хезмәт итү еллары. Әлеге вакыт аралыгында илдә икътисадый һәм социаль вазгыять алышынды, законнар үзгәреш кичерде. Сез замананың кырыс таләпләренә лаеклы рәвештә җавап бирә белдегез һәм барлык үзгәрешләрне җентекле контроль астында тота алдыгыз. Узган елларга әйләнеп карап, Сез, һичшиксез, һөнәри үсешегез белән дә, шәхси тормышыгыз үрнәге белән дә горурлана аласыз.

Сез – тормышта үз урынын тапкан һәм көн саен бөтен көчен, энергиясен, яңалыкка, омтылыш дәртен яраткан хезмәтенә багышлаган шәхес үрнәге. Вазыйфагыз Сездән ныклы ихтыяр көчен, зирәклекне һәм тирән аналитик сәләтне таләп итә һәм Сез моны һәр очракта исбатлыйсыз.

Сез туплаган тормыш һәм хезмәт тәҗрибәсе киләчәккә ышаныч белән карарга һәм алдыгызга яңа олы бурычлар куярга мөмкинлек бирә.Бәхетле кеше булуыгызга, хезмәттәшләрегезнең һәм фикердәшләрегезнең Сезне хөрмәт итүенә һәм кадерләвенә, туганнарыгызның һәм якыннарыгызның яратуына мин һич тә шикләнмим.

Нәтиҗәле хезмәттәшлек еллары өчен Сезгә рәхмәтемне белдерергә һәм яңа җиңүләргә ирешүдә ак юллар теләргә рөхсәт итегез! Ныклы сәламәтлек Сезгә, эшегездән канәгатьлек кичереп, йортыгызда тынычлык табып яшәгез!

Фото «Татэнерго» АҖнән алынды

Реклама

Күркәм үрнәк буларак таләпчәнлек һәм җаваплылык

Рифнур Сөләйманов,
«Татэнергосбыт» АҖ
директоры

– Хөрмәтле Шамил Хәмитович! Юбилеегыз көнендә шәхсән үз исемемнән һәм «Татэнергосбыт» АҖ коллективы исеменнән ихлас котлауларымны кабул итеп алыгыз!

Республикабыз иминлеге хакына озак еллар хезмәт куюгыз өчен рәхмәт белдерәм. Сезнең һөнәри сыйфатларыгыз арасында югары дәрәҗәдәге оештыру сәләтегез, вак нәрсәләргә дә гаять игътибарлы булуыгыз һәм фидакарьлегегез беренче урында тора. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты җитәкчесе вазыйфасындагы хезмәтегез белән Сез тирә-якны яхшыга үзгәртәсез. Сезнең эшчәнлегегез нәтиҗәсендә туган республикабыз елдан-ел үсә, социаль сфера алга китә, законнар камилләшә бара.

Сез фидакарьлек һәм оештыру сәләте таләп итә торган җаваплы вазыйфа билисез. Коллегаларыгызның хөрмәте һәм республика җитәкчелегенең Сезнең хезмәтне тануы үз вазыйфагызны менә дигән итеп башкаруыгыз турында сөйли. Хакимият органнарында алга таба да уңышлы эшчәнлегегезне дәвам итүгезне, яңадан-яңа җиңүләрнең матур нәтиҗәләр белән шатландыруын, ихлас рәхмәт хисләренең күтәрмәүләрен, нәкъ вакытлы килеп ирешүен телим.

Сезгә безгә карата күрсәткән даими ярдәмегез һәм энергетика мәсьәләләренә игътибарлы мөнәсәбәттә булуыгыз өчен рәхмәт белдерергә рөхсәт итегез. Тормышның барлык өлкәләрендә дә иминлек, бәхет һәм бетмәс-төкәнмәс дәрт-дәрман телим. Барлык күркәм эшләрегездә дә уңышлар һәм хезмәттәшләрегез белән якыннарыгызның ярдәме юлдаш булсын!

Фото «Татэнергосбыт» АҖнән алынды

www.protatarstan.ru
ТАТАРСТАН
Подписка!
Әһәмиятле
Игелекле
Мәңгелек
Казан ханбикәләре: Сөембикә
Сайттагы яңалык
Яңалыклар
22 апреля 2019
19 апреля 2019
Татарстан Язучылар берлеге нинди планнар корган
Казан ханлыгының мәшһүр хатыннары: Сөембикә
Иътибар үзәгендә – мәктәп
Милли холыклы классика
Тәвәккәл хуҗабикәләр
Реклама 16+

Илсур Метшин, Казан шәһәре мэры,
апрельдә үзенең 50 яшьлек юбилеен билгеләп үтә.

Лаеклы үрнәк

Азат Нигъмәтуллин,
Казан башкарма комитеты җитәкчесенең шәһәр төзелеше сәясәте буенча беренче урынбасары

– Хөрмәтле Илсур Рәисович! Казан шәһәре төзүчеләр блогы исеменнән, шәхсән үз исемемнән Сезне 50 яшьлек юбилеегыз белән котлыйм! Әлеге түгәрәк дата – тагын бер мәртәбә Сезгә күп еллар дәвамында уңышлы уртак хезмәттәшлек өчен рәхмәтебезне белдерер өчен менә дигән форсат.

Түбән Кама шәһәре мэры вазыйфасында Сез шәһәрлеләрнең тормыш сыйфатын күтәрүне эш стратегиясе итеп сайладыгыз. Әлеге тырышлыкларны күреп, Сезне республика башкаласы мэры итеп сайладылар. Бу вазыйфаның җаваплылыгы Сезгә үз алдыгызга киң күләмле максатлар куярга һәм аларга тырыш хезмәт нәтиҗәсендә ирешергә этәргеч бирә. Сезнең җитәкчелектә Казан алгарышка таба гаять зур ыргылыш ясады. Сез ирешелгәннәрдә генә туктап калырга җыенмыйсыз һәм идеаль шәһәр турындагы хыялларны алга таба да тормышка ашырырга омтыласыз.

Республика башкаласында узган дөнья чемпионатларында һәм башка олы вакыйгаларда үзегезне кунакчыл һәм зирәк хуҗа итеп күрсәтеп, Сез һөнәри сыйфатларыгызны халыкара дәрәҗәдә дә уңышлы рәвештә расладыгыз. Югары дәрәҗәдәге оештыру сәләтегез лаеклы бәясен алды, һәм Сез бүген халыкара оешмаларда җитәкче урыннарны билисез.

Сезнең җаваплылык кыры киң һәм күпмаксатлы, әмма Сез, шәп идарәче буларак, беркайчан да авырлыклар каршында югалып калмыйсыз. Гражданнар өчен хакимиятне төрле баскычларга бүлүнең әһәмияте юклыгын башкаларга караганда тирәнрәк аңлыйсыз: кеше үз өендә үзен уңайлы һәм имин итеп тоярга тиеш. Шуңа күрә Сез кабул иткән һәр карар шәһәр инфраструктурасына, аның тышкы кыяфәтенә генә уңай йогынты ясап калмыйча, шәһәрлеләрнең, башкала кунакларының кәефенә дә тәэсир итә.

Сез үз тирәгезгә битараф булмаган чын профессионалларны туплый алдыгыз. Без Сезне шәп идарәче һәм иң күркәм кешелек сыйфатлары хас булган шәхес буларак беләбез. Сезнең гаилә кыйммәтләре һәм милли традицияләр яклы булуыгыз да тирән ихтирам уята һәм Сезнең яныгызда эшләгән һәркем өчен үрнәк булып тора. Тормышта спорт һәм музыка Сезнең янәшәгездән атлый, Сез – зирәк акылга ия, үзенә тартып тора торган сөйкемле сөяге булган, һәр яктан үсеш алган шәхес. Бөек полководец артыннан барган кебек, Сезнең арттан да атлыйсы, проблемаларны инновацияләр һәм нәтиҗәле планлаштыру аша чишәсе, авырлыкларны җиңәсе килә. Казанны төзүчеләр исеменнән Сез башлаган һәр эшне хупларга, куелган бурычларны тулы җаваплылыкта башкарырга әзер икәнлегебезне беләсез. Безнең өчен Сез турыдан-туры катнашкан һәр проектны гамәлгә ашыру чын мәгънәсендә намус эше булып тора.

Сезгә туган һәр көннән ямь-тәм табып яшәргә язсын! Башланган проектларны уңышлы тапшырып бетерергә, шулай ук яңа идеяләр уйлап табарга, аларны бар колачында гамәлгә ашырырга насыйп булсын! Үзегезгә һәм дус-тату гаиләгезгә ныклы сәламәтлек һәм иминлек телибез! Яраткан Казаныбызның мэры вазыйфасында алга таба да нәтиҗәле эшләгез, тормышның барлык өлкәләрендә гармониягә ирешеп яшәгез. Без шәһәребез һәм аның халкы иминлеге хакына Сезнең белән бергә хезмәт куюыбыз белән горурланабыз!

Фото Казан шәһәре Башкарма комитетыннан алынды

Хөрмәтле Илсур Рәисович!

Альберт Шиһабетдинов,
«ТАИФ» АҖ
генераль директоры

Күркәм юбилей датасы – 50 яшьлегегез уңаеннан җылы, ихлас теләкләребезне кабул итеп алыгыз.

Кешенең яше еллар белән түгел, бәлки игелекле эшләре һәм гамәлләре, актив гражданлык позициясе, кешеләргә файда китерергә омтылуы, һәрвакыт эшлекле булуы һәм тормыш үзәгендә кала белүе белән билгеләнә. Илсур Рәисович, Сез лаеклы рәвештә замана ритмын билгеләүче күренекле, талантлы, гаять зур көч-куәткә ия җитәкчеләр буынына карыйсыз. Хезмәт биографиягезнең барлык этапларында да Сезне зур тырышлык, югары профессионализм, ирешелгән нәтиҗәләрне туктаусыз камилләштереп тору һәм үз алдыгызга тагын да катлаулы бурычлар кую омтылышы аерып тора.

Сез кешеләрне идеяләрегез белән рухландыра беләсез, ниятләгән план һәм проектларны тормышка ашыру юнәлешендә аларны берләштерә алу сәләтенә иясез. Республикабыз башкаласы җитәкчелегенә килгәч, Сез, профессионал командагыз белән бергәләп, шәһәргә яңа үсеш импульсы бирдегез, көчле уңай үзгәрешләргә ирешә алдыгыз. Әлеге сыйфатлар Казанны башка шәһәрләрдән аерып тора. Кыска гына вакыт аралыгында мәркәзебез алга таба зур, кыю адым ясады – шәһәр мохитен үзгәртү темплары, яңа микрорайоннар төзү, инфраструктураны үстерү гадәти вакыт агышын узып китте. Бүгенге көндә Казан – Европача матур мегаполис, яшәү өчен төзек һәм уңайлы шәһәр. Җир шарының төрле почмакларыннан йөз меңләгән туристны магниттай тартып тора торган кала.

Эшләү дәверегездә Сез республикабызның җитәкчелеге, һәрвакыт бер адым алда баручы һәм республикага иң алдынгы, иң яхшы тәҗрибәләрне җәлеп итүче Татарстан Президенты Рөстәм Нургалиевич Миңнеханов белән мөнәсәбәтләрегезне дөрес һәм нәтиҗәле итеп оештыра алдыгыз. Сез, Илсур Рәисович, һәрвакыт Президент инициативаларын хуплый беләсез һәм зур энтузиазм белән иң кыю планнарны тормышка ашырырга алынасыз! Татарстан Республикасының беренче Президенты, бүгенге көндә ТР Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәрипович Шәймиев тарафыннан тормышка ашырылучы киң колачлы проектларда актив катнашуыгыз да олы хөрмәт уята. Бу – тарих һәм архитектура һәйкәлләрен яңарту, белем бирү программаларын гамәлгә ашыру, заманча полилингваль үзәкләр булдыру һәм башка бик күп игелекле эшләр. Үзара файдалы хезмәттәшлекнең нәтиҗәләре кешеләргә, туган якны ямьләүгә һәм үстерүгә хезмәт итүе бигрәк тә куанычлы, кадерле!

Әлеге уртак тырышлык нәтиҗәсендә Казан дөнья дәрәҗәсендәге чаралар үткәрелә торган халыкара мәйданчыкка әверелде. Ул Бөтендөнья җәйге Универсиадасы, су спорт төрләре буенча ФИНА дөнья чемпионаты, футбол буенча дөнья чемпионаты кебек колачлы спорт чараларын оештыру көченнән килә торган калага әйләнде. Сезнең җитәкчелектә Казан ирешкән тагын бик күп уңышларны санарга мөмкин, ләкин шәһәр халкы һәм кунаклар арасында хезмәтегез нәтиҗәсендә яуланган хөрмәт һәм ихтирам да мөһим казанышыгыз булып тора. Сез югары дәрәҗәдәге җитәкче абруена ия. Сезне җаваплылык, Казанны динамик рәвештә үстерү, матур, уңай якка үзгәртү хакына иң амбициоз ниятләрне һәм иң кыю планнарны уңышлы рәвештә тормышка ашыра белү сәләте аерып тора.

Илсур Рәисович, Казан һәм Татарстанның мул-имин тормышы хакына көндәлек фидакарь хезмәтегез, яраткан шәһәребезне тагын да кунакчылрак, тагын да гүзәлрәк итү хакына куйган тырышлыгыгыз өчен олы рәхмәтебезне җиткерергә рөхсәт итегез.

Ихлас күңелдән Сезгә ныклы сәламәтлек, актив озын гомер, бәхет, иминлек, бетмәс-төкәнмәс дәрт-дәрман, эшегездә зур уңышлар, уй-ниятләрегезнең тормышка ашуын телим! Сезне беркайчан да күтәренке кәеф, өмет-ышаныч һәм илһам ташламасын, киләчәктә шатлык-куаныч, уңыш тулы бәхетле еллар көтеп торсын!

Сезгә һәм якыннарыгызга тынычлык һәм иминлек юлдаш булсын!

Реклама
Фото «ТАИФ» АҖнән алынды

Казан һәм башкала халкы иминлеге хакына

Дамир Кәлимуллин,
«КМҖБ» АҖ
генераль директоры

– Илсур Рәисович Метшин турында сөйли башлауга, иң беренче булып, башка «Казан – матур, заманча һәм уңайлы шәһәр» дигән уй килә.

Бу чыннан да шулай. 2004 елда мин КМҖБ сен җитәкли башладым, Казанга күченеп килдем һәм шәһәрдәге барлык үзгәрешләр минем күз алдында барды. Алар хәзер дә бара. Бүген башкала үз алдына бик биек планка куйды: ул көннән-көн үзгәрә, матурлана. Бу, иң беренче чиратта, тормыш итәр, эшләр өчен, шулай ук иҗади, мәдәни һәм спорт хәрәкәте өчен дә яңа, уңайлы инфраструктура пәйда булуга бәйле.

Илсур Рәисовичка шәһәрдә барган бар нәрсә өчен җаваплылык йөкләнә: аның тарафыннан шәһәрлеләрнең тормыш сыйфатын һәм уңайлылыкны күтәрүгә юнәлдерелгән масштаблы, тулы бер комплекслы бурычлар хәл ителә. Ул үзен гаять зур тәҗрибәгә ия, төрле хәлләрдә нәтиҗәле карарлар кабул итәргә сәләтле булдыклы җитәкче һәм оештыручы итеп күрсәтте. Шуңа күрә казанлылар 10 елдан артык вакыт дәвамында аңа муниципалитет белән җитәкчелек итүне ышанып тапшыра килә.

Хәзерге заманга хас иң мөһим сыйфатларның берсе – үзгәрешләрнең тизлеге. Эре мегаполисларның үсеш тенденцияләрен исәпкә ала барып, җәһәт эшләү таләп ителә. Казан, бу яктан караганда, Татарстан Республикасы Хөкүмәте тарафыннан хуплана торган күпләгән проектларны гамәлгә ашырып, вакыт белән бергә атлый, башкала заманча шәһәргә әверелеп бара.

Казанда яшәүче кешеләрнең берсе, моннан тыш сәнәгать предприятиесе җитәкчесе буларак мине һәм, гомумән, моторлар төзүче башка хезмәттәшләремне дә, башкалада, Авиатөзелеш районында барган үзгәрешләр, яңа микрорайоннар һәм юл чишелешләре төзелешләре, яңа балалар бакчалары, мәктәпләр, шәһәр скверлары һәм паркларының пәйда булуы сөендерә.

«КМҖБ» АҖ, бюджет булдыручы эре предприятие рәвешендә, җәмгыятебезнең социаль һәм икътисадый өлкәләрен алга таба үстерүгә юнәлдерелгән шәһәр инфраструктурасын яхшыртуга караган проектларда актив катнаша.

Хөрмәтле Илсур Рәисович, Сезне 50 яшьлек юбилеегыз белән котлыйм! Сезгә ныклы сәламәтлек, иминлек, бетмәс-төкәнмәс дәрт-дәрман һәм уңышлар телим! Бай тормыш тәҗрибәгез һәм көчле эшлеклелек сыйфатларыгыз киләчәктә дә күркәм уй-ниятләрегезне, планнарыгызны тормышка ашырырга ярдәм итсен. Казан һәм башкала халкы иминлеге хакына мөһим бурычларны чишкәндә сабырлык һәм эзлеклелек насыйп булсын!

Реклама

Фото «КАҖБ» АҖ нән алынды

Реклама

Шәһәр тормышын көйләүдә күпьеллык уңыш

Фото «Татэнерго» АҖнән алынды

Рәүзил Хаҗиев,
«Татэнерго» АҖ
генераль директоры

– Хөрмәтле Илсур Рәисович! Күркәм юбилей уңаеннан тирән ихтирамымны белдерергә һәм «Татэнерго» АҖ коллективы исеменнән, шәхсән үз исемемнән бәйрәмегез белән котларга рөхсәт итегез!

Сездәге максатчанлык һәрдаим сокландыра, үзегезне исә үрнәк итеп күрсәтәсе килә. Эшенә ихлас бирелгән чын профессионал, мөлаем, гаять көчле шәхси тарту көченә ия шәхес кенә илнең иң эре шәһәрләренең берсендә мэр вазыйфаларын шулкадәр яратып башкарырга һәм башкала йөзенә күркәм, үзенчәлекле чалымнар өстәргә сәләтле.

Сез көн саен яраткан Казаныбызның инфраструктурасын, төзекләндерү эшләрен һәм бизнесны үстерүгә караган мәсьәләләрне хәл итәсез. Инновацияле проектларны эшләү, чит илләр тәҗрибәсен безгә яраклаштыру һәм инвестицияләр җәлеп итү юлыннан уңышлы атлыйсыз.

Экологик һәм икътисадый яктан нәтиҗәле проектларга күз төбәп эш итәсез. Безнең компания дә әлеге таләпләрне истә тотып үсеш кичерә. Озак еллар дәвамында хезмәттәшлек итү Сезнең энергетика мәсьәләләреннән дә хәбәрдар булуыгыз турында фикер йөртергә мөмкинлек бирә. Сезнең өчен әлеге өлкәдә катлаулы һәм мөһим булмаган сораулар юк. Сез төрле дәрәҗәләрдәге бурычларга бер үк төрле игътибар күрсәтәсез.

«Татэнерго» АҖ шәһәребездә уздырыла торган спортка һәм яшьләргә кагылышлы барлык чараларда зур кызыксыну белән катнаша, Татарстан башкаласын төзекләндерү һәм аның социаль тармагын үстерүгә ярдәм итә. Без Казанда яшәвебез һәм эшләвебез белән горурланабыз.

Тормышыгызның шәхси һәм һөнәри өлкәләре уңышка, җиңүләргә бай булсын, күңелегездә гармония хөкем сөрсен. Сезгә ныклы сәламәтлек телим, имин эш көннәре һәм яңа күләмле проектлар насыйп булсын!

Ирешкәннәрдә туктап калмыйча

Фото «Татэнергосбыт» АҖнән алынды

Рифнур Сөләйманов,
«Татэнергосбыт» АҖ
генераль директоры

– Хөрмәтле Илсур Рәисович! Юбилеегыз көнендә мулдан яңгыраган матур котлауларга кушылырга рөхсәт итегез.

Түбән Кама мэры вазыйфасында идарәче талантыгызны кулланып, үзегезнең ныклы холкыгызны һәм шәп лидерлык сыйфатларыгызны күрсәттегез. Республика башкаласы җитәкчесе булып сайлангач, бөтен көчегезне Казанның иминлеген булдыруга юнәлттегез. Сез идарә иткән елларда шәһәрнең индустриаль, туристлык һәм социаль куәте ныклап ачылды. Сез бүген дә ирешкәннәрдә генә туктап калмыйсыз, чираттагы халыкара проектларга гаризалар әзерлисез һәм яңа уникаль программалар эшлисез.

Үз үрнәгегездә уңышка атлау юлында җиңә алмаслык бернинди дә каршылыклар булмавын раслыйсыз. Сезнең зирәк акылыгыз, алга карап планлаштыра белү сәләтегез һәм югары профессиональ дәрәҗәдәге фикердәшләр командагыз каршында иң кыю максатлар да җиңелә.

«Татэнергосбыт» АҖ коллективы һәм шәхсән үз исемемнән Татарстан башкаласын үстерүгә керткән хезмәтегез өчен Сезгә карата тирән хөрмәтемне һәм рәхмәтемне белдерәм. Сезнең турыдан-туры катнашыгыздан башка шәһәребезнең үсешен күзаллап та булмый.

Шәһәрлеләрнең тормыш сыйфатын күтәрү – безнең уртак максат. Сезнең инновацияләргә хәерхаһлы булуыгыз безнең коллективны энергия саклау һәм энергиянең нәтиҗәлеген күтәрү өлкәләрен зур тизлек белән үстерергә илһамландыра. Эшчәнлегебез өлкәсенә караган мәсьәләләрдә катнашуыгызны югары бәялибез. Сез сәнәгать, бизнес-җәмәгатьчелек һәм хакимият органнары арасында ачык диалогның мөһимлеген башкаларга караганда күбрәк аңлыйсыз.

Сезгә алга таба да, Россия һәм халыкара рейтингларның беренче баскычларына күтәрелеп, уңышлы хезмәт итәргә язсын! Тормышыгыз гаилә җылысына, туганнарыгыз һәм якыннарыгызның кайгыртучанлыгына һәм яратуына бай булсын!

Халык иминлеге хакына көндәлек тырыш хезмәт

Борис Тихомиров,
«Казан Гипрониие-авиапромы» КТ генераль директоры

– Хөрмәтле Илсур Рәисович! Шәхсән үз исемемнән һәм «Казан Гипрониие-авиапромы» КТ коллективы исеменнән юбилеегыз уңаеннан ихлас котлауларны кабул итеп алыгыз.

Казаныбызны үстерүгә, аны матурлауга бәһаләп бетергесез өлеш кертүегез өчен Сезгә рәхмәт белдерергә рөхсәт итегез. Менә инде 14 ел дәвамында Сез, шәһәребезне яшәү, эшләү өчен уңайлырак итү хакына көн саен зур тырышлык күрсәтеп, казанлылар иминлеге өчен лаеклы хезмәт итәсез.

FIFA 2018 футбол буенча дөнья чемпионатын, Универсиада-2013 Бөтендөнья җәйге студентлар спорт уеннарын, XVI су спорт төрләре буенча дөнья чемпионатын һәм башкаларны уздыру көннәрендә Сезгә төрле кыйтгалардан килгән кунакларны хуҗа сыйфатында каршы алу кебек гаять мөһим рольне үтәргә туры килде. Әлеге барлык чаралар алдыннан җентекле әзерлек эшләре башкарылды. Бу эшләрдә безнең коллектив та актив катнашты. Мәсәлән, без «Казан» Халыкара аэропорты объектларын, Су спорт төрләре сараен, бассейннарны һәм транспорт инфраструктурасын проектлау юнәлешендә эшләдек. Шуңа күрә Сезнең командагыз кыска вакыт аралыгында шәһәрне сыйфат ягыннан үзгәртүгә ирешә дип, кыю рәвештә әйтә алабыз.

Дөньядагы кризислы хәлләргә карамастан, республика башкаласы, сәнәгатьтә, квалификацияле кадрлар әзерләүдә һәм инновацияләрне гамәлгә кертүдә әйдәп баручылар рәтендә тора. «Крылья Советов» паркы территориясе проектын эшләп, Сезнең белән бергә парклар һәм скверларны яңарту юнәлешендә дә хезмәттәшлек итәбез.

Алдагы елларга да зур күләмле проектлар тәгаенләнгән. Шуларның берсе – зур Казан боҗрасын төзү, бу – мэрыбызның «киләчәккә олы хыялы»! Шәһәр транспортын реформалау буенча советлардан соңгы чорда гамәлгә ашырылган, «Золотая колесница» милли премиясенә лаек дип табылган пилот проекты – шәһәр җитәкчесенең халык турында кайгыртуының күркәм күрсәткече.

Шәһәребез йортларын һәм урамнарын реставрацияләү, аларга тарихи йөзләрен яңадан кайтару юнәлеше эшчәнлегегездә аерым урынны алып тора. Бу эшләрдә без, Казанның 1000 еллыгына әзерлек чорындагы кебек үк, турыдан-туры катнашырга һәрвакыт әзер.

Спорт сөюче буларак, Сез иң югары максатлар куярга курыкмыйсыз һәм, фикердәшләрегезгә таянып, аларны уңышлы башкарып та чыгасыз. Командагызның бердәмлеге эшлекле чаралар белән спорт ярышлары уздырганда гына күренеп калмый, ә музыка, җыр юнәлешендә дә аермачык күренә.

Үз Ватаны, үз эше, үз йорты һәм якыннары, үз киләчәге өчен, ягъни Сез кем һәм нәрсә хакына көрәшергә кирәклекне төгәл белүче кыю һәм көчле рухлы ир-ат!

Барлык ниятләгән эшләрегезне алга таба да уңышлы гамәлгә ашыру өчен Сезгә чын күңелдән илһам телисе килә. Сезгә һәрвакыт дәрт-дәрман, ныклы сәламәтлек һәм күтәренке кәеф юлдаш булсын!

Казан шәһәре үзенең мэры сыйфатында Сезнең кебек шәп хуҗалыкчы, профессональ оештыручы һәм еракка карап эш итүче инноваторга ия булуы белән бәхетле. Үзе бер язмышка әверелгән эшчәнлегегездә Сезгә бары тик уңышлар гына насыйп булсын!

Реклама

Фото «Казан Гипронииавиапромы» КТнән алынды

Һәрвакыт хәрәкәттә!

Искәндәр Миңнуллин,
«Республика клиник тире-венерология диспансеры» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе баш табибы

– Хөрмәтле Илсур Рәисович! Безнең учреждение хезмәткәрләре исеменнән Сезне юбилеегыз белән котларга рөхсәт итегез. Әлеге күркәм бәйрәмне шундый энергияле, эшлекле, дәртле халәттә каршылавыгызны билгеләп үтү, күрү бик күңелле! Сезне коллегаларыгыз, дусларыгыз, туганнарыгыз хөрмәт итә һәм кадерли. Чөнки алар күз алдында Казаныбыз матурлана, тагын да уңайлырак шәһәргә әйләнә бара. Казанлылар зур горурлык белән Россиянең иң заманча һәм уңайлы калаларының берсендә яшибез, дип әйтә ала.

Бу алгарышта, мэр буларак, Сезнең өлешегез бик зур. Казанның динамик үсеше, бәхәссез, Сезнең стратегик фикер сөрешегезгә, үз алдыгызга олы, амбициоз бурычлар куеп кына калмыйча, аларны уңышлы гамәлгә ашыра алуыгызга да ныклы дәлил. Бүген шәһәр икътисады күрсәткечләре барлык юнәлешләр буенча да диярлек тотрыклылык булуын раслый.

Сез, Илсур Рәисович, һәрвакыт хәрәкәттә, Татарстан башкаласы халкының иминлеге хакына яңадан-яңа проектларны эзлекле рәвештә тормышка ашырасыз.

Сезгә һәм Сезнең зур, күркәм гаиләгезгә чын күңелдән ныклы сәламәтлек, тынычлык һәм иминлек телибез, якыннарыгызның ярдәме һәм мәхәббәте алга таба хәрәкәт итәр өчен көч һәм дәрт-дәрман бирсен!

Фото «Республика клиник тире-венерология диспансеры» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесеннән алынды

Лаеклы лидер һәм үз эшенең остасы

Леонид Анисимов,
«Грань» ҖЧҖ
генераль директоры

Фото «Грань» ҖЧҖ нән алынды

– Хөрмәтле Илсур Рәисович!

«Грань» ҖЧҖ коллективы исеменнән һәм шәхсән үз исемемнән Сезне юбилеегыз белән ихлас күңелдән котлыйм!

Татарстанда һәм аннан читтә Сезне абруйлы дәүләт эшлеклесе, социаль тормышның һәм икътисадның күп кенә сфераларыннан яхшы хәбәрдар югары классы профессионал, тирән эрудициягә, кирәкле белемнәргә, мөһим бурычларны чишкәндә перспективаны күрә белү сәләтенә һәм интуициягә ия шәхес буларак беләләр.

Сезнең Казан башлыгы вазыйфасында күп еллар дәвамындагы уңышлы хезмәтегез ихтирам уята. Күпчелек Сезнең оештыру талантыгыз, инновацияле фикер сөрешегез һәм дөрес инициативаларыгыз нәтиҗәсендә Татарстан башкаласының йөзе, шәһәрлеләрнең тормыш шартлары уңай үзгәрешләр кичерде: халыкара дәрәҗәдәге спорт объектлары пәйда булды, транспорт инфраструктурасы тамырдан үзгәртелде, шул исәптән метрополитен ачылды, «Казан» халыкара аэропорты яңартылып, аэроэкспресс җибәрелде. Бүген дә шәһәрдә җәмәгать урыннарын үстерү, парк һәм скверлар булдыру буенча эш алып барыла, юлларны, дәваханәләрне, балалар бакчаларын, мәктәпләрне капиталь төзекләндерү буенча мөһим программалар гамәлгә ашырыла, торак төзелеше күләмнәре үсә.

Илсур Рәисович! Сез һәрвакыт – алгы сызыкта, яңа идеяләр белән янасыз. Күтәренке кәефегез сокландыра, дәрт-дәрманыгыз ташып тора. Сезгә иминлек, ныклы сәламәтлек, җаваплы эшегездә уңышлар, куелган максатларыгызга ирешүегезне телим! Эшлеклелек сыйфатларыгыз киләчәктә дә иң катлаулы һәм мөһим бурычларны хәл итәргә булышсын, янығызда тугры дусларыгыз һәм фикердәшләрегез булсын!

Киләчәк мегаполисы рулендә

Руслан Нурмөхәммәтов,
«#СУВАРСТРОИТ» ҖЧҖ
генераль директоры

Фото «#СУВАРСТРОИТ» ҖЧҖ нән алынды

– Хөрмәтле Илсур Рәисович! 50 яшьлек юбилей көнегездә Сезгә юлланган барлык теләкләргә дә кушылырга рөхсәт итегез. «#СУВАРСТРОИТ» ҖЧҖ компаниясенең күпсанлы коллективы исеменнән һәм үз исемемнән Сезне юбилеегыз белән котлыйм. Сезнең максатчанлыгыгыз һәм дөрес планлаштыра белү сәләтегез сокландыра. Татарстан башкаласы мэры вазыйфасын биләгән шушы елларда Сез шәһәрне үстерүдә гаять зур уңышларга ирештегез. Инвестицияләрне җәлеп итүдәге, халыкара чараларны уздырудагы тырышлыгыгыз, шулай ук гражданнар өчен уңайлы яшәү мохите булдыруга юнәлеш алуыгыз нәтиҗәсендә без киләчәк мегаполисында яшибез.

Шәһәр төзелеше тармагында дөрес итеп планлаштырылган үсеш стратегиясенең никадәр мөһим роль уйнавын Сез башкаларга караганда күбрәк аңлыйсыз. Гаять кыйммәтле тарихи асылга ия территорияне нигез итеп алып, аны заманча социаль инфраструктура һәм яңа торак кластерлары белән тулыландырып, Сез шәһәрнең уникальлеген, үзенчәлеген саклап кала алдыгыз.

Сезнең идарә итү талантыгыз дөнья күләмендә танылды, Сез халыкара оешмаларда җитәкче вазыйфаларын билисез һәм ирешелгәннәрдә генә туктап калырга уйламыйсыз. Сезнең кебек прогрессив лидерның һәм менә дигән хуҗалыкчының җитәкче булуы – Казан һәм аның халкы өчен зур уңыш.

Сезгә озак еллар дәвамындагы уңышлы хезмәттәшлек, компаниябез проектларына карата күрсәтелгән игътибарыгыз һәм республикабыз үзәген үстерү юнәлешендәге эшчәнлегегез өчен олы рәхмәтемне белдерәм. Без казанлыларның иминлеге, аларны бәхетле тормышы хакына Сезнең җитәкчелектә эшләвебез белән горурланабыз.

Һәр яңа көн Сезгә яңа идеяләр һәм җиңүләр алып килсен. Сез шәһәрне матурлаутөзекләндерү юлында каршылыкларның булмавын раслап киләсез, әлеге хакыйкать алга таба да какшамас булуын дәвам итсен. Сезгә һәм дус-тату гаиләгезгә сәламәтлек һәм иминлек телим!

Рөстәм Сайманов,
«Рубин» футбол клубының
генераль директоры

Казанны илнең иң күркәм шәһәренә әйләндереп…

– Хөрмәтле Илсур Рәисович! Шәхсән үз исемемнән һәм «Рубин» футбол клубы исеменнән Сезне юбилеегыз белән ихлас күңелдән тәбрик итәм! Сез яраткан Казаныбызны Россиянең иң уңайлы, төзек һәм тормыш итәр өчен иң имин шәһәре итү өчен зур тырышлык куясыз. Төрле рейтинглар буенча республикабыз башкаласы лаеклы рәвештә илебезнең иң яхшы шәһәрләренең берсе санала.

Соңгы елларда Казанда мөһим халыкара вакыйгаларның, шул исәптән спорт бәйгеләренең дә узуы – шәһәр башлыгы буларак һичшиксез Сезнең булдыклылыгыгызны раслаучы үрнәкләр. Зур күләмле чараларның һәркайсы үзеннән соң мираска халык өчен яңа юллар, спорт объектлары калдырып, Казанны яшәү өчен тагын да уңайлырак һәм иминрәк шәһәргә әйләндерә һәм Татарстанның башкаласын яңа сыйфат дәрәҗәсенә күтәрә. Алга таба да Илсур Рәисович, Сезнең алдыгызда тагын да югарырак баскычлар, җаваплырак мәсьәләләрне хәл итү бурычы торуына ышанабыз. Юбилеегыз белән! Сезгә ныклы сәламәтлек, җан тынычлыгы, дәрт-дәрман, яңа, кызыклы проектлар телибез!

Фотолар «Рубин» футбол клубыннан алынды

Вячеслав Матвеев, «Химик технологияләр өлкәсендә төбәк инжиниринг үзәге» АҖ генераль директоры, «Урыссу химия заводы» ЖЧҖ генераль директорының үсеш буенча киңәшчесе, апрельдә 55 яшьлек юбилеен билгеләп үтә.

Николай Лукин,
«Урыссу химия заводы» ЖЧҖ
генераль директоры

Уңышлы хезмәт һәм кыйммәтле киңәшләрегез өчен рәхмәт

– Хөрмәтле Вячеслав Иосифович! Юбилей көнегездә «Урыссу химия заводы» ЖЧҖ коллективы һәм шәхсән үз исемемнән Сезне бәйрәмегез белән тәбрикләп, тирән хөрмәтебезне белдерергә рөхсәт итегез.

Сез гомерегезнең күп елларын туган төбәгегезгә багышлап, Ютазы районы үсешенә саллы һәм күп яклы өлеш керттегез. Сезнең җитәкчелектә Димтамак урта мәктәбе бик яхшы эшләде. Аннары Сез һөнәри талантыгызны Ютазы районы халык мәгарифе бүлеге мөдире вазыйфасында расладыгыз. Район хакимиятендәге нәтиҗәле хезмәтегез Сезгә оештыру һәм хуҗалыкны алып бару эшендә тәҗрибә тупларга мөмкинлек бирде. Сезнең җаваплылык өлкәсенә караган барлык мәсьәләләр дә һәрвакыт югары дәрәҗәдә һәм тиз хәл ителеп килде. Туган районыгыздагы нәтиҗәле хезмәтегез өчен Сезне яхшы белгеч буларак та, кеше буларак та нык хөрмәт итәләр. Шуңа күрә хезмәт сөючәнлегегез һәм осталыгыгызның соңыннан «Урыссу химия заводы» ЯАҖ генераль директоры вазыйфасын башкарганда да калку күренүе һич тә гаҗәп түгел.

Сезнең һөнәри яктан үсүегез һәм ныгуыгыз шактый катлаулы вакытка туры килде, бу исә Сездә зирәк акыл һәм нык холык тәрбияләде. Үзегез башкарган һәр вазыйфага иң зур җаваплылык һәм югары нәтиҗәгә ирешүне максат итеп куйган омтылыш белән алындыгыз. Максатчанлыгыгыз һәм актив тормыш позициягез Сезгә тормышта зур уңышларга ирешергә ярдәм итте. Сезне хезмәттәшләрегез, һичшиксез, хөрмәт итә һәм кадерли, хезмәткәрләрегез үрнәк алырга омтыла, якыннарыгыз исә һәрчак хуплап, булышып тора.

Иң югары класслы профессионал буларак, Сез зирәк һәм алдан күрүчән җитәкче дәрәҗәсенә ирештегез. «Урыссу химия заводы» ЖЧҖ коллективы күп еллар дәвамында Сезнең кул астында эшләве белән горурлана. Җитештерүне яңартып, камилләштереп, хезмәт шартларын яхшыртып, Сез завод өчен бик күп эш башкардыгыз. Игътибарлы җитәкче буларак, Сез хезмәткәрләр арасында үзара уңай мохит тудыруга зур әһәмият бирдегез, бу исә, үз чиратында, эшчеләрнең югары хезмәт күрсәткечләренә омтылуына этәргеч булды.

Генераль директор киңәшчесе буларак, завод өчен янып-көеп йөрүегезне дәвам иткән өчен Сезгә олы рәхмәт белдерәбез. Мөһим стратегик карарлар кабул иткәндә кыйммәтле киңәшләрегезнең ярдәме бәһасыз. Бүгенге көндә, шул исәптән Сезнең ярдәм белән дә, завод үзен химия сәнәгате базарында ышанычлы көндәш итеп тоя.

55 яшьлек юбилеегыз көнендә, ирешелгәннәр белән генә килешеп калмыйча, яңа һөнәри үрләр яуларга насыйп булсын, дип телибез Сезгә. Янәшәгездә барлык ният-максатларыгызны тормышка ашырырга әзер ышанычлы фикердәшләр булсын. Иң катлаулы мәсьәләләрне хәл итүдә гадәти булмаган ысул-алымнар куллану осталыгын, үз көчегезгә ышанычны һәм яңа ачышларга омтылышны мәңгегә саклап калыгыз. Сез – әйләнә-тирәдәгеләр өчен лаеклы үрнәк һәм исеме чын мәгънәсендә зур хәрефләрдән язылырга тиешле Кеше.

Вячеслав Иосифович, Сезгә ныклы сәламәтлек телибез, үзегезгә һәм матур гаиләгезгә мөмкин кадәр күбрәк бәхетле мизгелләр насыйп булсын!

Уруссинский химический завод

423950, Татарстан, Ютазы районы, Урыссу шәһәр тибындагы бистәсе, Химиклар тыкрыгы, 7 йорт
тел./факс: +7 (85593) 49500 / 49501
Электрон почта: zaouhz@mail.ru
Сайт: www.zaouhz.net

Реклама
Фото «Урыссу химия заводы» ЖЧҖнән алынды

Фаил Камаев, Татарстан Республикасы Тукай районы башлыгы, майда үзенең 50 яшьлек юбилеен билгеләп үтә.

ТЫРЫШЛЫК ҺӘМ ЮГАРЫ ТАЛӘПЧӘНЛЕК – АНЫҢ ТӨП СЫЙФАТЛАРЫ

2018 ел Тукай районы һәм аның халкы өчен нәтиҗәле эш елы булды. Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округларының социаль-икътисадый үсеше рейтингы буенча район – дүртенче, ә авыл районнары арасында беренче урынны алды. Ә бу елның беренче ике аенда, авыл җирлекләре арасында алдынгылыгын саклап, шәһәр округлары рейтингында тагын бер баскыч югары менде һәм хәзер өченче урында бара. Биредә яңа социаль объектлар актив рәвештә кулланышка тапшырыла, юллар һәм торак йортлар төзелә. Тукайлылар үз уңышларының күбесен район башлыгы вазыйфасына алдынгы фикерле, мөмкинлекләрне күреп алырга сәләтле җитәкче – Фаил Камаев килүе белән бәйли. 3 майда ул үзенең 50 яшьлеген билгеләп үтә.

Фаил Мисбах улы тумышы белән Мөслим районы Салауз-Мухан авылыннан, үзенең хезмәт юлын туган ягында башлаган. 1992 елда Алабуга педагогика институтын тәмамлаганнан соң, авылдагы урта мәктәпкә тарих укытырга кайта. Аннан соң тәрбия эшләре буенча директор урынбасары, мәктәп директоры була. Ә 2001 елда Мөслим районы Митрәй авыл җирлеге башлыгы вазыйфасыннан аның җирле үзидарә органнарындагы хезмәт юлы башлана. Аннары Актаныш районы хакимиятенә эшкә килә, 2017 елга кадәр Фаил Мисбах улы район башлыгы була. 2017 елның 8 декабреннән ул Тукай муниципаль районын җитәкли башлый. Бу вакыт эчендә, Фаил Камаев үз сүзләренә караганда, ул Тукай районының патриотына әйләнергә өлгерә.

Башлыкның хезмәттәшләре, аның командасы һәм предприятие җитәкчеләре Фаил Камаевны битараф булмаган, үз эшенә бирелгән, өстенлекле юнәлешләрне дөрес билгеләргә сәләтле, киң белемгә ия кеше буларак кына телгә алалар. Бу сыйфатлар район башлыгына, халык белән нәтиҗәле хезмәттәшлек корып, актуаль мәсьәләләрне уңышлы хәл итәргә мөмкинлек бирә.

Аның командасында муниципаль берәмлек алдында торган бурычларны уңышлы һәм эзлекле рәвештә башкарып чыгарлык эшлекле мохит булдырылган. Моңа Фаил Мисбах улына хас шәхси дисциплина, тырышлык, үҗәтлек, үзенә һәм кул астындагыларга карата югары таләпчәнлек, кешеләрне катлаулы эшләргә рухландыра, җайлый белү һәм авыр минутта ярдәм кулы суза белү кебек сыйфатлары шактый дәрәҗәдә булыша.

Көндәлек эшендә район башлыгы төрле милек формасындагы авыл хуҗалыгы оешмалары эшчәнлегенә аерым игътибар бирә, һәм узган ел нәтиҗәләре буенча алар 18,6 млрд сумлык продукция җитештергән. Район башлыгы тырышлыгы белән авыл хуҗалыгына җәлеп ителгән инвестицияләр аграр предприятиеләрне техник яктан җиһазландырырга мөмкинлек бирә. Икътисадның авыл хуҗалыгы секторын нәтиҗәле үстерүгә юнәлдерелгән чаралар кысаларында, 2018 елда район дәүләт ярдәменең барлык төп программаларында катнашты, шуның белән авыл халкына 470 млн сумлык финанс ярдәме күрсәтүгә ирешелде.

Районда шулай ук төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык тармагындагы программалар уңышлы тормышка ашырыла, үзмәшгуль гражданнарга, фермерларга эш алып бару өчен уңай шартлар тудырыла. Әйтик, 2018 елда төзелеш эшләрен финанслау күләме 1,03 млрд сум тәшкил иткән. Авыл хуҗалыгы кооперациясе, яшьләр эшкуарлыгы һәм сәнәгать мәйданчыклары уңышлы үсеп килә. Болар барысы да төрле дәрәҗәдәге хакимиятнең нәтиҗәле хезмәттәшлеге нәтиҗәсендә тормышка ашырыла һәм төп максат – район халкының тормыш дәрәҗәсен күтәрү, аларга уңайлы яшәү шартлары һәм лаеклы эш урыннары булдыруны күздә тота.

Тукай районы үзенчәлеге шунда: аның халкының күпчелеге Чаллыда эшли. Биредә, эре сәнәгать шәһәре һәм район хакимиятләренең берләшеп эш йөртүе һәм зирәклеге нәтиҗәсендә, гадәттәгечә, көндәлек проблемаларны бергәләп хәл итүдә үзара уңай бәйләнешләр җайга салынган. Һәм монда районның социаль-икътисадый сәясәтен, ерак киләчәкне күздә тотып, оста алып баручы Фаил Камаевның өлеше зур.

Күпсанлы хезмәттәшләре, дуслары, якыннары, туганнары һәм Тукай районы халкы Фаил Мисбах улын 50 яшьлек юбилее белән чын күңелдән тәбрик итә һәм аңа изге теләкләрен җиткерә.

Фото: Тукай муниципаль районыннан алынды

Наил Фәррахов,
«Фәррахов» КФХ
директоры

– 50 яшь – бай һөнәри тәҗрибәсе һәм җаваплы гражданлык позициясе булган ир-ат өчен чәчәк ату чоры ул.

Фаил Мисбах улы Камаевның горурланырлык нигезе бар. Республиканың аңа эшләргә насыйп булган барлык өч районында да – Мөслим, Актаныш һәм хәзер Тукай районында күпьеллык намуслы хезмәте халкына һәм хезмәттәшләренә тирән ышаныч, хөрмәт белән сугарылган. Югары җаваплылык хисе, хезмәт сөючәнлек һәм намуслылык аның холкын башкалардан аерып торган үзенчәлекләр булып тора. Ә болар, мөгаен, район җитәкчесенең төп сыйфатларыннандыр. Фаил Мисбах улының Тукай районы башлыгы вазыйфасында җиде ай хезмәте бу җирнең чын патриотына әверелүен һәм киләчәктә аның үсеше өчен бөтен мөмкинлекләрен һәм сәләтен файдаланачагын район халкына ачык күрсәтте. Юбилей көнендә аңа зур уңышлар, ышанычлы фикердәшләр һәм бәхет телибез.

Рифкать Шәфигуллин,
«Тукайагрохимсервис»
ҖЧҖ директоры

– Фаил Мисбах улы Камаев – зур тәҗрибәгә ия шәхес. Ул безгә күп кенә социаль-икътисадый мәсьәләләр акыл белән һәм эзлекле хәл ителгән, бай гореф-гадәтләргә ия районнан килде. Аның хезмәт сөючәнлеген һәм җаваплылыгын Тукай районы җитәкчеләре һәм халкы район башлыгы вазыйфасына керешкән беренче көненнән үк бәяли алдылар. Беренче эш итеп, ул барлык авыл җирлекләрен карап чыкты, халык җыеннарында катнашты, анда тукайлылар үзләрен борчыган конкрет проблемалар турында сөйләде. Җитәкченең моңдый күзәтүчәнлеге, тикшерү-өйрәнүе күп нәрсә хакында сөйли. Фаил Мисбах улы эшкуарлар, предприятие җитәкчеләре һәм район халкы белән элемтә урнаштырырга әзер. Шунысы да бар: Тукай районы башкалардан шактый аерылып тора. Аның халкын, нигездә, Чаллыда эшләүчеләр тәшкил итә. Тукай районының эре сәнәгать шәһәре белән тыгыз хезмәттәшлеге район башлыгы эшенә билгеле бер кыенлыклар тудыра. Ләкин ул, намусына тап төшермичә, үз эшен бик шәп башкара. Фаил Мисбах улына теләгебез шул: хезмәт юлында тупланган һөнәри тәҗрибәсе киләчәккә ышанычлы карарга мөмкинлек бирсен. Сәламәтлек һәм һәр өлкәдә уңышлар Сезгә!

Нияз Дәүләтшин,
«Кама» сәнәгать паркы
директоры

– «Кама» сәнәгать паркының барлык хезмәткәрләре исеменнән, районыбыз башлыгын 50 яшьлек юбилее белән ихлас сөенеп котлыйбыз. Фаил Мисбах улы Камаев эшкуарлык үсеше өчен көч бирүче мохит булып торган кече һәм урта бизнесның районның икътисадый һәм социаль тормышында нинди роль уйнавын ачык күзаллый. 2018 елда эшли башлаган сәнәгать мәйданчыгыбыз моңа дәлил булып тора. Без район башлыгында һәрвакыт ярдәм кулы сузарга әзер торган җитәкчене күрәбез. Аның командасы Тукай районы үсешенә бәйле эшчәнлекне тормышка ашыру максатында булган барлык көчләрне тупларга сәләтле. Без яңа сәнәгать һәм агросәнәгать паркларын булдыру юнәлешендә эш дәвам иткәнен беләбез. Һәм моңа куанмыйча мөмкин түгел! Димәк, Тукай районы җирлеге алга таба да үсештә булачак һәм чәчәк атачак. «Кама» паркы коллективы юбилярга сәламәтлек, куйган максатларына ирешүен һәм район халкыннан югары бәя алуын тели!

Валерий Чулаков,
эшкуар

– Тормышыбыз күп төрле һәм катлаулы, һәр яңа көн үзе белән тагын да катлаулырак мәсьәләләр һәм проблемалар алып килә. Эшкуарлар бу хакта ишетеп кенә белми. Әмма территориянең ныклы үсеш стратегиясе, үсеш юнәлеше бар икән, андый җирдә бизнес кору һәрвакыт җиңелрәк. Тукай районында бу юнәлештә бик күп эшләр башкарыла. Җирле эшкуарлыкның муниципаль берәмлек үсеше өчен мөһим ролен аңлап, район хакимияте биредә кече эшкуалык объектлары өчен уңай шартлар тудыра, үз җаваплылыкларында булган мәсьәләләрне оператив рәвештә хәл итү дә шул исәптән. Дәүләт тарафыннан каралган төп ярдәм чаралары эшкуарларга җиткерелә, квалификацияле мәгълүмат-консультация ярдәме күрсәтелә.

Тукай районы башлыгы Фаил Мисбах улы Камаевны 50 яшьлек юбилее белән котлап, эшкуарлар исеменнән аңа иминлек, ныклы сәламәтлек һәм бәрәкәтле тормыш телим. Аның җаваплы хезмәте һәм энергиясе һәрвакыт Тукай районы халкы файдасына булачак яңа уңышларга һәм казанышларга китерсен!

КЫЮЛАР БИКЛӘНЕП ЯШӘМИ

Теге яки бу авылга баргач: «Мондый хәлне күргән юк иде әле», – дип, сәяхәттән еш кына шаккатып кайтасың. Икенче юлы инде бүтән болай гаҗәпләнмәм, дип уйлыйсың... Ә юк, һәр сәфәр алдагысына охшамаган, чөнки кешеләре, аларның яшәү рәвеше бүтән, авылларның урнашу урыны, тарихы, җире дә башка.

Автор:
Руфия Фазылова

«УЕН АВТОМАТЛАРЫ АЧТЫЛАР»

Бу юлы без Тукай районының Бикләй авылында булдык. 1700 кеше яши биредә, 560 хуҗалык бар. Бикләй – Яр Чаллы шәһәреннән 15 чакрым ераклыкта урнашкан. Һәм Түбән Кама шәһәреннән дә – нәкъ шул ераклыкта. Ул гади авыл булудан бигрәк, бистәне хәтерләтә. Яшәү рәвеше буенча шәһәрнекеннән бер дә ким түгел. Бәдрәф, гигиена өчен уңайлыклар – өйдә, күп йортларда бассейн бар, һәр хуҗалыкта диярлек теплица тоталар... Шуңа күрә биредә су проблемасы кискен тора икән, аеруча ул җәен сизелә, диләр. 2011 елда «Чиста су» дәүләт програмасы нигезендә 12 чакрым су челтәрен алыштырганнар. Тик Бикләндә бер-бер артлы яңа урамнар барлыкка килә тора, аларны да сулы итәргә кирәк.

– Бикләндә 5 су скважинасы, 2 су башнясы бар, ләкин су һәр урамга барыбер җитми, – диде Бикләй авыл җирлеге башлыгы Сәхбиев Мансур Шакирҗан улы. – Авылны тулысынча яктырттык, менә су проблемасын да чишеп бетерә алсак...

Проблемалар турында сүз чыккач, авыл җирлеге башлыгы белән алга таба да шул хакта сөйләштек.

– Зур авылның проблемалары да олы була инде, – диде Мансур әфәнде. – Бөтен җирдә чисталыкны саклау авыр. Аеруча язын кыен. Инде менә ничә көн җыештырабыз, әле эшнең очы-кырые күренми. Трактор керә алмый торган җирләр бар, аларны да тәртипкә китерергә кирәк. Минем кул астымда техника да, әллә никадәр кеше дә юк бит. Авыл җирлегендә өч кеше хезмәт куя. Кечкенә авылларда да шул кадәр кеше эшли. Мисал өчен, алар 500 кешенең документын кулдан үткәрсә, без 1700 кеше белән эшлибез. Әй, санап китсәк күп инде. Зарлану түгел бу, дөрес аңлагыз. Ничек бар, шулай гына әйтәм.

Ул да түгел, авыл җирлеге идарәсенә ике сөйкемле ханым килеп керде. Мансур Шакирҗанович аларны үзе чакырган икән.

– Авылыбызның активистлары, йөзек кашлары – Рәзинә апа белән Фирая апа, – дип таныштырды ул.

Рәзинә апа Сәетгәрәева – җирле «йолдыз». Тукай районы гимны авторы, башка бик күп җырларга да шигырь язган шагыйрә ул, журналист та әле. Шактый еллар район газетасында эшләгән. Хәзер лаеклы ялда. Туган авылы тарихы белән кызыксына. Бикләндә яшәгән өлкәннәр белән аралашып, материаллар җыйган.

– Бикләй авылы тарихы турында күп мәгълүмат тупладым, ничек тә шуны китап итеп бастырасы иде, – диде Рәзинә апа.

– Шундый зур авылда китап бастырырга акча бирүче иганәчеләр юкмы? – дим.

– И, сеңлем, китап кирәкмени хәзер кешегә?! Авылдагыларның бит күбесе читтән күчеп килгән кешеләр. Шуңа да Аларга тарихының да, китабының да хаҗәте юк. Хәзер урамга чыксаң, кешене таный торган түгел. Шәһәргә якын булгач, күпләр монда җир алып йорт сала.

– Димәк, авылыгыз бетми, яшәрә, дигән сүз бит. Кайбер районнар, яшәргә кеше юк, дип, зар елап утыра. Ә сез кешеләр күп күченеп килгәнгә уфтанасыз, – дим.

– Әйе, авыл бетми, анысы бар. Тик нинди кешеләр килә бит әле. Күбесе татарча да белми. Бикләндә гомергә татарлар яшәгән, дүрт мәхәллә генә булган. Ә хәзер туган авылым чын асылын югалта бара, менә шунысы бәгырьгә тия...

– 1990 нчы елларда мәчет белән янәшә уен автоматларына кадәр ачтылар, – дип сүзгә кушылды Фирая апа. – Читтән килгән бер хатын оештырды аны. Ул вакытларда авылның тынычлыгы булмады инде. Яр Чаллыдан, Түбән Кама шәһәрләреннән автоматта уйнарга килә иделәр. Төне буе тыз-быз машиналар чабыша, акырыш, сугыш. Хәтта бер ирне үтерделәр дә. Инде, Аллага шөкер, ул көннәр артта калды. Автомат аппаратларны яптылар, теге хатын да авылдан китте.

Бактың исә, Бикләй ниләр генә күрмәгән: үзгәртеп кору елларында монда бар да булган, яше-карты килеп кәеф-сафа корып та яткан хәтта...

Фото: Лилиана Вәлитова

– Хәзер андый эшләр авылда юк, – диде Мансур Шакирҗанович. – Закон да катгыйланды бит. Безнең тарафтан да контроль көчле. Менә шушы апалар белән авылның йөзен саклап калырга тырышабыз. Фирая апа әнә урам бәйрәмнәре оештырып йөри. Бәйрәмнәрдә күңелле итеп концертлар куялар.

– Авылда хәзер авыл балалары да гел русча сөйләшә, менә шуңа көенәм, – дип сүзен дәвам итте Рәзинә апа. – Мәктәптә класс саен диярлек бер-ике читтән кайткан русча сөйләшә торган укучы бар, менә шуларга ияреп безнекеләр дә туган телләрен оныта. Тәрбия мәсьәләләре дә үзгәрә. И, сеңлем, сөйләсәң – сүз, төртсәң, күз инде...

– Авылыбызның активистлары, йөзек кашлары – Рәзинә апа белән Фирая апа, – дип таныштырды авыл җирлеге башлыгы.

«БЕЗ ХИМИЯ АШАТМЫЙБЫЗ!»

Бикләндә ниләр белән генә шөгыльләнмиләр: мини-пекарня, ит эшкәртү цехы бар, блоклар эшлиләр, хәтта кечкенә генә завод та бар. «Соколъ» дип атала ул. Синтетик материалдан кирәк-яраклар ясыйлар. Тагын бередә чеби үстерәләр. Йөзләп түгел, меңләп!

Хановларның гаилә фермалары республикага гына түгел, бөтен Россиягә билгеле. Аларның чеби, үрдәк бәбкәләре Үзәк регионга, Себер, Урал төбәкләренә кадәр китә.

Эшнең башы 1990 нчы елларга барып тоташа. Ирле-хатынлы Ренат белән Гөлнур Хановлар берничә дистә чеби алып үстереп карый. Икенче елга тагын да күбрәк алалар. Шуннан, үзләренең ихатасына гына сыймыйча, туган авыллары Калининодагы иске ферма бинасын арендалыйлар... Бүген Хановларның фермалары Тукай районының Калинино, Бикләм, Яңа Мусабай авылларында да бар. Әле күрше Зәй районында да ачканнар. Барлыгы 18 корылма. Аларда берьюлы 800 мең баш кош үстерергә була икән.

Бикләндәге корылмалар (элеккеге ферма биналары) – Хановларның төпчек кызлары Гөлнара карамагында. Без килгәндә корылмада үрдәк бәбкәләре инде бар иде.

– Өч көн элек Оренбург өлкәсеннән алып кайттык, быел – беренче партия, – диде фермер Гөлнара ханым.

Хуҗа белән сары йомгаклар янына юнәлдек. Җырдагы кебек, дип уйлап куйдым. Нәни-йомшак 4 мең баш үрдәк бәбкәсен күргәнем юк иде әле. Барысы да – сап-сарылар, дулкын «ясап» йөгерешеп йөриләр. Гөлнара аларны «үти-үти» дип чакыруга, ишек янына йөгерешеп килделәр. Бу хәл үзеннән-үзе балачакны искә төшерде: бар иде бит хәтфәдәй чирәмдә бәбкә саклаган чаклар. Нәкъ шулай итеп чакырасың, алар синең арттан йөгерә...

– Өч көнлек бәбкә дә тавышка килә икән, – дибез, гаҗәпләнебрәк.

– Ничек өйрәтәсең инде. Аларны беренче көнне сабый баладан артыграк карыйсың. Авызларына суын да каптырасың, ризыгын да. Шунсыз тиз генә өйрәнеп китә алмыйлар.

Бәбкәләр бередә бер ай яши, аннан үзләрен сатуга чыгаралар

икән. Һәм яңаларын алып кайталар. Эш шулай көзгә кадәр дәвам итә. Чебиләрне дә бер ай үстерәләр дә саталар.

– Үрдәкләрнең бездә өч төре бар – «Темп», «Темп-Авангард», «Мулард», – диде Гөлнара. – Болар инде халык яратып өлгергән төрләр. Мәсәлән, «Темп» ул – бройлер-үрдәк. Ике ай дигәндә өлгерә алар. «Мулард»лар бик зур, 4 килога кадәр җитәләр. Индоутка белән пекин үрдәген «кушып» ясаганнар бу төрне. Өч ай дигәндә өлгерәләр. «Темп-Авангард» исә – төсле үрдәк, ите бик тәмле була.

Чебиләр исә дүрт төрле: «Бройлер РОСС – 308», аның авырлыгы 5,5 килога кадәр җитә. 2–3 айда бу авырлыкны җыялар. Йомырка сала торганнары – «Ломан-Браун», елга 400 күкәй бирәләр, үзләре кызыл төстә. «Корал» дигәне – әле чагыштырмача яңа төр. Суыкка чыдам, йомырканың кабыгы калын. «Супер-Ник» төре – шулай ук яңа гибрид. Тавык булып җитешкәч, бик активлашалар. Йомыркалары ак төстә, бик эре – 70 граммга кадәр җитә.

Кош-кортлар үстерүче династия вәкиле Гөлнара үрдәк, тавыклар турында әнә шундый мәгълүмат бирде безгә. (Бәбкә, чебешләр ала торган чак, журнал укучыларыбызга да әлеге мәгълүмат файдалы булыр, дип уйлыйбыз.)

– Ел саен диярлек кош грипплары чыгып тора, асрарга курыкмыйсызмы? – дим фермер ханымга.

– Курыксаң, эшләп булмый. Төрле вакыт була. Мәсәлән, узган ел кош гриппы дип карантин кертелгәч, бәбкә, чебиләрне сатуга чыгара алмадык. Андый вакытта минуска эшлисең. Ашатырга да кирәк бит. Зуррак үскән саен биби, чебиләрнең бәясе арта, ә халыкның кыйммәткә бик аласы килми. Шуңа да озак асрауның файдасы юк. Бер ай эчендә урнаштыра барырга кирәк. Яңа кайткан бәбкәләргә, чебиләргә, үлмәсен өчен, махсус прививка ясыйбыз, дару бирәбез. Ә ашату бездә берниндиhимиясез. Үзебезнең тегермән бар, иген сатып алып, шунда тарттырабыз. Кошлар натураль ризык ашап үсә. Шуңа күрә бер сатып алган кеше соңыннан гел безгә килә.

Хановларның бөтен гаиләсе – кызлар, кияүләр, оныклар – шушы эштә. Утыз ел эчендә, кирәге чыгып торгач, мал табибы һөнәрен дә, экономистныкын да үзләштергәннәр.

ЮРИСТТАН – ФЕРМЕРЛЫККА

Бикләннең читтагы фермерлары белән таныштык. Аталы-уллы Рафиз, Динар Вилдановлар үгез үстерү белән мәшгуль, 40 гектар җирләре бар. Өч ел элек КФХ булып теркәлгәннәр. Иң гаҗәпләндергәне шул булды – дәүләттән бер ярдәм алмаганнар. 45 баш үгез, ферма, берничә техника – шушы өлкәдә күп еллар эшләү нәтиҗәсендә барлыкка килгән байлык.

– Кредитларның берсен каплыйбыз, икенчесен алабыз, – диде Рафиз абый.

– Ә ни өчен дәүләт программаларында катнашмыйсыз? – дим.

– Әй... Документлар да җыйган идек. Очына чыга торган түгел. Ферма төзергә дип грант алырга уйлашкан идек тә, булмас, ахры. Кәгазь эше күп. Әле бер документ сорыйлар, әле икенчесен. Яратмыйм мин ул эшләрне...

Юрист дипломы алып, туган нигезенә Динар да кайткан. Аның максаты – фермер булу. Авыл башына ферма төзеп, мөгезле эре терлек үстерү.

– Дәүләттән акча алсаң, бәйле буласың, – диде Динар. – Кредит алсаң, тынычрак. Планнар шактый... Чаллыда 15 мең хезмәт хакына эшләп йөргәнче, дип, менә авылга кайттым. Әлегә әтигә ярдәм итәм. Монда эш бөтен кешегә җитә.

...Биклән турындагы сәяхәтнамәгә шушы урында нокта куям. Мондый зур авылны, әлбәттә, бер язмада гына ачып бетереп булмый. Ләкин аерым тәэсирләр белән

Дәүләттән бер ярдәм алмаганнар фермерлар – аталы-уллы Рафиз, Динар Вилдановлар.

уртаклаша алам. «Май чүлмәге тышыннан билгеле», дигәндәй, авыл җирлеге башлыгы Мансур Шакирҗанович килгәч тә, иң «авырткан» җирләре турында сөйли башлаган иде. (Гадәттә, җитәкчеләр журналистларга барысы да ал да гөл дип күрсәтергә ярата). Хәтта социаль яктан куркыныч гаилә булып исәптә торган ана белән балалар янына да алып барырга теләгән иде, вакыт җитмәде. Авылның апалары да бөтен нәрсәне ничек бар, шулай сөйләде. Сүз дә юк, кыю халык яши биредә. Ул аларның сөйләмнәрендә генә түгел, яшәү рәвешләрендә дә сизелә. (Әйтик, хәмер сатып ята торган барны, уен автоматын яптырганнар.) Эшкуарларның күп булуы халыкның тәвәккәллеге турында сөйли. Теләк бер – гел шундый кыю, батыр булсыннар, ә иң мөһиме – татарлыкларын, үз йөзләрен югалтмасыннар.



ТАРИХ БИТЛӘРЕННӘН

«Бикләнавылының төгәл төзелү вакыты билгеле түгел. Казан ханлыгы җимерелгәч барлыкка килүе хак, дип исәплиләр. Якын-тирәдәге рус авыллары Бикләнне Бичурин дип атап йөрткән. Ни өчен дигәндә, авылга Байчура исемле кеше нигез салган дип фаразлана. Чукындырудан качып, урман уртасына килеп урнашканнар. Ул урында чишмә дә булган.

Халык арасында авылның исеме белән бәйле тагын бер тарих та йөри. Имеш, урман арасына килеп урнашкан халык: «Бикләң, бикләндек», – дип сөйләшкән.

Борынгы бабаларыбыз умартачылык белән шөгыльләнгән булырга тиеш. Урманда юан имән, яки юкә агачының башына ясалган умарталарны авылның аксакаллары әле дә хәтерли. Тора-бара урманнарны кисеп, чирәм җирләр ясаганнар.

Бикләнавылы 1917 елгы революциягә кадәр Уфа губернасы, Минзәлә өязе, Бәтке волостена буйсынган. 1919 елда 700 хуҗалыкка җиткән, аннан нык кимегән – 1921 елгы ачлыкта бик күп кеше үлгән. Шул чорда берничә хуҗалык Себер ягына күченеп киткән. 1924 елда Бикләнавылыннан – Бакчасарай, ә 1926 елда Кызыл юл бистәсе бүленеп чыккан».

Рәзинә Сәетгәрәеваның авыл тарихына караган тупланмаларыннан.

ИСЕМЕН АТАРГА ЯРАМЫЙ ТОРГАН БЕРӘҮ

Март азагында Казан Ратушасындагы «Окно» галереясын курчаклар белән песиләр басып алды. Әлеге, бер карагаңда, төрле ырудан булган шәхесләрне «Казан Песиенең дуслары» дип аталган күргәзмә берләштерде. Әмма ул күргәзмә тиз арада «Исемен атарга ярамый торган берәүнең дуслары»на үзгәрде дә куйды. Шул рәвешле легендар Казан персонажы әкияти персонажга әверелде – Гарри Поттерча рух алды хәтта. Ни өчен дисезме? Чөнки ул патентланган, димәк ки, нинди дә булса исем-атамаларда кулланылырга тиеш түгел. «Песи» яисә «Казанныкы» дигән сүзләрне аерым кулланганда, бернинди куркыныч янамый әле. Ә менә аларның икесен бергә кушып, «Казан песие» дисәң, инде авторлык хокуклары турында уйларга кирәк булачак... Шактый зур күләмдә штраф түлисең килмәсә, алай дип атамыйсың, әлбәттә.

Шунысы сөендерә: «Исемен атарга ярамый торган берәү» «тәмле ашап, йоклап» кына ятмый, ә бик әйбәт итеп, тырышып токым да калдыра. Шулай булгач, аның балалары, оныклары һәм онықчыклары – шулай ук Казан песиләре (күплек санда кулланганда, патент дип шикләнәсе юк) – үзләренең «ата-бабаларын» менә дигән итеп, югары дәрәҗәдә күрсәтә алды. «Окно» галереясында Казан кул осталары тарафыннан әзерләнгән бик күп төрле курчаклар янәшәсендә песи затлары үзләрен гаять уңайлы хис итте, кыскасы. Халык тегеләренә дә сокланды, боларына да. Ягъни курчакларга да, песиләргә дә. Өч көнә көн дәвам итсә дә, күргәзмә курчак белән песи яратучылар арасында зур игътибар һәм ихтирам казанды.

Галереяның хуҗабикәсе Диләрә Байчурина курчак һәм песи темасының халык өчен бу дәрәҗәдә кызыклы булуын моңарчы белмәгән дә икәнлегенә басым ясады. Алга таба мондый күргәзмәләрне ешрак оештырырга вәгъдә бирде.

Фото: Ната Смирнова

ТАССРНЫҢ 100 ЕЛЛЫГЫНА

БАГЫШЛАНГАН УНИКАЛЬ ОТКРЫТКАЛАР КОЛЛЕКЦИЯСЕН ҖЫЙ



2019 ел. Болак.
Апрель

Фото: Александр Ефремов

ТАССР 100 ЛЕТ ЕЛ

ТАССРның 100 еллыгына

багышланган уникаль открыткалар коллекциясен җый

«...Татреспубликадагы бәла-казаның күләме санап бетергесез... Су басу белән көрәшү өчен кичектергесез чаралар күрү таләп ителә... Җирле бюджеттагы кытлыкны һәм киеренкелекне исәпкә алып, тиз арада әлегә ике йөз мең сум күчерүегезне сорыйбыз...»

РСФСР Халык комиссарлары Советына юлланган 212нче телеграммадан

1926 ел. Болак.
1926 елның май башында Казанны су баса башлый, бу хәл 20сенә кадәр дәвам итә. Суның биеклеге нормадан артып китә һәм 14,5 метрга күтәрелә. Шәһәр үзәгендәге илле бер урам су астында кала, кешеләр арасында курку башлана. Болак аркылы салынган барлык агач күперләрне су агызып китә, таштан салынган Лебедев күпере дә су астында кала. Су Болак ярындагы өйләрнең икенче катына кадәр күтәрелә. Георгиев урамы (хәзерге Петербург урамы) буенча көймәләрдә генә хәрәкәт итеп була. Туфрактан өелгән барлык дамбаларны да су ишә, «Спартак» фабрикасын, Елга аръягындагы җитен комбинатын тулысынча су баса.

Фото: Арнольд Бренинг. Абдулла Дубин коллекциясеннән.